

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# ШАНХАЙ ТӨРК-ТАТАР МӘДӘНИЯТ ҖӘМГЫЯТЕ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# ШАНХАЙ
# ТӨРК-ТАТАР
# МӘДӘНИЯТ ҖӘМГЫЯТЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2012

УДК 902/904 + 30
ББК 63.2 + 71
Ш 21

*Төзүчесе, басмага әзерләүче
һәм махсус мәкаләләр авторы–
археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

Ш 21 **Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте** / төз. Раиф Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 9 нчы китап).

ISBN 978-5-88473-063-2

Китапта XX гасырның беренче яртысында Кытайдагы Шанхай шәһәрендә яшәгән татар мөһаҗирләренең тормышы тасвирлана. Андагы төрки-татарлар 1925 елдан башлап оештырылган төрле җәмгыятьләре ярдәмендә милли-мәдәни мохитне 1940 нчы еллар ахырына кадәр саклап килгәннәр.

Бу җыентыкта Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең 1934–1936 еллардагы җыелыш беркетмәләре һәм шушы оешма эшчәнлеген яктырткан, мөһаҗирлек матбугатында дөнья күргән материаллар урын алды.

ISBN 978-5-88473-063-2

УДК 902/904 + 30
ББК 63.2 + 71

© Мәрданов Р.Ф., 2012
© «Милли китап» нәшрияты, 2012

## «ЮЛЫБЫЗ ТУГРЫ, МИЛЛӘТЕБЕЗ КӨЧЛЕ»

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең 1934–1936 елларда узган җыелыш беркетмәләре журналы Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондына 1993 елда саклануга алынды. Беркетмәләр дәфтәрен һәм бүтән кызыклы материалларны Америка Кушма Штатларының Калифорния штатында яшәүче татарлар җәмгыятенең президенты Равил Салиәхмәт китапханәбезнең ул вакыттагы директоры Разил әфәнде Вәлиевкә биргән иде. Равил әфәнденең әтисе Кәшшаф һәм әнисе Мәдинә – Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең җитәкчеләреннән булганнар.

Ерак Шанхай шәһәрендәге татар мәдәни җәмгыятенең шушы кыйммәтле документаль чыганагын «Татар археографиясе» сериясенең бер китабы рәвешендә бастырырга кирәк дип таптык. Тик, җыелыш беркетмәләре дәфтәрен басмага әзерләү белән бергә, Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең эшчәнлеген дәфтәрдә теркәлгән 1934–1936 еллардагы документлар белән генә чикләү ярап бетмәс иде. Шул сәбәпле, татарларның Көнчыгыш Кытайга кайчан килеп төпләнүләре һәм андагы иҗтимагый мохит турында, Шанхайдагы Татар мәдәният җәмгыяте идарәсендәге шәхесләр, бу җәмгыятьнең башка еллардагы эшчәнлеге хакында үзебез туплый алган мәгълүматларны тема таләп иткән микъдарда язарга булдык.

1898 елда Көнчыгыш Кытай тимер юлы төзелешенә һәм шул төбәккә сәүдә эшләре белән татарлар күпләп барып урнаша башлаган. Берничә елдан андагы тимер юл буе кибетләре һәм рестораннары, тулаем диярлек, татар эшкуарлары карамагында булган. Милләттәшләребезнең Манҗуриядә төпләнүләре тарихы матбугатта шактый яктыртылган. Татарларның андагы кайсы шәһәрләрдә яшәгәнлекләре, милли-мәдәни тормышлары һәм язмышлары ту-

рында милләттәшебез, җәмәгать эшлеклесе, публицист һәм библиограф Мәхмүт Таһир (1922–1991) Төркиядә 1970–1980 нче елларда чыккан «Казан» журналының төрле саннарында дәвамлы мәкаләләр бастырып килгән[1]. Аның язмалары Ерак Көнчыгыштагы татар мөһаҗирлеге турында язган башка авторлар өчен нигез булган. 1990 елларда татар матбугатында Манҗуриядәге татарлар тарихы турында галим Әбрар Кәримуллин (1925–2000) әтрафлы мәкаләләр язып бастырды. Галимнең бу турыда төрле журналларда һәм газеталарда чыккан мәкаләләре «Язмыш, язмыш» исемле китабында туплап бирелде[2]. Башка галимнәрнең дә бу темага караган хезмәтләре басылды[3]. Кытайда, Төркиядә һәм АКШта яшәгән, шактый катлаулы тормыш юлы үткән, Салиәхмәтләр нәселе кызына өйләнгән Әмрулла Аги (1912–2001) китабында Кытайдагы татарларның тормышы һәм мөһаҗирлектәге башка милләт вәкилләренә, аларның төрле оешмаларына милләттәшләребезнең мөнәсәбәте әтрафлы итеп тасвирланган[4].

Харбин шәһәренә татарларның килеп урнашу тарихын Ә.Кәримуллин болай дип язды. «Татарлар Харбинга XX йөзнең беренче елларында ук киләләр. Азмы-күпме татар җыелгач, бередә дә халык үз мәнфәгатьләрен кайгырта башлый. Тиз арада милли-дини җәмгыять оеша... Сәүдәгәр һәм баерак татарларның акчасына Харбинда 1906 елны зур гына мәчет бинасы салына... Балалар саны арту сәбәпле, мәктәпкә яңа бина төзелә. Аны төзү өчен Харбин шәһәрендәге татар үзешчән театр труппасы концертлар, спектакль куеп, акча җыя. Мәктәптә китапханә, уку заллары да ачыла... 1918–1919

[1] Аның кайбер мәкаләләре Татарстан матбугатында да дөнья күрде. Мәсәлән: Таһир Мәхмүт. Ерак Көнчыгышта татар сәүдәгәрләре // Мирас. – 1992. – №11. – Б. 52–56.
[2] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – 423 б.
[3] Ивао К. Татарлар Япониядә // Йөртә безне язмышлар...: фәнни-популяр очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 46–53; Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция: начало XX века – 30-е годы: исторический очерк. – Набережные Челны: Камский издательский дом, 1997. – 159 с.; Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды. – Казан: ун-т нәшр., 2005. – 100 б.; Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция в Северо-Восточной Азии начала XX в. // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2005. – №1. – С. 92–100.
[4] Аги Э. Жизнь одного человека: незавершенная автобиографическая повесть. – Казань: Магариф, 2003. – 175 с.

елларда Россиядән килгән качаклар хисабына Харбинда татарлар саны тиз арта. Качаклар арасында әдәбият-сәнгать, мәгърифәт әһелләре дә шактый күп була. Алар килгәч, Харбиндагы татар әдәби, мәдәни, мәгърифәт эшләре аеруча җанлана... 30 нчы елларда Харбинда 1000-нән артык татар яши, аның мәктәпләрендә 100-дән артык татар баласы белем ала... Харбинның беренче имамы Россиядән чакырылган Гыйниятулла ахун Салиәхмәт була»[5].

## Салиәхмәтләр

Харбин шәһәрендә яшәгән татарлар һәм, гомумән, Ерак Көнчыгыштагы милли мөһаҗирлек тарихы уңаеннан Салиәхмәт фамилиясе еш очрый.

Пенза губернасының (хәзерге Мордовия Республикасының Торбеево районындагы) Юнә авылы егете Гыйнәятулла Салиәхмәт 1908 елда Харбинга имам булып килгән. Ул тирән белемле, милләтпәрвәр шәхес булган. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, 1916 елда Харбиндагы татар мәхәлләсе Кытай, Япония һәм Кореядәге барлык төрк-татар җәмгыятьләренең төп үзәге булып җитешкән. Гыйнәятулла Әхмәди (Салиәхмәт), Хөсәен Габдүш (1901–1944) һәм Рәшит Рәхмәти (1900–1964) тарафыннан 1920–1922 елларда Харбинда татар телендә «Ерак Шәрык» исемле журнал нәшер ителгән. 1924–1925 елларда шундый ук исемдәге газета чыгарылган. Идел буе болгарларының Ислам динен кабул итүенә багышлап, Харбинда 1922 елның 28 май көнендә «Мең ел» исемле, бер көнлек газета бастырылган. Шул ук истәлекле вакыйга уңаеннан Харбинда 1922 елда зур мәчет төзелә башлаган. Ул төрле сәбәпләр аркасында 1937 елда гына төзелеп беткән[6].

Дин һәм милләт өчен игелекле эшләре белән зур абруй яулаган Гыйнәятулла хәзрәт Салиәхмәт 1926 елның 15 сентябрендә вафат

---

5 Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 28–30.

6 Бу хакта тулырак мәгълүматны карагыз: Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – 423 б.

булган. Аның эшен имам Мөнир хәзрәт Хәсбиуллин[7] (1896–1944) дәвам иткән. Мөнир хәзрәткә мәрхүм Гыйнәятулла мулланың бертуган энесе Кәшшаф Салиәхмәт (Әхмәди) ярдәм иткән. Сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгән Кәшшаф бөтен буш вакытын милли-мәдәни эшкә багышлаган. Аңа җәмәгате Мәдинә булышкан[8].

Әмрулла Аги, Харбиндагы төрк-татар яшьләре түгәрәге әгъзасы буларак, гаять тәртипле һәм бик намуслы Кәшшаф Салиәхмәт белән якыннан аралашып, милли бәйсезлек һәм хөррият фикерләре рухында тәрбияләнгән. Ул К.Салиәхмәтне үзенең һәм, гомумән, бөтен төрк-татар яшьләренең остазы, иң зур мәгърифәтче дип санаган һәм аның 1932 елда Харбинны көчле су басу фаҗигасеннән соң Шанхайга киткәнлеген язган[9]. Дөрес, К.Салиәхмәтнең китү сәбәбе нәкъ су басуга бәйләп әйтелмәгән. Бәлки Әхмәдиләр гаиләсенең Харбиннан Шанхайга күчеп китүе ул елларда бөтен дөньяда икътисадый кризисның көчәюенә дә бәйле булгандыр. Салиәхмәтләр гаиләсенең Харбиннан Шанхай шәһәренә күчеп китү вакыты турында Ә.Кәримуллин ике төрле дата: 1932 һәм 1934 елларны күрсәткән[10], ә галимә Лариса Усманова Кәшшаф Салиәхмәт 1933 елда киткән, Мәдинә белән улы 1934 елда килгән дип яза[11]. Дөреслектә исә, Әмрулла Аги язганча, 1932 елда Кәшшаф Шанхайга китеп, аның янына җәмәгате белән улы 1933 елда күченгән. Равил Салиәхмәтнең хатирәләрендә дә К.Салиәхмәтнең Харбиннан китү елы «1932 елларда» дип язылган[12]. Мәдинә Салиәхмәтнең 1941 елда инглизчә басылган мәкаләсенә кереш сүз язган журнал редакторы Клаус Мехнертның сүзләре дә моңа дәлил булып тора. Ул Мәдинә ханымның Шанхайда 1933 елдан яшәве турында язган[13].

---

[7] Хәсбиуллинның фамилиясе кайбер китапларда хаталы итеп башкача язылган очраклар да бар.
[8] Аги Э. Жизнь одного человека... – С. 37–38.
[9] Шунда ук. – Б. 42, 44, 45, 50, 65.
[10] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 52, 60.
[11] Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция Дальнего Востока: «Тюркские народы не были готовы защищать себя от большевистского потока...» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2007. – №2. – С. 185.
[12] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 74–75.
[13] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 60; Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2007. – №2. – Б. 186.

Кайбер Интернет сайтларында Кәшшаф Әхмәди 1933 елда Шанхайда имам булып билгеләнгән дип язылган мәгълүмат бар. Әмма бу сүзләр хакыйкатькә туры килми. Чөнки Шанхай татарлары арасында имамлык вазыйфаларын 1925–1928 елларда Мәдияр Шәмгуни (1874–1939), аннан соңгы елларда Әүхәди Җамалетдин үтәгәнлеге билгеле.

Әбрар Кәримуллин, Равил Салиәхмәт биргән мәгълүматлар нигезендә, Мәдинә Салиәхмәткә багышлап, «Халкыбызның батыр кызы» исемле махсус мәкалә язган иде. Шул мәкаләнең кайбер урыннарын монда күчерәбез. «Мәдинә 1897 елның 12 декабрендә Уфа шәһәрендә дөньяга килә. Әтисе – Хөсәен Солтан Галиуллин Асекай Пенза ягындагы Аллагол авылыннан XIX йөзнең 70 нче елларында Уфага күченеп килә һәм мөфти бертуган Тәвкилевләрнең имениесендә управляющий булып эшли. Унынчы елларда – «Мусульманское духовное собрание»нең[14] секретаре. 1914 елда вафат була. Әнисе – Киндеркүл авылы[15] кызы Гайнехәят Гайнетдин Бәгми Авзал[16].

Мәдинә башлангыч белемне өйдә әнисеннән ала, аннары татар мәктәбендә укый. Урыс гимназиясен тәмамлагач, әнисе аны Санкт-Петербургка, олы абыйсы Ибраһим янына җибәрә. Ибраһим биредә югары уку йортын тәмамлап, башкалада яши. Мәдинә 1916–1917 елларда Санкт-Петербургта табигать фәннәре буенча хатын-кызлар укый торган югары курсларга керә, ләкин революция мәхшәре башлангач, укуын ташлап, Уфага кире кайта... 1920 елда биредә Мәдинәнең әнисе һәм абыйсы Госман тифтан вафат булалар... Ике ятим кыз Мәдинә белән Зәйнәп Харбинда татар мәктәбенә укытучылар кирәген ишеткәч, Маньчжуриягә барып чыгалар һәм биредә укытучы булып эшли башлыйлар. Алар Харбин татар мәктәбендә

---

[14] Ягъни, Диния Нәзарәте (Мәхкәмәи шәргыяи исламия).

[15] Китапта Киндеркүл исемле авылның кайсы төбәктә икәнлеге язылмаган. Тик андый исемдәге татар авылы Татарстан Республикасының Кукмара районында барлыгын искәртәбез. Ә Татарстаннан читтәге төбәкләрдә Киндеркүл исемле авыл бармы яисә элек булганмы – анысы безгә билгесез.

[16] Гайнелхәят Әсәкәева 1912 елда Уфада оештырылган мөслимә ханымнар җәмгыяте хәйриясенең рәисе итеп сайланган. Аның шул елларда төшкән фоторәсеме Айсылу Юнысова китабында басылды (Юнусова А. Ислам в Башкортостане. – Уфа, 1999. – С. 67).

эшлиләр. Дөнья бераз тынычлангач, Зәйнәп 1923 елны Уфага кайта... Мәдинә Асекай исә Харбинда кала, укытучы булып эшләвен дәвам итә һәм Гыйнәятулла (Инниятулла) Сәлихмәтнең (1888–1926) энесе Кәшшаф Сәлихмәткә (1890–1963) кияүгә чыга. Асекай фамилиясен Салихмәткә (Сәлиәхмәткә) алыштыра...

Мәдинә Сәлихмәт төрек, урыс, инглиз, француз телләрен яхшы белгән. Шанхайга күчеп килгәч, ул шушы телләрдә төрле илләрдә чыга торган матбугатны күзәтеп бара. Максаты – СССР халыкларының язмышы, иң беренче чиратта төрки-татар халыкларының хәле турындагы информацияләрен барлап, танышып бару. Төрки-татар халыкларының хәле һәм алар турында язылган материаллар буенча Маньчжуриядә чыгып килә торган «Милли байрак» газетасына күзәтүләр, аерым мәкаләләрнең тәрҗемәләрен җибәреп тора. Шул ук вакытта Мәдинә ханым Шанхайда һәм Маньчжуриядә яшәүче урыслар һәм чит ил кешеләре арасында татарларны таныту буенча да өзлексез эшләп килә. Харбин, Мукден, Шанхайда чыга торган урыс газеталарында татар халкының тарихы, аның күренекле уллары турында зур-зур мәкаләләр бастырып килә»[17].

Мәдинә һәм Кәшшаф Салиәхмәтләрнең милли-мәдәни эшчәнлекләре турында Ә.Кәримуллин болай язган. «Мәдинәнең ире сәүдә эше белән шөгыльләнсә дә, абыйсы кебек үк, ул да Кытайда татар җәмгыятенең рухи, дини, милли эшендә актив катнаша, табышының күп өлешен татар мәктәпләре өчен сарыф итеп килә. 1932 елда Мәдинә һәм Кәшшаф Салиәхмәтләр уллары Равилне алып, Шанхайга күчеп китәләр. 1934 елда Кәшшаф Шанхайдагы татар җәмгыятенең рәисе итеп сайлана. Мәдинә ханым, ире белән бергәләп, биредә яшәүче татарларны берләштерү, аларның балаларына милли белем бирү, укыту эшләренә керешә. Татарлар өчен төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештырып килә. Биредә яшәүче, большевиклар Россиясеннән качкан башка милләт кешеләре белән элемтәләр урнаштыра. Шанхайда оештырылган «Идел-Урал, Украина, Кавказ халыкларының милли азатлык комитеты»ның вице-президенты булып сайлана (бу комитетның исеме бүтән чыганакларда төрлечәрәк искә алына). Шанхайда яшәүче татарларның милли аңын үстерү, үз халкының үткәне, күренекле затлары белән та-

[17] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 51–52, 56–57.

ныштыру йөзеннән алар Маньчжурия, Япониядә басыла торган китапларны, Төркия һәм башка илләрдә дөнья күргән, татарларга караган басмаларны алдыртуга әһәмият бирәләр»[18].

1940 нчы елларда, Икенче бөтендөнья сугышы вакыйгаларына бәйле рәвештә, Шанхай шәһәрендә дә сәяси һәм иҗтимагый тормыш зур үзгәрешләргә дучар булган. Анда яшәгән мөһаҗирләр чит илләргә күчеп киткән. Салиәхмәтләрнең уллары Равил 1948 елда, ә Кәшшаф белән Мәдинә 1949 елда Шанхайдан Төркиягә күчеп киткәннәр. «...Бирегә килгәч, Мәдинә ханым Кытайда башлаган эшләрен дәвам итә: татарлар арасында милли аңны үстерү, татар балаларына милли сабак бирү, телне саклап калу. Төркиядә татарларны таныту буенча да эшли. 1964 елның 22 маенда ул – 67 яшендә күзен йома, Истанбулның Фәрикой зиратында җирләнә. Халкыбызның бу батыр кызы, зур мәгърифәтчесе, милләтебезнең азатлыгы, халкыбызның якты киләчәге өчен көрәшкә бөтен гомерен биргән бу изге җанның исеме – тарихыбызның аерылмас өлеше ул»[19]. Мәдинә Салиәхмәтнең исеме «Татар энциклопедиясе»нә дә кертелгән[20].

Равил Салиәхмәт 1926 елда Харбинда туган[21]. «Равил башта укырга-язарга әнисеннән өйрәнә, аннан бер ел буе Харбиндагы урыс балалар бакчасына йөри. Шанхайга күчеп килгәч, французлар ачкан урыс мәктәбендә өч ел укый. Анда уку инглиз, француз, урыс телләрендә алып барыла. Аннары аны инглиз мәктәбенә бирәләр, аны тәмамлагач, ул француз университетына укырга керә. Анда бер ел укыгач, Кытайда властька коммунистлар килә. Бу

---

[18] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 52–53.
[19] Шунда ук. – Б. 58.
Ә.Кәримуллин М.Салиәхмәтнең Россия төркиләренең тарихи үткәненә багышланган, Шанхайда инглиз телендә басылган «The XX Century» журналының 1941 елгы 2 нче санында чыккан күләмле мәкаләсен татарчага тәрҗемә итеп бастырган иде (Мирас. – 1994. – №11–12. – Б. 172–179; Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 60–70). Лариса Усманова бу мәкаләне рус теленә тәрҗемә итеп чыгарды (Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2007. – №2. – Б. 186–193).
[20] Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2002. – Б. 539; Татарская энциклопедия. – Т. 5: Р–Т. – Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2010. – С. 215.
[21] Ә.Кәримуллин Равил Салиәхмәтне 1926 елда туган дип язган иде (Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 71), ә Л.Усманова 1927 елда туган дип язды (Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция Дальнего Востока... – С. 185).

шартларда Сәлихмәтләр Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Биредә Равил технологик университетта укый башлый. Әтисе авыру сәбәпле, ике елдан аны ташлап, 1951–1952 елларда АКШның Төркиядәге бер зур фирмасында конструктор булып эшли. Аннан ике ел Төркия армиясендә офицер булып хезмәт итә. Армиядән соң шул ук фирмага эшкә кайта һәм аның йомышларын үтәп, Иран, Гыйрак, АКШка йөреп тора... Аннан ул АКШта яши башлый... Ул үз һөнәре буенча 1991 елга хәтле АКШ компаниясе исеменнән Канадада эшли. Хәзерге көндә Равил Салихмәт пенсиядә, АКШта яши. Сан-Францискодагы татар җәмгыятендә, андагы татарларны милли рухта тәрбияләүдә актив эшләп килә. Ул соңгы елларда ике тапкыр Казанга килеп китте, 1992 елда үткәрелгән Бөтендөнья татар конгрессында да катнашты... Равил Салихмәт – полиглот. Ул инглиз, немец, француз, гарәп, төрек урыс телләрен дә яхшы белә»[22].

Соңгы мәгълүматыбыз буенча, Равил Салиәхмәт хәзерге вакытта Нью-Йоркта яши.

## Ерак Көнчыгыштагы төрк-татарлар арасындагы фикер каршылыклары

1930 нчы елларда Ерак Шәрыктә хөкем сөргән милли һәм иҗтимагый вәзгыятьне күзалламыйча, Шанхай шәһәрендә яшәгән татарлар арасындагы кайбер мәсьәләләрне аңлау-төшенү читен. Шул сәбәпле, әлеге мәсьәләләрне тасвирлап узабыз.

Токио шәһәрендәге мөселман мөһаҗирләре үзәген җитәкләгән эмигрант Габделхәй Корбангалиевкә[23] 1930 нчы еллар башында

---

[22] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 71–73.

[23] Мөхәммәт-Габделхәй Корбангалиев (Корбангали, 1889–1972) – Оренбург губернасының Чиләбе өязе Мидияк авылында туган. 1915–1916 елларда мөфти Мөхәммәдъяр Солтановның сәркятибе булган. Гражданнар сугышы вакытында Колчак гаскәре калдыклары белән Себергә, аннан Манҗуриягә киткән. Башта Манҗуриядә, 1925–1938 елларда Япониядә яшәгән, имамлык вазыйфаларын башкарган. Токио шәһәренең мөселман җәмгыяте җитәкчесе булган. Токиода мәчет, мәдрәсә һәм матбага төзеткән. 1938 елда япон хөкүмәте тарафыннан кулга алынып, Япониядән Кытайга сөрелгән. Ә 1945 елда совет контрразведкасы тарафын-

япон хөкүмәте даирәсеннән бөтен Ерак Көнчыгыштагы (Япония, Кытай, Манҗуриядәге) татар мөһаҗирләрен берләштерергә тәкъдим ителгән. Шул максатта 1932 елның июнь аенда Г.Корбангали, япон һәм рус мөһаҗирләре оешмасы вәкилләре катнашында киңәшмә үткәрелгән. Анда татар мөһаҗирләренең үзәк оешмасын һәм идарәсен оештыру өчен Токиода мөселман корылтае уздыру турында карар кабул ителгән һәм бу эшләр Г.Корбангалигә йөкләнгән[24].

Ләкин башка татар милли лидерлары белән каршылыклар чыгу нәтиҗәсендә, Габделхәй Корбангали үзенә ышанып тапшырылган эшне тиешенчә үтәп җиткерә алмаган. Шунлыктан, японнар татар мөһаҗирләрен берләштерүне лаеклырак кешегә – ул вакытта Европада яшәгән Гаяз Исхакыйга (1878–1954) тәкъдим иткәннәр. Идел-Урал мөстәкыйль дәүләтен төзү уе белән янган Г.Исхакый Ерак Көнчыгыштагы төрки-татар мөһаҗирлегенә зур өметләр баглаган[25].

Гаяз Исхакый төрки-татар мөһаҗирләрен берләштерү максаты белән 1933 елның 16 октябрендә Токио шәһәренә килгән. Поляк телендә язылган бер рәсми документта Гаяз Исхакыйның Токиога килгән вакыты 16 сентябрьдә дип ялгыш язылган. Бу хаталы дата матбугатта да басылып чыкты[26]. Югыйсә, ул үзе бер мәкаләсендә 24 көнгә сузылган сәфәрдән соң, 2 октябрь көнендә Шанхайга ки-

---

нан Далянь (Дальний) шәһәрендә кулга алынып, ун ел Владимир шәһәре төрмәсендә утырган. Тоткынлыктан азат ителгәч, аңа Токиодагы гаиләсе янына китү тыелган. Вафатына кадәр туган төбәге Чиләбе өлкәсендә муллалык вазыйфаларын үтәгән.

Бу затның үзе һәм нәселе турында өстәмә мәгълүмат алырга мөмкин: Юнусова А. Ислам в Башкортостане. – Уфа, 1999. – С. 74–82, 110–114, 122; Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 40–41; Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция в Северо-Восточной Азии – С. 93, 97; Ислам на Урале: энциклопедический словарь. Вып. V. – М.; Нижний Новгород: ИД «Медина», 2009. – (Серия «Ислам в Российской Федерации). – С. 176–177.

[24] Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 103.

[25] Шунда ук. – Б. 103–105.

[26] Исхакый Гаяз. Япония–Токио // Мирас. – 1998. – №2. – Б. 30; Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 108; Мусин Ф. Гаяз Исхакый: тормышы һәм эшчәнлеге. – Казан: Татар. китап нәшр., 1998. – Б. 118.

леп җиткәнлеген язган[27]. Галим Рөстәм Гайнетдинов язуынча, Г.Исхакый белән Г.Корбангалинең кайсы сәләтлерәк һәм абруйлырак – ягъни кулайрак булачагын ачыклау өчен японнар ике җитәкче арасында үзенчәлекле «конкуренция» оештырганнар. Бу исә ике лидер тарафдарлары арасында, вакыт-вакыт якалашуга кадәр барып җиткән, ямьсез төс алган. Ике тараф та бер-берсен Совет хөкүмәте һәм чекистлар белән бәйлелектә гаепләгән. Ерак Шәрыктәге мөһаҗир татарлар арасында бу эчке тарткалашу тиз генә тынмаган, еллар буенча дәвам итеп килгән. Г.Исхакый һәм аның фикердәшләре 1934 нче ел дәвамында Япониядә «Идел-Урал төрк-татар мәдәният җәмгыятьләре» оештырганнар. Бу атамадагы «мәдәният» сүзен японнар «бәйсез» дигән сүзгә совет тышкы сәяси оешмаларының игътибарын йомшарту нияте белән алмашка тәкъдим иткән булганнар. Төрле шәһәрләрдә мондый комитетлар оештырылуы нәтиҗәсендә Габделхәй Корбангали татар җәмгыятьләре җитәкчелегеннән читләштерелгән.

Габделхәй Корбангали җитәкчелегендәге төркемнең Гаяз Исхакыйга һәм аның тарафдарларына 1934 елның 11 февралендә Токиода яңа оештырылган Идел-Урал Төрк-татарларының мәдәният җәмгыяте идарәсенә сайлау җыелышында хулиганнарча һөҗүме һәм ике каршы якның аннан соңгы тарткалашулары турында галим Ибраһим Нуруллин республикабыздагы соңгы чор матбугатында беренчеләрдән булып язган иде. Ул бу турыда «Токиодагы татар колониясенең лидеры Габделхәй мулла Корбангалиев, мондагы татарларны бүтән җирлектә берләштерүнең аны башлык булу шәрәфеннән мәхрүм итәсен белгәнлектән, үз тирәсенә яраннарын туплап һәм рус эмигрантларыннан кайберләрен ярдәмгә чакырып, Г.Исхакыйның оештыру эшләренә аяк чала башлый. «Япон мөхбире» исемле журналында ул Гаязны һәм аның идеясен хурлый торган материаллар урнаштыра, скандаллар ясап, Исхакый тарафдарларының җыелышларын өзәргә маташа (Поротиков фамилияле бер ак офицер хәтта әдипкә суккан), полиция департаментына донос артыннан донос җибәреп тора...» дип язган иде[28].

---

[27] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 12.
[28] Нуруллин И. Әдип эзләреннән – Төркиядә // Казан утлары. – 1991. – №3. – Б. 144–145.

Корбангали белән бәйле вакыйгалар Берлинда татар телендә нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналының 1934 елгы саннарында бик күп язылган. Мәсәлән, бу журналның шул елгы 5 нче саны тулаем диярлек шул низагларга, аның тамырларына һәм асылына багышланган. Гаяз Исхакый бер мәкаләсендә бу мәсьәлә турында болай дип язган. «...Ерак Шәрыктә безнең 15 меңләп милләттәшләремез – Идел-Ураллылар яшиләр. Боларның бер өлеше сугыштан элек[29] үк бунда сәүдә берлә йирләшкән милләттәшләремез. Бер өлеше – большевик сугышы вакытында җиңелгән рус гаскәре берлә бунда килеп чыккан гаскәри вә цивиль мөһаҗирләр. Әүвәлгеләренең күпчелеге пензалы булса, соңгылары арасында киң илемезнең һәр вилайәтенең угыллары-кызлары катышкан. Болар мөһаҗәрәттә 15 ел бергә үткәргән милли тормышлары вә милли хисләре берлә үзләрен-үзләре русларга кушмыйча йөретергә тырышканнар вә йөретәләр.

Ләкин кайберләре, бик азчылык булса да, тимер юл буйларында руслар арасына төшеп калганнар, рус марҗалары берлә уртак тормыш корганнар. Рус аракысына үгрәнеп китеп, милли тормыштан читкә сугылганнар. Марҗалары, кода-кодагыйлары аркылы бу тарафтагы бик шау-шулы русларның русчылыгы, кара русчылыгы тозагына да эләккәннәр. Русларның монархист фиркаләренә, фашист агымнарына кушылганнар. Шуларның көчләреннән файдаланып, алар исеменнән сүз сөйләргә яратучы Корбангалиевнең бунда булуы, аларның бу мескен тормышларына сәяси буяу да буяган. Корбангалиев: «Без – мөселман руслар, без Русиянең бүленмәвен телимез, падишаһлар заманасындагы кеби булуын телимез» – дип, боларга, үзенә күрә бер агым төсе биреп, аларны рус байрагы астына кушкан. Аларны рус монархист фиркаләренең садыйк бәндәләре итеп русларга кушып, алар арасында үзенә урын тәэмин иткән. Идел-Урал хәрәкәте менә шул мескен, юлдан язганнар арасында русларның вә русчыларның бик тырышып эшләвенә сәбәп булды. Корбангалиев руслар булган һәрбер шәһәрдә шундыйлардан, 4–5 кешелек булса да, групплар ясап, русларга катыштырды. Милли хәрәкәткә каршы чыгаруда бик ямьсез рәвештә башчылык итә алды. Боларның саны бундагы милләттәшләр арасында бер йә ике

[29] Бу урында Беренче Бөтендөнья сугышы күздә тотылган.

процenттан артмаса да, рус гәзитәләре аркылы, Манжу-Кода полисдә хезмәт итә торган рус түрәләре аркылы боларны бер агым итеп күрсәтергә тырышты, әһәмият бирдерергә ижтиһад итте. Манжурлар, японнар, безнең эчке тормышны яхшылап белмәгәнгә, кайбер вак-төяк түрәләр арасында аз-чук муаффәкъ тә булдылар. Хосусан, безнекеләрнең паспортлары русча «ов»ка бетүе аларга зур бер дәлил булып күрсәтелде. Нәтиҗәдә, Ерак Шәрыктәге мөселманнар арасында (алар милли исем – «төрк-татар»ны кулланмыйча, үзләрен «мөселман» дип кенә йөриләр; японнар, манжурларга «без милләт җәһәтеннән – рус, дин ягыннан – мөселман» дип таныталар) русчылык, руслар берлә багланган булу шактый нык дигән тәэсир калдырдылар вә безнең халыкка Ерак Шәрыктә һичбер хөрмәте булмаган «рус» исемене тактырдылар...»[30]

Гаяз Исхакый һәм аның тарафдарлары 1934 елның май аенда Япониянең Кобе шәһәрендә илдәге төрк-татар мөһаҗирләренең гомуми корылтаен уздырганнар. Анда Идел-Урал оешмасының уставы кабул ителгән һәм вакытлы идарә оешмасы – Мәркәз комитет оештырылган. Шуннан соң Г.Исхакый шундый ук максатлар белән Манжуриягә юл тоткан. Андагы төрле шәһәрләрдәге төрк-татар оешмалары да гаять сәясиләшкән булып, үзара каршылыклар эчендә гомер сөргәннәр. Г.Корбангалинең фикердәшләре дә шактый көчле булган.

Гаяз Исхакый 1934 елның икенче яртысында Корея һәм Манжуриядәге төрле калаларда булып, ел ахырында Кытайдагы милли татар оешмаларына барган. Ул бик күп очрашулар уздырган, киңәшмәләр үткәргән һәм чыгышлар ясаган. Ерак Көнчыгыштагы (Япония, Корея, Кытай һәм Манжу-Го дәүләтләрендәге) бөтен төрк-татар мөһаҗирләрен берләштерү өчен Мукден шәһәрендә 1935 елның 4–14 февраль көннәрендә корылтай уздырырга карар кылынган[31].

Исхакый җитәкчелегендәге корылтай үткәреләчәге билгеле булгач, Г.Корбангали Токио мөселман җәмгыяте исеменнән Квантун жандармериясе башлыгына махсус телеграмма белән мөрәҗәгать

---

[30] Исхакый Г. Ерак Шәрык тимер юлы мәсьәләләре // Яңа милли юл. – 1934. – №12. – Б. 5–6.
[31] Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 108–110.

иткән. Ул, 4 февральдә Мукденда ачылырга тиешле Идел-Урал татарлары корылтаеның максаты – Ерак Шәрыктәге мөселманнарны большевиклаштырудан гыйбарәт, дип белдергән[32].

Идел-Уралчыларның 1935 ел корылтаенда 21 кешедән гыйбарәт Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының дини-милли мәркәзе – үзәк идарә оешмасы сайлап куелган. Мукден шәһәрендә урнашкан Мәркәз башкармасының җитәкчесе итеп Гаяз Исхакый сайланган[33].

1938 елның 5 маенда япон хөкүмәтенең Габделхәй Корбангалине кулга алуы мөһаҗирлек матбугатында аның чын йөзен фаш иткән мәкаләләр бастыруга тагын бер этәргеч булган. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналының 6 нчы һәм 7 нче саннарында Гаяз Исхакыйның бу хактагы усал мәкаләләре дөнья күргән. Ул бер мәкаләсендә: «Садәдил японнарга кайбер чакта үзен башкорт принцы, кайберләренә Бөтенрусия мөселманнарының шәйхелисламы [мөфтие – *Р.Ф.*], кайберләренә бөтен Урал тауларының хуҗасы итеп күрсәтүче Габделхәй Корбангали кем иде соң?..» дип, аның милләт өчен китергән зарарларын язган[34].

Ерак Көнчыгыштагы мөһаҗирләр арасындагы Корбангали–Исхакый каршылыклары турында Рөстәм Гайнетдиновның алда әйтелгән хезмәтеннән тыш, матбугатта материаллар шактый басылды[35].

---

[32] Гайнетдинов Р. «...политический акт представителей многомиллионного мусульманского мира...» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1999. – №1/2. – Б. 90.

[33] Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 111–117, 120. Бу Мәркәз 1944 елга кадәр эшләп килгән. 1945 елда Япония капитуляциягә кул куйганнан соң, совет контрразведкасы Идел-Урал оешмасының Ерак Шәрыктәге җитәкчеләрен һәм татар мөһаҗирлегенең исемнәре мәгълүм затларын кулга алган.

[34] Гъ. Хаклык астта калмый // Яңа милли юл. – 1938. – №6. – Б. 19. Гаяз Исхакый мондый сүзләрне, кемнең күздә тотылуын тәгаен әйтмәсә дә, элегрәк тә язган булган (Исхакый Гаяз. Ерак Шәрык // Яңа милли юл. – 1934. – №2. – Б. 6).

[35] Мәсәлән: Ивао К. Татарлар Япониядә // Йөртә безне язмышлар... – Б. 53; Аги Э. Жизнь одного человека... – С. 76; Гаяз Исхакыйның Ерак Көнчыгышка сәфәре: Япония–Токио // Мирас. – 1998. – №2. – Б. 30–37; Гайнетдинов Р. «...политический акт...» – С. 86, 90, 96–100; Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды. – Казан: ун-т нәшр., 2005. – Б. 38–42, 47–50, 87; Рокыя Дәүләт-Килде: бер татар хатынының ачы язмышы. – Казан: ун-т нәшр., 2005. – Б. 20–22; Черникова Л. «Никто не думал вначале, ...что нам придется здесь жить и работать целое десятилетие: Тюрко-мусульманская колония в Шанхае // Гасырлар авазы = Эхо ве-

## Шанхай шәһәрендә яшәгән татарлар

Тын океан тарафындагы Көнчыгыш Кытай диңгезе буена, Кытайның иң зур шәһәре Шанхайга татарлар кайчан һәм ни сәбәпле барып чыкканнар, анда ничек гомер сөргәннәр, кайчан һәм кайларга киткәннәр? Бу сорауларга җавап рәвешендә гомуми бер күзәтү ясап үтик.

Әмрулла Аги язуынча, Шанхай шәһәре ул чорда дөньядагы иң зур шәһәрләрнең берсе булган һәм әллә ничә өлешкә (Кытай, япон, инглиз, американ, француз һ.б.) бүленгән. Бу калада аралашу өчен иң зарур тел – инглиз теле булган[36].

Ул чордагы татар совет матбугатында Кытайның иң бай шәһәрләреннән берсе буларак, әлеге шәһәр бу рәвешчә сыйфатланган: «Шанхай – Кытайда иң зур хуҗалык үзәге санала. Монда 250-гә якын фабрик-заводлар һәм 450000-ләп фабрик эшчесе бар. Шанхай порты бөтен дөньяда беренче дәрәҗә портлардан исәпләнә. Шанхайга меңнәрчә чит ил пароходлары килеп-китеп тора. Бөтен дөньядан монда һәр төрле товарлар һәм исәпсез-хисапсыз байлык агыла...»[37]

Шанхай һәм анда яшәгән милләттәшләребез турында Ә.Кәримуллин болай дип язган иде: «Шанхай – Кытайның күп миллионлы шәһәре, зур диңгез порты. 1842 елгы Нанкин килешүе буенча чит ил сәүдәгәрләре өчен дә ачык шәһәр. Монда, әле дә Англия, АКШ, Франция, Япония һәм башка күп кенә илләрнең сәүдә фирмалары, концессияләре, сеттльментлары урнашкан. Дөнья сәүдәсенең җанлы үзәкләренең берсе. 20 нче еллар башында бирегә татар сәүдәгәрләре дә килеп чыга. Алар монда фирмалар ачып, Сингапур, Вьетнам, Австралия, Океания ярларына да сукмак салалар.

---

ков. – 2005. – №1. – С. 143–144; Исхакый Гаяз. Ерак Көнчыгышка сәфәр // Мирас. – 2006. – №1. – Б. 84–90; Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт.: С.Рәхимов, З.Мөхәммәтшин, А.Заһидуллин. – Казан: Җыен, 2011. – Б. 213, 216–219, 231, 710–721, 731–732, 736–738.

Бу мәсьәләгә караган материаллар Татарстан Милли архивында да бар (Р-2461 ф., 1 тасв., 63а сакл. бер.).

[36] Аги Э. Жизнь одного человека... – С. 91.

[37] Азат хатын. – 1927. – №8. – Б. 1.

Чит ил товарларын Шанхай аркылы Маньчжурия, Кореяга алып барып сәүдә итәләр»[38].

Мәхмүт Таһир татарларның Шанхайга рус гаскәриләре белән бергә 1922 елда килгәнлекләрен язган[39]. Анда татарларның кайберләре фирмаларга эшкә урнашкан, кемнәрдер сәүдә белән шөгыльләнә башлаган. «Ерак Шәрык» газетасында язылганга караганда, Шанхай шәһәрендә татар асламчылары (кырык тартмачылар) 1923 елның җәендә йөри башлаганнар[40].

1933 елның көзендә Шанхайга барган Гаяз Исхакый бу шәһәр һәм андагы мөһаҗирләр турында үзенең күзәтүләрен болай тасвирлаган. «Шанхай шәһәренең берничә зур урамнарыны гиздек. Шәрыкне күрмәгән-белмәгән кешеләргә монда һәрнәрсә яңы, һәрнәрсә Аурупаныкына башка булса да, безгә, Шәрык балаларына, дөньяның өченче дәрәҗәдәге зур шәһәре артык искитәрлек күренмәде. Кытай баласы кайный торган бик зур хәрәкәтле, бик чуар киемле, кырык корамалы биналы, шактый былчырак, бик тар, бик һавасыз, бик сасы урамнар да бик күп. Безнең йөргән йирләребез инглиз һәм француз идарәсендәге мәхәлләләр булса да, аурупалы бунда бик аз. Аурупалы киемнәрдәге кешеләрнең иң күбесе бунда качак ак урыслар, дөньяның төрле почмагыннан җыелган, үзене урыс дип йөрүче яһүдиләр, сабикъ рус тәбәгаләренең саны бунда 30 мең чамасында икән. Бу урыслар бунда француз вә инглизләрдә полис булып хезмәт итәләр, кечкенә түрәләр булып эшлиләр, төрле кытай, аурупалы мәгазәләрендә хезмәтче, сатучылык итәләр, үзләре кибетләр ачып эш күрәләр...

Хәзерге Идел буе татары бунда бары ике йөзләп кенә, болар барсы да большевик революциясеннән соң бунда сыгынганнар, күпчелеге большевикларга каршы корал берлә сугышкан татар гаскәрләре, татар әфисәрләре. Бунда хәзер боларның төрлесе төрле эштә киченеп торалар. Күбрәк өлеше сәүдәгәрләр һәм дә асламчы сәүдәгәрләр. Боларның бик күбесе аркасына күтәргән букча тулы малы берлә Кытайның йөрмәгән йирене калдырмаган. Кытай

---

[38] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 34.
[39] Таһир М. Шанхай шәһәрендәге Төрк-татар җәмийәте // Казан (Истанбул). – 1978. – №22. – Б. 23–24.
[40] Мирас. – 1992. – №11. – Б. 56.

эчендә болар сатмаган бер төрле товар да калмагандыр дисәк, хата булмас. Болар – кызыл малчы, болар – кырык тартмачы, болар – сәгатьче, болар – кайчы, пычак, йозак сатучы, болар – көмешче. Бала-чагаларыны шәһәрдә калдыралар да, эчке Кытай уртасына кереп китәләр вә анда сату итәләр... Аз-маз белгән Кытай сүзләре берлә сату итә бирәләр...

Шанхайның үзендә 80 мең кадәр Кытай мөселманнары бар, боларның үз җамигълары, мәдрәсәләре, зиятлары, вәкыфләре бар. Читтән килгән һиндлы, гарәп, Иран, төрк-татар мөселманнарының да саны берничә мең хисап ителә. Башларында үзләренең җамигъ-лары булган һинд мөселманнары торалар вә, бу читтән килгән мөселманнар бунда – Кытай илендә бер-берсенә тагы якынрак баглаunion налар...»[41]

Шанхай шәһәрендәге төрк-татар мөһаҗирләренең 1920–1930 еллардагы тормышы һәм милли яшәеше тарих фәннәре кандидаты Лариса Черникова мәкаләсендә дә киң тасвирланган[42].

Черникова язуынча, 1920 нче еллар уртасыннан 1940 нчы еллар уртасына кадәр Шанхайда яшәгән төрки-мөселман җәмәгатьчелеге анда ике төрле юл белән барып эләккән. Беренче төркем – Колчак армиясе белән Себер аша чигенеп, акгвардияче дивизияләрнең калдыклары белән 1922 елның ахырында Владивостоктан Корея, Япония һәм Кытайга эмигрант буларак күчкән. Колчак армиясе калдыклары арасында татар-башкорт гаскәри частьләре дә булган. Владивостоктан барлыгы 30 хәрби корабльдә тугыз меңнән артык кеше, котылу эзләп, алда әйтелгән илләргә китеп барган. Берничә портта тукталып торганнан соң, кораллы хәрбиләр белән һәм трюмнары да корал белән шыплап тулган корабльләрнең бер өлеше Шанхайга барып җиткән. Төрк-татарларның икенче төркеме Төркестандагы басмачылык хәрәкәте тар-мар ителгәннән соң качып килүчеләрдән торган.

Рус корабльләре портка килеп туктагач, Шанхай шәһәре хакимияте флотилия башлыгы генерал Ф.Л.Глебовка, кораллыларга да һәм гади гражданнарга да шәһәргә төшү тыелуын, 24 сәгать эчендә Шанхай портыннан китәргә тиешлекләрен белдергән. Нәтиҗәдә,

[41] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 14–16.
[42] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 138–144.

качаклар төялгән Россия корабльләре Шанхай портында дустанә булмаган шартларда өч ел су өстендә рейдта торган. Азык-төлек, ягулык һәм эчәргә яраклы су беткән, үлүчеләр саны арткannан-арта барган. Исәннәре исә билгесезлеккә һәм тулы өметсезлеккә дучар булган. Генерал Глебов яшерен рәвештә берничә корабль һәм кораллар сатып кына, качакларның хәлен бераз җиңеләйтүгә ирешкән. Шулай ук Шанхайдагы халыкара хәйрия оешмалары да, хәл кадәренчә ярдәм күрсәткәннәр. Мөһаҗирләр аз-азлап рәсми һәм рәсми булмаган рәвештә корабльләрдән төшеп, шәһәрдә урнаша башлаганнар. Качакларга озак айлар, хәтта еллар дәвамында чит тел һәм ят мәдәният мохитенә яраклашырга, эш эзләргә туры килгән. Күпчелеге зыялы һәм белемле катламны тәшкил иткән эмигрантларга тамак хакына авыр хезмәткә ризалашу аеруча читен булган[43].

Ул вакытта Кытайның үзендә гражданнар сугышы барган. Шанхайда ул чорда француз һәм япон гаскәрләреннән тыш, инглиз-американ гаскәрләре дә булган. 1927 елда Кытай революцион гаскәрләре Шанхай каласына якынлашып, чит ил гаскәрләренә куркыныч янагач, ак эмигрант генералы Ф.Глебов үзенең кораллы гаскәрләре белән ярдәмгә килгән. Шуннан соң Шанхайдагы Россия мөһаҗирләренә мөнәсәбәт уңайланган[44].

Россия мөһаҗирләренең күпчелеге Шанхай шәһәренең француз колониаль гаскәрләре хакимлек иткән өлешендә яшәгән. Матди хәлләре бик кыен булганнары шәһәрнең Кытай өлешендә төпләнергә мәҗбүр булган. Аның читендә мәчет булып, ул тирәдә төрле мөселман илләреннән килгән кешеләр торган. Качаклар башта бик фәкыйрь тормыш чиккәннәр. Авыру һәм ялгыз картлар ачтан үлмәс өчен Шанхай урамнары буйлап хәер сорашып йөрергә мәҗбүр булган. Кайберләре шулай йөреп югалганнар[45].

Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларын үткән хәрбиләр, сәүдәгәрлек һәм эшкуарлык сәләтенә ия кешеләр тора-бара Шанхайда үзләренә эш һәм кәсеп тапканнар.

---

[43] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 139.
[44] Шунда ук. – Б. 140.
[45] Л.Черникова мәкаләсендә 60 яшьлек бер татар кешесенең 1934 елның 3 мартында хәбәрсез югалу вакыйгасы язылган (Б. 139–140).

Шанхайдагы төрк-татарлар үз балаларына ана телен укыту һәм дин нигезләрен өйрәтү өчен мәктәп ачканнар. Ә калган фәннәрне, башка мөһаҗир балалары белән берлектә, чит ил мәктәпләрендә укыганнар[46].

1937 елда, Кытайга япон агрессиясе башлангач, Харбинда яшәгән татарларның бер өлеше Шанхай шәһәренә күченгән. Чөнки Манжу-Го марионет дәүләте җитәкчеләре СССРга каршы сугышу өчен мөһаҗир яшьләр арасыннан армиягә мобилизация үткәрергә ниятләгәннәр.

Черникова Шанхайдагы татарлар турында язганда рус телендә нәшер ителгән «Шанхайская заря» газетасының 1934–1935 еллардагы төрле саннарына таянган. Ул сылтама биргән мәкаләләр арасында әлеге газетада басылган «Колония тюрко-татар хотя и малочисленна, но крепка. Община отмечает непрерывный рост колонии» (1935, 12 апрель), «Отъезд артистов тюрко-татар» (1935, 23 март) исемнәрендәге мәкаләләр дә күрсәтелгән.

Ул чорда Шанхайда яшәгән татарларның статусы турында Ә.Кәримуллин болай дип язды. «Шанхайдагы «Идел-Урал» комитеты эшчәнлеге нәтиҗәсендә биредәге япон, инглиз, немец, американ концессияләре һәм Кытай хөкүмәте татарларны аерым халык буларак таныйлар. Моңа да биредәге урыс эмигрантларының ачуы килә. Ул гына түгел, Шанхайдагы «Идел-Урал» комитеты урнашкан йорт өстендә милли татар байрагы җилфердәп тора. Биредә Идел-татар җәмгыяте булачак азат Татарстанның илчелеге формасында таныла башлый, төрле концессияләр һәм Кытай хөкүмәте органнары белән элемтә тоту да җиңеләебрәк китә. Бу комитет тиздән Төркиянең Кытайдагы илчелеге һәм Шанхайдагы консуллыгы белән дә элемтә урнаштыра»[47]. Бу хәлне Әмрулла Аги китабындагы бер эпизод та куәтли. Ә.Аги сәүдә эшләре буенча С.И.Палей дигән юлдашы (элекке җитәкчесе) белән Чаньчун шәһәреннән Шанхайга баруларын тасвирлаган. Алар Шанхай шәһәренең икенче өлешенә керү өчен япон жандармериясенең тикшерү пункты аша үтәргә тиеш булалар. Шунда Ә.Аги үзенең Идел-Урал төрк-татар милли җәмгыятенең секретаре булуын белдергән визиткасын

[46] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 141.
[47] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 57–58.

күрсәткәч, аны тиз генә үткәреп җибәргәннәр. Ә юлдашы уза алмыйча калган. Эшләрен башкарып килеп, яңадан очрашкач, Палей Агидән нинди документ күрсәткәнлеген сораган. Әмрулла үзенең булачак бөек Идел-Урал дәүләтенең гражданины икәнлеген әйтеп биргән[48].

Шанхайда яшәгән төрк-татарларның санына килгәндә, Равил Салиәхмәтнең Шанхайда «1920 нче елларда берничә татар ак гаскәриләрдән башка кеше ияләшмәгән иде. Гаилә рәвешендә Харбиннан килү 1928 елларда башланды... Шанхайда, заманында, иң күп дигәндә 100-дән артык татар яшәмәде» дип язган сүзләре[49] дөреслеккә туры килеп бетми. Чөнки башка чыганакта, Мәдияр хәзрәт Шәмгунинең «1921/22 нче елларда Шанхайга барып, мөһаҗир төрк-татар мөселманнары арасында мәхәллә имамы булып яши»[50], дип язылган мәгълүмат хәлнең бүтәнчә торганлыгын дәлилли. Ягъни, «мәхәллә имамы булып яши» дигән сүзләр 1920 нче еллар башында Шанхайдагы татарларның берничә кеше яисә санаулы гына гаилә булмаганлыгын белдереп тора. 1920 нче еллар башында, анда М.Шәмгуни килгәндә, дистәләгән татарлар яшәгән дип фаразларга мөмкин.

Мәхмүт Таһир язуына караганда, 1925–1928 нче еллар арасында Шанхайда илледән алып бер йөзгә кадәр милләттәшебез яшәгән[51].

Гаяз Исхакый 1933 елның октябрь башында Шанхайда Идел буе татарларының ике йөзләп булганлыгын язган[52].

Л.Черникова язуына караганда, 1935 елда Шанхай төрк-татар җәмгыятендәге әгъзаларның саны 120 тирәсе ир-егет булган. Бу санга нигезләнеп, мәкалә авторы Шанхайдагы төрк-татарларның гомуми исәбе якынча 400–450 кешене тәшкил иткәндер, ә гомумән андагы Россия эмигрантлары төрле елларда 20–50 меңләп кеше булган дип яза[53].

---

[48] Аги Э. Жизнь одного человека... – С. 90.
[49] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 74.
[50] Мәдияр хәзрәт Шәмгунинең тәрҗемәи хәле // Яңа милли юл. – 1939. – №8/9. – Б. 13.
[51] Таһир М. Шанхай шәһәрендәге... – Б. 23.
[52] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 15.
[53] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 140.

Черникова саннары, бәлки, арттырыбрак күрсәтелгәндер. Чөнки аннан соңгы 1940 нчы елларда Шанхайда яшәгән татарлар 200 кеше булган дип язучылар бар[54].

Шанхай шәһәрендә яшәгән татарлар, сәяси вакыйгалар аркасында, 1940 нчы еллар уртасыннан читкә китәргә мәҗбүр булганнар. Мәхмүт Таһир татарларның 1945 елда күчеп китә башлауларын һәм 1950 елдан соң Шанхайда татарлар калмаганлыгын язган[55]. Төркиядә яшәүче милләттәшебез, галим Надир Дәүләт ул турыда болай дип яза: «1945 елда Америка һава көчләре японнарны тезләндерү максаты белән Шанхай тирәсенә бомбалар төшерә башладылар һәм соңында японнар җиңелде. Хакимият кытайлар кулына күчте. International Refugee Organization (Халыкара Эмигрантлар оешмасы) Кытайдан китәргә теләүчеләргә ярдәм күрсәтә башлады. Шул рәвешле татарларның монда яшәү чорлары да төгәлләнде»[56]. Шанхайда яшәгән рус эмигрантларының бер өлеше Советлар Союзына кайтарылган. Калганнары белән бергә татарлар да башта Филиппинга, аннан Төркиягә, Австралиягә һәм Америкага киткәннәр.

Равил Салиәхмәт Шанхайдагы татарларның күбесе 1948 елда Төркиягә киткәнлеген язган[57].

Бу уңайдан Ә.Кәримуллин тарафыннан Шанхайдагы татарларның 1950 нче елларда гына читкә китүләре турында язган сүзләрнең[58] дөреслеккә туры килмәвен искәртергә тиешбез.

Хәзерге вакытта Шанхай шәһәрендә даими яшәүче татарлар булуы безгә билгесез.

## Шанхайдагы татар җәмгыятьләре

Мәхмүт Таһир Шанхайдагы татар җәмгыятьләре турында, Шаһвәли Келәүледән алган мәгълүматларга нигезләнеп, кыскача

[54] Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды... – Б. 77; Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция в Северо-Восточной Азии... – С. 100.
[55] Таһир М. Шанхай шәһәрендәге... – Б. 23–24.
[56] Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды... – Б. 34–35.
[57] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 75.
[58] Шунда ук. – Б. 34–35.

язма бастырган[59]. Ул язганга караганда, Шанхай шәһәрендә 1925 елда Мәдияр мулла Шәмгуни җитәкчелегендә бер җәмгыять төзелгән. Аның 50–60 әгъзасы булып, кайбер елларда 100-гә хәтле җиткән. Бу җәмгыять арендага алынган бинада урнашкан. Шанхай татар җәмгыятенең максаты авыр көн күрүче кардәшләргә ярдәм итү, эшсезләрне эш белән тәэмин итү, дини йолаларны үтәүдән гыйбарәт булган. Татарлар җомга намазларына һәм дини бәйрәмнәргә пакьстанлылар мәчетенә йөргәннәр. Җәмгыять бинасында китапханә оештырылган. Балаларга сабак укытылган.

Мәхмүт Таһир мәкаләсендә булган кайбер төгәлсезлекләрне искәртеп үтәбез. Мәсәлән, Мәдинә Салиәхмәтнең Шанхайдагы татар балаларын 1935 елда укыта башлавы турында язылган сүзләр ялгыш. Чөнки М.Салиәхмәт Шанхайга баргач та (1933 елда) укыту эшенә керешкән. Һәрхәлдә, ул 1934 елда укытучы булган[60]. Шулай ук бу мәкаләдә Шанхайдагы татар җәмгыятен 1936 елда Кәшшаф Салиәхмәт җитәкләве турындагы мәгълүмат та дөреслеккә туры килми. Ягъни, ул елларда Шанхайда төрк-татарларның ике җәмгыяте булганлыгы аерып әйтелмәгән. Өстәвенә, берсенә – Мәдәният җәмгыяте буларак исем алганына, К.Салиәхмәт 1934 елда җитәкчелек итә башлаган.

Мәхмүт Таһирның Шанхай җәмгыяте белән К.Салиәхмәт идарә итә башлагач, андагы татарлар тормышының җанлануы, милли мәдәнияткә зур әһәмият бирелүе, милли кичәләр оештырылуы, спектакльләр уйнала башлавы һәм концертлар куелуы турындагы сүзләре игътибарга лаек.

Мәкаләдә язылганга караганда, Мәдияр мулла Япониягә киткәннән соң, Шанхайда имамлык вазыйфаларын озак еллар Әүхәди Җамалетдин башкарган. Анда вафат булган татарларны Кытай мөселманнары зиратына җирләгәннәр.

«Милли байрак» газетасының 1939 ел 1 сентябрь санында элегрәк төшелгән кызыклы күмәк фоторәсем басылып чыккан. 21 ир-ат төшкән ул фотоның астында «1925 елда Шанхайда мәрхүм Мәдияр хәзрәт Шәмгуни җитәкчелегендә төзелгән беренче Төрк-

---

[59] Таһир М. Шанхай шәһәрендәге... – Б. 23–24.
[60] Бу җыентыктагы №14 протокол.

татар оешмасының әгъзалары мәрхүм хәзрәт белән бергә» дип язылган.

Шанхайдагы татар мөһаҗирләре тормышы турында соңрак язган авторлар, Мәхмүт Таһир мәкаләсендә язылган мәгълүматларны нигез итеп алып, шул исәптән андагы кайбер төгәлсезлекләрне дә кабатладылар.

Надир Дәүләт Ерак Шәрыктәге мөһаҗирлек тарихына багышланган китабында, М.Таһир мәкаләсенә таянып, «Шанхай төрек-татарларның дини һәм милли җәмгыяте» турында язып чыкты[61]. Ул язганга караганда, Шәмгуни тарафыннан 1925 елда оештырылган җәмгыять «Мөселман мөһаҗирләре җәмгыяте» дип аталган[62].

Мәдияр мулла Япониядәге Кобе шәһәренә 1928 елда киткән[63]. Ул киткәннән соң Шанхайдагы татар җәмгыяте үзгәртелеп яңача оештырылган булса кирәк. Чөнки Н.Дәүләт бу оешманы «уңышка ирешмәде һәм 1928 елда «Шанхай төрек-татарларның дини-милли җәмгыяте» оештырылды» дип язды[64].

Лариса Черникова да бу җәмгыятьнең 1928 елда оештырылган булуын яза. Аның язуынча, аз санлы кешеләр катнашында үткәрелгән беренче гомуми җыелышта җәмгыять идарәсенең рәисе итеп И.Акбирдин сайланган. Ул 1931 елда Америка Кушма Штатларына киткәннән соң, идарә рәисе итеп Ибраһим Мамлиев сайлап куелган. Бу җәмгыятьнең төп максаты – фәкыйрь хәлдәге төрк-татарларга ярдәм итүдән гыйбарәт булган. Андыйларга паспорт алырга, эшкә һәм фатирга урнашырга, бушлай туклану талоннары алырга булышканнар. Авылларга йөреп сәүдә итәргә теләүчеләргә җәмгыять кредитка товарлар алып бирергә ярдәмләшкән[65].

Идел-Урал бәйсезлек хәрәкәте юлбашчысы Гаяз Исхакыйның Ерак Көнчыгыштагы төрле илләрдә һәм төрле шәһәрләрдә яшәгән мөһаҗир төрк-татарларны берләштерү максаты белән 1933–1936 елларда ул якларга сәфәре Шанхай шәһәреннән башланган һәм

---

[61] Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды... – Б. 34–35.

[62] Шул ук автор бер мәкаләсендә бу җәмгыять турында «...Мәдияр Шәмгуни җитәкчелегендә дини-милли җәмгыять төзелә» дип язган иде (Казан утлары. – 2000. – №2. – Б. 151).

[63] Яңа милли юл. – 1939. – №8/9. – Б. 14.

[64] Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды... – Б. 34.

[65] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 140.

шул ук калада тәмамланган. Ягъни, ул 1933 елның 2 октябрендә Шанхай шәһәрендә пароходтан төшкәндә аны шунда яшәгән татарлар каршы алганнар. Исхакый Шанхайдагы мөһаҗир татарларның тормышы, көнкүреше һәм җәмгыятьләре белән якыннан танышкан. Бу юлы ул Шанхай шәһәрендә унбер көн торган. Ике ел ярым дәвамында Ерак Шәрыктәге милли-мәдәни тормышны үзгәртеп, рухландырып һәм яңа агымга кую максатында армый-талмый, искиткеч күп эшләр башкарганнан соң, яңадан Европага киткәндә дә Г.Исхакыйның соңгы тукталышы Шанхайда булган. Ул бу юлы анда, 1936 елның 4 мартында килеп, өч көн торган һәм 7 мартта пароход белән Европага киткән. Милләт юлбашчысын Шанхайдагы татарлар озатып калганнар.

Гаяз Исхакый 1933 елда Шанхай шәһәренә төшкәндә аның белән бер үк пароходта җәмәгать һәм дин эшлеклесе Габдеррәшит Ибраһимов (1857–1944) та булган. Исхакый үзенең Шанхайга килүе турында һәм андагы татарлар тормышына багышлап 1934 елда зур мәкалә бастырган[66]. Ул мәкаләсендә «Шанхай төрк-татар мөһаҗирләре мине күптән көтәләр икән» дип, аларның газеталардан белеп, Европадан килгән һәр пароходны каршы алганлыкларын бәян иткән. Гаяз Исхакый сүзен дәвам итеп, «Хәтта берсе белән килеп чыгуым мөхәкъкак дип ышанганга, август аенда киләчәк Италия вапурының килүенә бер банкет та хәзерләгән булганнар вә, мин вапурда булынмагач, үзара гына мәҗлесләрене уздырганнар» дип язган.

Исхакыйның Италиядәге Триест портыннан пассажир судносында 1933 елның җәендә сәфәргә чыгачагы Шанхайга һәм Мукденга хәбәр ителеп тә, вакытында барып җитмәве Ерак Көнчыгыштагы татарлар арасында хәвеф тудырган булган. Бу хакта галимнәр язган иде[67]. Ибраһим Нуруллин бу турыда «Шанхайда ул пароходны каршыларга барсалар, Гаяз юк. Булганмы ул анда, әллә кайдадыр төшеп калганмы – моңа экипаж да, белмибез, дип җавап биргән» дип, Исхакыйның совет агентлары тарафыннан юк ителгән

[66] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 12–17.
[67] Нуруллин И. Әдип эзләреннән – Төркиядә... – Б. 144; Гайнетдинов Р. Тюрко-татарская политическая эмиграция... – С. 107.




Шанхай шәһәрендәге татар мөһаҗирләре мәҗлесе. 1933 ел.
*(Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды. – Казан: ун-т нәшр., 2005).*

булуын фаразлап хәвефкә төшкәнлекләрен язды. Гаяз Исхакый анда бүтән пароход белән соңрак барып җиткән.

Исхакый үзенең 1933 елның 2 октябрендә Шанхайда пароходтан төшкәнлеген язып, таможня аша үткәннән соңгы хәлләрне түбәндәгечә тасвирлаган. «Чыгарга ишек төбенә килдем, анда «Гаяз абзый! Хуш килдегез!» дигән тавышны ишеттем. Бу – мәрхүм Харбин имамы Гыйнәят әфәнденең энесе Кәшшаф әфәнде иде. Аның янындагы бер егет тә сәлам бирде. Ишектән чыгып өлгерә алмадым, икесе дә килеп күрештеләр. Танымаганым Уфаның Фазлыйәхмәт Мамлиевнең угылы Ибраһим әфәнде икән, ул бу тарафларга чигенгән татар гаскәре берлә әфисәр булып килгән дә, Ерак Шәрыкнең төрле тарафында булынып, хәзер Шанхайда йирләшкән

икән. Күрешеп, янымда Рәшид әфәнденең дә булуыны сөйләп, аны табып алыр өчен мин тагы эчкә кереп киттем... алып чыгып күрештереп, шәһәргә таба киттек. Мин Шанхайда беренче мәртәбә. Каршы алучылар безне «Империал» отеленә китереп төшерделәр. 24 көн юлчылыктан соң аягыбызны исән-сау корыга басканга без бик сөенгән булганга, бу шатлыкны тутыра төшәр өчен чәй сорадым. Чәйдән соң шәһәрне карарга киттек, берничә һәмшәһри берлә кибетләрдә, урамда күрештек...

Кич берлә сәгать 8-ләрдә кичке ашка безне бундагы төрк-татар колониясенең күп еллар рәисе булган Сөнгать Дүзи әфәнде алып китә. Анда без чын мәгънәсендә бер татар гаиләсе эченә килеп керәбез. Безне киң итеп тегелгән итәкле күлмәкле, йон яулыклы карт абызтай, Казанның соңгы мода киемендә яшь ханым каршы алалар, берничә бала да килеп безнең берлә татарча итеп күрешәләр... Тагы илдәш берничә мөсафир килә, без чәйгә тотынабыз, үзебез сөйлибез, үзебез ашыйбыз... Без Аурупадагы мөһаҗирләребезнең хәлене аңлатабыз, алар безгә бундагы, Шанхай тирәсендәге, төрк-татарларның ни эшләүләрене сөйлиләр, ничек дөнья кичерүләрене аңлаталар...

Идел буе татарлары монда үзене чит хис итми, Шанхай шәһәрендә бу мөһаҗирләр үзләренә «Милли идарә» төзегәннәр. Биш кешенең эш башлавы берлә корылган бу җәмгыятьнең хәзер 150 кадәр әгъзасы бар. Үзенең, кечкенә генә булса да, бүлмәсе бар, үзенең көтепханәсе бар. Ул Идел буеның милли бәйрәмнәрене бергәләп эшли, аның милли кайгыларыны җәмгыять төсендә катышып кайгырта. 1933 нче ел Тукай вафатының 20 еллыгыны бик зур тантана берлә үткәргәннәр. Мәүлүд кичәсен, бәйрәм көннәрен илдәге кеби бәйрәм ясаганнар. Хәзер болар даими музыка, театр түгәрәге ясарга тырышып йөриләр. Боларның бу җәмгыятьләре дини вазыйфаларны үтәп килә. Араларыннан берсе имамлык вазыйфасыны кыла, үлем-җитем булганда, үзләре җеназа укып, үзләре җуып, үзләре бундагы Кытай мөселманнары зиярятында дәфен итәләр. Ләкин җомга намазларына, бәйрәм намазларына Шанхайдагы Һиндстан мөселманнарының җамигысына баралар...

«Милли идарә» безнең хөрмәтебезгә мәҗлес ясый вә бездән төрле йирләргә таралган халкыбызның хәле берлә таныштыруны

үтенә. Без дә вазыйфаларны бүлешеп алып, Рәшид әфәнде ислам дөньясы берлә таныштыра, мин төрк дөньясы хакында гомуми бер мәгълүмат биреп, үзебезнең Идел буе мөһаҗирлеге хакында озак туктыйм. Безнең сөйләгәннәребез халыкның дәртене ачса да, сусавыны бетерерлек булмаганга, тагы бер мәртәбә мәҗлес ясарга сорыйлар, вә мин дә тагы бер мәртәбә сөйләргә сүз бирәм. Икенче мәҗлесебез дә бик тирән хиссият эчендә үтә. Халык чит илләргә таралган кардәшләренең хәлене бик зур дикъкать берлә тыңлый, үзенең милли юлының кая таба булырга тиешлеге хакындагы фикерләрне бик сөенеп каршы ала. Бунда Идел-Урал истикъляль фикере бик күп эшләгән, халкыбызның күпчелеге чит илләрдә йөреп үзенең илене бик сагынган, үзенең халкыны башка халыкларга чагыштырып, татарның көчлелегенә, булдыклылыгына иманы бик зурайган. Һәммәсе дә: «Хәлебез бик авыр булса да, сөяк сындырып йөрүчебез бер данә дә юк. Урысның кенәзләре, графлары хәер сораша. Аллага шөкер, халкыбызның йөзенә кара китерерлек эш эшләмибез», – диләр. Шул сөемле сүзләрне ишетеп, сөйкемле илдәшләрдән аерылып, икенче шәһәрләрдәге халкыбызны карарга тагы юлга чыгам»[68].

Гаяз Исхакыйның бу мәкаләсе ахырында «Шанхай, 12 октябрь» дип язылган. Ул 13 октябрьдә пароход белән Япониягә юл тоткан. Ә юлдашы Габдеррәшит Ибраһимов Шанхайда озак калмыйча, сәфәрен алданрак дәвам итеп, 12 октябрьдә инде Япониянең Токио шәһәренә барып җиткән[69].

Черникова язуынча, Шанхайга Манҗуриядән, Владивостоктан һәм башка урыннардан мөселман яшьләре килә башлагач, төрк-татар җәмгыяте каршында мәдәни-агарту түгәрәге оештырылган[70]. Әлеге Яшьләр түгәрәген оештыру мәсьәләсе 1933 елның урталарында башланган булса кирәк. Чөнки Г.Исхакыйның шул елда октябрь ае башында Шанхайга килгәч «Хәзер болар даими музыка,

[68] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 12–17.

[69] Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз. М.Госманов, Ф.Галимуллин. – Казан: Җыен, 2011. – Б. 39.

[70] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 141.

театр түгәрәге ясарга тырышып йөриләр»[71] дип язган сүзләреннән шулай аңлашыла.

«Шанхай төрк-татар яшьләр оешмасы» 1933 елның 17 декабрендә төзелүе, аның рәисе Кәшшаф Әхмәди булганлыгы һәм бу оешманың гомуми җыелыш үткәреп, ярты ел эчендә башкарган эшләренә хисап тотканлыгы турында матбугатта махсус язма басылып чыккан[72]. Шул ук җыелышта Шаһвәли Keләүле тарафыннан Шанхай Яшьләр оешмасын «Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте»нә әйләндерергә кирәк дигән тәкъдим кертелгән.

Шанхай Төрк-татарларының милли һәм дини оешмасының бер тармагы буларак эш башлаган Яшьләр түгәрәге нигезендә 1934 елның сентябрендә оешкан Шанхай Төрк-татарларының мәдәният җәмгыятенең эшчәнлеге Л.Черникова мәкаләсендә уңай яктыртылган. (Тик мәкалә авторы баштагы Яшьләр оешмасы белән мөстәкыйль Мәдәният җәмгыятен бер үк оешма буларак тасвирлаган). Ул Кәшшаф Әхмәди җитәкчелегендә мәдәни кичәләр, концертлар һәм спектакльләрнең еш оештырылганлыгын һәм мондый чараларның Шанхайдагы татар мөһаҗирләрен туплау өчен зур роль уйнаган булуын яза. Ул, шулай ук, К.Әхмәдинең берничә пьеса һәм повестьлар иҗат иткәнлеген һәм газеталарга (рус газеталары күздә тотыла – *Р.М.*) төрк-татар мәдәнияте эшлекләләре турында еш язып торганлыгын искәртә. К.Әхмәдинең актив ярдәмчеләре булган талантлы артистлар Keләүле һәм Арсланбәк хор белән җитәкчелек иткәннәр, поэмалар язганнар, сәхнә әсәрләрен куйганнар һәм үзләре дә шунда катнашканнар[73].

***

Алда язып үтелгән, Ерак Шәрыктәге татарлар арасындагы фикер каршылыклары Шанхай шәһәрендә яшәгән татарлар тормышына да тәэсир иткән. Гаяз Исхакый Шанхай татарларын үз тарафына җәлеп итү өчен 1934 елның апрель аенда Япониядәге Кобе шәһәре

---

[71] Гаяз. Шанхай // Яңа милли юл. – 1934. – №1. – Б. 16.
[72] Идел-Уралчы. Ерак Шәрыктән // Яңа милли юл. – 1934. – №10. – Б. 26.
[73] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 141.

имамы Габдрахман Кәримовны[74] махсус җибәргән. Ләкин Г.Корбангали Шанхайдагы татар җәмгыяте рәисе Ибраһим Мамлиевкә[75] хат юллап, Габдрахман Кәримовның Иж-Бубый авылында имамлык вазыйфасыннан куылган кеше булуын, большевикларга мөнәсәбәте барлыгын һәм Г.Исхакый тарафдары икәнлеген белдергән. Шул сәбәпле, Г.Кәримов Шанхайга килгәч, И.Мамлиев аны дошман кебек кабул иткән. Ә Шанхай татарлары җәмгыятенең элекке рәисе Дүзиев[76] белән Яшьләр оешмасы җитәкчесе Кәшшаф Салиәхмәт Г.Кәримовка уңай мөнәсәбәт күрсәткәннәр. Шул сәбәпле, Мамлиев белән Дүзиев кайнар бәхәсләргә кергәннәр. Мамлиев полициягә Дүзиев төркеменең совет оешмасы булуы турында һәм «алар белән совет паспортына ия Кәшшаф Салиәхмәт җитәкчелек итә» дип хәбәр иткән. Бу хәлдән соң К.Салиәхмәтне татар җәмгыяте әгъзалыгыннан чыгарганнар[77].

Шанхай җәмгыяте рәисе И.Мамлиевкә 1934 елның 7 маенда Гаяз Исхакыйның Кобе шәһәрендә корылтай уздырачагын хәбәр итеп, Габделхәй Корбангали протест белдерергә киңәш биргән. Шуннан соң Шанхай җәмгыяте Токиога, чит илләр эшләре министрына Кобеда булачак корылтайның хәвефле гамәл икәнлеген искәртеп телеграмма юллаган[78].

Шулай итеп, Шанхайдагы татарлар ике өлешкә бүленгән. Анда электән эшләп килгән «Шанхай төрк-татарларының милли вә дини оешмасы» (соңрак: «Шанхай төрк-татарлар дини вә милли идарәсе», аны кыскача «Милли идарә» дип кенә дә йөрткәннәр) Г.Корбангали тарафын якласа, бу җәмгыятьтән чыгарылган К.Әхмәди 1934 елның сентябрендә оештырган Мәдәният җәмгыяте баштан ук

---

[74] Габдрахман Бәдретдин улы Кәримов (Кәрим) – Вятка губернасының Сарапул өязе Әгерҗе волостендәге (хәзерге Татарстанның Әгерҗе районындагы) Иж-Бубый авылында туган. 1909 елның августында имам-хатыйплык шәһадәтнамәсе алган. 1916 елның гыйнвар аенда туган авылы мәчетенә икенче имам итеп расланган булса да, озак тормыйча, вазыйфасыннан чыгарылган.

[75] Л.Черникованың алда күрсәтелгән мәкаләсендә И.Мамлиев турында тулырак мәгълүмат бар.

[76] Документта Дүзиевнең исеме күрсәтелмәгән булса да, аның Сөнәгать (Сөнгатулла) Дүзи булганлыгы аңлашыла. (Бу җыентыктагы №№9, 10 протоколларга карагыз).

[77] Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык... – Б. 716–717.

[78] Шунда ук. – Б. 717.

Гаяз Исхакый фикерләрен яклаган. Шанхай татарлары арасындагы бу каршылыкның кайчагында көчәеп, ә кайвакытта бераз сүрелгән хәлдә дәвам иткәнлеге Мәдәният җәмгыятенең җыелыш беркетмәләреннән дә күренә.

Әлеге мәсьәләне тулырак күзаллау өчен кыскача тасвирлап китәбез. Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең 1934 ел 18 октябрьдә булган җыелышында «Япон мөхбире» журналында язылган ялган хәбәрне халыкка аңлатырга кирәклеге турындагы сүзләрдә Г.Исхакыйның максатларын хурлап язган мәкалә күздә тотылган. Шул ук җыелыш беркетмәсендә Казан алыну мөнәсәбәте белән 1934 елның 14 октябрендә үткәрелгән матәм мәҗлесендә Шанхай Милли идарәсеннән бер вәкил дә катнашмаган булуы да фикри каршылыкның ачык мисалы.

1934 елның 17 ноябрь җыелышында каралган мәсьәләләрдән аңлашылуынча, Шанхай Милли идарәсе Мәдәният җәмгыятенә, үзенә буйсына торган оешма итеп карап, күрсәтмәләр биргән булган. Мәдәният җәмгыяте, моңа җавап хатында үзенең мөстәкыйль оешма булганлыгын белдергән. Шуннан соң Кәшшаф Әхмәди 1934 елның 15 декабрендә Милли идарә җыелышына чакырылган. Милли идарәнең рәисе Әүхәди Җамал аның Мәдәният җәмгыятеннән китүен таләп иткән. Ызгыш-талаш чыккан. Бу хәлдән соң Милли идарә мәктәбендә балалар укыткан Мәдинә Салиәхмәт укытуын дәвам итмәячәген белдергән. Шуңа күрә Мәдәният җәмгыяте дин һәм татар теле дәресләре өчен аерым курслар оештырырга карар иткән.

Мәдәният җәмгыятенең Ата-аналар комитеты һәм Милли идарә белән берлектәге 1934 елның 18 декабрь җыелышы мәктәп мәсьәләсендә уртак фикергә килә алмаган. Мәдәният җәмгыяте, балаларны укудан мәхрүм итмәс өчен, мәктәпне үз карамагына алырга карар кылган.

Шанхайдагы ике оешма арасындагы низаглар мәсьәләсе Мәдәният җәмгыятенең 1935 елгы 12 гыйнвар җыелышында да каралган. Мәсьәлә һаман да куера барып, 1935 елның 4 февралендә Мукден шәһәрендә Идел-Урал төрк-татарларының Ерак Шәрык корылтае ачылганда, анда Шанхай Мәдәният җәмгыятеннән вәкил итеп җибәрелгән Кәшшаф Әхмәдине кертмәскә дип, 28 имза белән

Шанхай Милли идарәсе телеграмма җибәргән. Тик К.Әхмәди барыбер корылтай эшендә катнашкан. Аннан тыш корылтайда Шанхай Төрк-татар дини-милли идарәсе вәкиле Рәхмәтулла Фәтхулла да катнашкан.

Гаяз Исхакый үз чыгышларында үзара каршылыкларны ничек тә бетереп, берләшергә өндәп килгән. Берләшү омтылышлары Шанхайда да ясап каралган. Мәсәлән, Мәдәният җәмгыятенең 1935 елгы 5 июнь утырышында Милли идарә белән Мәдәният җәмгыяте арасында үзара аңлашу өчен киңәш мәҗлесе эшләү турында сүз кузгатылган. Шул ук елның 1 июль җыелышында да берләшү мәсьәләсе каралган.

1935 елның 26 июль көнендә Шанхай Милли идарәсендәге (җыелыш беркетмәсендә алар «корбангаличеләр» дип аталган) гомуми җыелышта бер төркем төрк-татарлар бу оешмага ризасызлык белдереп, үзләрен «мохтариятчеләр» дип, җыелышны ташлап, әгъзалыктан чыкканнар. Алар киләчәктә Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте белән милләт өчен бергәләп эшләүне тәкъдим иткәннәр[79]. Мәдәният җәмгыяте «мохтариятчеләр» белән вакытлыча уртак комитет (Шанхай шәһәрендәге төрк-татарларның милли берләшмәсен оештыру буенча инициатив төркем) төзегәннәр[80].

Милли идарә белән araларны көйләү максатындагы чаралар күрү Мәдәният җәмгыятенең 1935 елгы 4 ноябрь җыелышында тагын тикшерелгән.

Шул елның 17 декабре утырышында Мәдәният җәмгыяте рәисе К.Әхмәди Ерак Шәрыктәге төрк-татарларның Г.Исхакый җитәкчелегендәге Идел-Урал хәрәкәтенең асыл максатларын һәм Г.Корбангали кебек хыянәтчеләрнең гамәлләре турында башка халыкларга аңлату өчен рус телендә бер брошюра бастыру фикерен күтәргән.

Гаяз Исхакый 1936 елның март ае башында Ерак Көнчыгыштан Европага китеп барышлый Шанхайда тукталган. Ул Ерак Шәрыктәге татар мөһаҗирләренең фикер каршылыклары уңаеннан борчылуларын белдереп һәм берләшергә кирәклекне кайгыртып язган, «Хаталарыбыздан гыйбрәт алырга тиешбез» дип аталган мә-

[79] №43 протокол.
[80] №44 протокол.

каләсен Шанхайдагы төрк-татарлар мисалында тасвирлап биргән[81]. Мәкаләсендә ул болай дип язган. «Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татарларының соңгы мәртәбә күргәнем Шанхай мәхәлләсендә өч кенә көн кала алдым. Өч көндә, бер яктан, Корбан бәйрәмнәре тугры килеп, бәйрәмгә баглы әллә никадәр зиярәте, тәбриге, күрешү белән туп-тулы булганга, икенче яктан, китү мөнәсәбәте белән туган билет, виза, рәсми саубуллашу кебек, бик күп формальностьлар белән башны катырырга мәҗбүр ителгәнгә, өченче яктан, хасталыгым һәрбер сәгатьтә, һәрбер минут үзен хәтерләтеп, бөтен хәрәкәтемә, эшләремә хуҗа булып, кулны-аякны баглап торганга, Шанхайның шәһәрен генә түгел, үз мәхәлләбезне дә рәтләп күрә алмадым». Исхакый мондагы татарлар арасындагы каршылыкларның милләт дошманнары тарафыннан ясалма рәвештә куертылуына игътибар юнәлтеп, алда әйтелгән сәбәпләр аркасында бу мәсьәләне җентекләп тикшерергә мөмкинлек таба алмавын белдергән. Ул Шанхайдагы кайбер нәрсәләрнең күпертелгән булуын әйтеп, килештерү юнәлешендә тырышканын яза, үзара аңлашылмаучылыкның сәбәпләрен ачып бирә. «Шанхайда милләтчеләр арасында бүленү, зур аңлашылмау куәтле дип барабан сугылып йөртелгән сүзләр йөзгә туксаны дошманнар тарафыннан махсус күпертелеп, зыянчылык нияте белән эшләнгәне, янына килеп җиткәч, ап-ачык күренде. Кара-каршы китерелгәч, икегә бүленгән кебек күрсәтелә килә торган милләтчеләрнең бер-берсенә каршы әсастә һичбер аермалары юклыгы, хәттыль-хәрәкәләрендә генә аз-маз караш башкалыгы барлыгы мәгълүм булды, вә искесе кебек милли хәрәкәттә берлекне саклап алып бару вә милләтчелекнең ике канаты кебек күренгән милли көчләребезне бер милли максатка, бер милли гаййәгә хезмәт иттерү вә арадагы аңлашылмауларны тирәнәйтмәү хакында фикерләр берләште. Вә ике милләтче гөруһ та бер җан, бер тән булып милли-дини эшләребезне бергәләп алып барышырга вә арага дошманның былчырак тырнагын тыктырмаска сүз биреште. Ерак Шәрыкнең бөтен самими милләтчеләрен борчый торган Шанхайдагы аңлашылмауларның төп сәбәпләре бетерелде вә, һәрбер милләтчене сөендереп, үзеннән-үзе бетерелде. Ләкин монда – Шанхайда чыккан бу аңлашылмаулар Ерак Шәрыкнең башка

[81] Милли байрак. – 1936. – 27 март.

йирләрендә чыгу ихтималы булганга, моның төбен-тамырын күздән кичерү зарар булачак түгелдер.

Иң әүвәл шуны кыйммәт итәргә кирәк ки, Шанхайдагы Милли идарә белән Идел-Урал Мәдәният җәмгыяте арасында күренгән бу аңлашылмаулар милли эшләргә карашның икелегеннән чыккан нәрсә түгелдер. Ике групп та – йөзгә-йөз милләтчедер. Ике групп та үзләренең милләтләренә хезмәт итәргә теләүләрендә самимидер. Ике групп та хаиннәргә каршы нәфрәт белән тулыдыр. Вә һичбер алар белән якынлашу уе-фикере берсенең дә башына кергән юктыр. Аерма булса, хәттыль-хәрәкәдә генәдер. Милли идарә, киң халык катлавы белән эш итәргә мәҗбүр булганга вә эшләре Шанхай мохитенә мөнхасыйр кебек калганга, руслы, французлы Шанхайның хосусиятенә дикъкатьне артыграк җәлеп итәргә мәҗбүрдер. Идел-Урал Мәдәният җәмгыяте, үзен бөтен Идел-Урал җәмгыятьләре белән баглы итеп хис иткәнгә, үзен киң төрк дөньясы белән баглы дип уйлаганга, Шанхайның кайбер кысынкы хосусиятләреннән үзен өстен дә тотарга, кайбер хәрәкәтләрендә үзен хөррәк хис итәргә мәҗбүрдер. Вә боларның икесе дә хәяттан килеп чыкканга вә Ерак Шәрыктәге милли барлыгыбыз өчен икесе дә кирәкле булганга, бу ике хәттыль-хәрәкәне урыны-урыны белән алып бару кирәкледер. Икесен дә милли барлыгыбыз, милли үзлегебез өчен хезмәт иттерергә тиешледер. Читтән караганда бер-берсенә башка төсле күренгән бу хәттыль-хәрәкәнең нигезендә башкалык юкка болар арасында антагонизм-аңлашылмау чыгармаска тырышу – шөгурле милләтченең милли бурычыдыр...

Ник кечкенә генә аермалар Шанхай милләтчеләре арасында шулкадәр уңайсызлыклар тудырган? Шанхайда булган бу эшләребезнең сәбәпләре башка мәхәлләләребез, оешмаларыбыз өчен дә уртак булган бундагы пәрдәне бераз ачу зарарлы булмас дип уйлыйм.

Буның берничә сәбәбе бар. Кайберләре үзебезнең эчке тормышыбыздан чыккан, кайберләре үзебезнең читтә яшәвебездән килеп чыккан, читләрнең тәэсире белән туган сәбәпләрдер. Идарәләребездә сөйләнә торган, идарәбездә хәл ителергә тиеш булган бик күп мәсьәләләребез, гомумән, бездә үзенең фикере үтмәгәннәр тарафыннан урамга чыгарыладыр. Урамда аңлар-аңламас әгъзалар

арасында пропаганда эшләтеп, идарәгә тәзайык эшләнелергә тырышыладыр. Вә, нәтиҗәдә, идарәнең карары, үзенең кыйммәтен, хөрмәтен азайтып, бөтен идарә тарафыннан кабул ителгән төсен югалтып, идарә әгъзасы фәлән әфәнденең фикере кыяфәтен аладыр. Җәмгыятьнең әгъзалары арасында аның милли мәҗбүрияте, кыйммәте югала да, бунын нәтиҗәсендә, идарәнең һәрбер карарын үзе яратмаган һәркем тәнкыйть итәргә, «буйсынмаска хакым бар» дип уйлап, җәмгыятьнең җәмгыятьлеге бетереләдер. Оешып, бергәләп милли эшне алып баруның нигезе җимереләдер. Шанхайда бу сөэ истигъмаль башка мәхәлләләребезгә караганда, бәлки, күбрәк булгандыр вә шул гайре табигыйлек Шанхайның милли-дини эшләренең табигый юлыннан баруына зур киртә булып килгәндер.

Тышкы көчләрнең тәэсире белән булган уңайсызлыклар – баягы безгә мәгълүм провокаторның чыгарган һәрбер милли-дини эшебезне русларга сөйләү вә арабызда милли-дини сахәдә чыккан моназарәләрдә русларны хаким итеп төшенеп, хәлне сорап мөрәҗәгать итү вә шәхси мәнфәгать өчен мохалифләр өстеннән ялган донослар яудыруны кирәк дип уйлаудадыр. Корбангалиев тарафыннан Токиода татбикъ ителә башланган бу былчырак метод бара-тора киң Ерак Шәрыккә җәелеп киткән вә, шул провокаторларның коткысы арасында Шанхайга кадәр килеп җитеп, бунда да бик киң рәвештә татбикъ ителгәндер. Шанхайда хаким булган французлар, инглизләр, кытайларга үзең яратмаган һәрбер кешене кызыл итеп донос ясау кыйммәте бунда бик аз булса да, шул эшкә русларны катыштырып эшләнелгән. Бундый мәгънәсез ялган доносларның Шанхайда да милли эшләргә, милләтче эшчеләргә каршы да зарары юк түгелдер. Бу метод та Шанхайдан бик тулы көенчә милли хаиннәрнең аңсыз бәндәләре ашасыннан эшләнеп килгәндер вә милли хәрәкәтебезнең хөрмәтенә зур зарар иткәндер.

Провокаторларның Шанхайда татбикъ иткән өченче юллары тагы да зур зарар китергәннәр. Ул да – милләтчеләр сафыннан торган булып, милләтче төсенә бөркәнеп йөртелгән зыянчылык хәрәкәтедер. Гомум корылтайдан соң бик киң рәвештә татбикъка керешкән бу методка Шанхай милләтчеләренең ике гөруһы да корбан ителгәндер. Вә ике гөруһ та, бу зыянчыларның ачык максатларын

вакытында аңлап өлгермәенчә, бик зур зарар-зыянга уграганнардыр. Матур күбәләк төсенә кереп, аннан-моннан милләтчеләр арасында оча торган, кеше алдында милләтче булып кылана торган, зәһәр йоткан бу милли көяләрдән Шанхай милләтчелеге акрын-акрын гына үзенең милли берлеген, үзенең хезмәтчеләренең бер-берсенә каршы хөрмәтен, милли эштә туа торган дустлыгын тишек-тошык иттерткәндер. Милли сафның берлеген шул мәлгунь көянең зәһәрле теше астыннан иләк кебек хәлгә куйдыргандыр, үзенең бергәләп эш итүенең зәминен авырлаткандыр. Бу зыянчы провокаторларның Шанхайда татбикъ иткән методлары башка мәхәлләләребез, башка җәмгыятьләребез өчен дә гайни рәвештә татбикъ итәргә маташып килгәнгә, гомум Ерак Шәрык милләтчеләре боңарга зур дикъкать итәргә тиештер. Вә арабызга матур күбәләк булып, тәмле сүз, якты йөз белән керергә теләгән шул зәһәрле хаиннәрдән сак булырга тиештер. Вә аларның төрле матур сүзләрен тыңлаганда, асыл максатлары ни икәнлеген онытмаска тиештер.

Шанхай милләтчеләре хәзер үзләренең эчләреннән чыккан хаталарын, дошманнарыбыз тарафыннан эчебезгә кертелгән бәлаләрдән милләтче сафыны пакьләү белән мәшгуль булырга мәҗбүрдер. Вә, иншаллаһ, шуны эшли дә алырлар... Тышкы провокаторларны коралсызландырган кебек, эчтән хәрәкәт итә торган зыянчыларны да коралсызландырсак, Ерак Шәрыктә зур тәһликәдән котылган булабыз вә милли эшебезне сәламәтлек юлына чыгарган булабыз. Шанхай милләтчеләренә бик күп баш ватарга, кан бозарга сәбәп булган вә бөтен милләтчеләрне бик көендергән бу хаталарыбызны соң булса да аңлавыбыз, милләтебез юлында иткән тәҗрибәләребез булып, башкаларыбызга шундый хата юллардан сакланырга гыйбрәт булачактыр... Шанхайдагы аңлашылмаулар, килешүләрнең менә мәгънәсе шул. Шанхай эшләреннән көткән өмидебез дә менә шул»[82].

Бу мәкаләнең ахырында күрсәтелгәнгә караганда, Гаяз Исхакый аны Шанхайдан китеп барышлый, 9 март көнне пароходта язган.

[82] Исхакый Гаяз. Хаталарыбыздан гыйбрәт алырга тиешбез // Милли байрак. – 1936. – 27 март.

Мөһаҗирлектәге милләттәшләребезнең эчке низагларының сәбәпләрен Мәдинә Салиәхмәт тә «Гаяз әфәндене Аурупага озату» исемле мәкаләсендә образлы һәм төгәл итеп аңлаткан[83].

Шанхай Мәдәният җәмгыятенең 1936 елның 8 июлендә булачак гомуми җыелышына каршы фикердәге кешеләрне кертмәү турындагы карардан Шанхай татарлары арасындагы эчке тарткалашуның һаман да дәвам иткәнлеге аңлашыла.

***

Төрле чыганаклардан күренүенчә, Шанхайдагы төрк-татар мөһаҗирләренең иң әүвәлге җәмгыяте мулла Мәдияр Шәмгуни тарафыннан 1925 елда оештырылып, аның рәислегендә 1928 елга кадәр эшләп килгән. 1928 елдан элеккесе урынына яңа җәмгыять – «Шанхай төрк-татарларының дини һәм милли идарәсе» (исеме үзгәргәләп торган булса кирәк) оештырылган. Милли идарәне 1930 нчы елларда И.Мамлиев җитәкчелек иткәнлеге алда әйтелгән иде. Шулай ук бер ара Сөнәгать Дүзи, аннан соң Әүхәди Җамалетдин (1934–1938 елларда һәм, бәлки, аннан соң да) рәислек иткәнлеген әйтә алабыз.

Милли идарә карамагында 1933 елның 17 декабрендә «Шанхай Төрк-татар яшьләр оешмасы» эшли башлаган. Ул ярты елдан артык – 1934 елның җәй урталарына хәтле дәвам иткән. Бу оешма нигезендә 1934 елның 7 сентябрендә яңа бер җәмгыять – «Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте» оештырылган. Анысының рәисе Кәшшаф Әхмәди булган.

Шанхайдагы менә бу ике җәмгыять бер чорда параллель рәвештә, кайчагында каршылыклар белән, ә еш кына үзара аңлашып, милли-мәдәни, иҗтимагый һәм дини эшчәнлек алып барганнар.

Шанхай шәһәрендәге ике җәмгыять тә 1945 елга кадәр мөстәкыйль рәвештә эшләп килгәннәр булса кирәк. Мәдәният җәмгыятенең 1934–1936 еллардагы җыелыш беркетмәләре һәм татар мөһаҗирлек матбугатында аннан соңгы елларда басылып чыккан мәкаләләр һәм язмалар шулай булганын раслый. Алар, Икенче бөтендөнья сугышы вакыйгаларына бәйле рәвештә, 1945 елда мәҗбүри ябылганнар.

[83] Яңа милли юл. – 1936. – №5. – Б. 22–23.

Шанхайдагы татарлар тормышы турында язган галимнәрдән Мәхмүт Таһир, Әбрар Кәримуллин, Надир Дәүләт, Лариса Черникова һәм Лариса Усманова хезмәтләрендә Шанхай шәһәрендә милләттәшләребезнең бер үк чорда ике җәмгыяте эшләгән булуы аерып күрсәтелмәгән.

## Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең эшчәнлеге

Мәдәният җәмгыяте турында мәгълүматыбыз күбрәк булганлыктан, аның тарихын һәм башкарган гамәлләрен аерым тасвирлыйбыз.

1934 елның апрелендә Шанхайдагы дини һәм милли идарәдә булып үткән низаглар нәтиҗәсендә Яшьләр оешмасы җитәкчесе Кәшшаф Әхмәдинең җәмгыять әгъзалыгыннан чыгарылганлыгы турында алда язып үткән идек. Шул елның май аенда Кобе шәһәрендә төрк-татар мөһаҗирләренең корылтае уздырылып, Ерак Көнчыгыштагы милләттәшләрнең төрле шәһәрләрдәге җәмгыятьләрен Идел-Урал идеясе нигезендә берләштерү максаты куелган. Бу уңайдан 1934 елның җәендә Шанхайда «Идел-Урал» җәмгыятен оештыру өчен төрк-татарларның гомуми җыелышларын үткәрү омтылышы булган. Тик ул чакта, үзара каршылыклар аркасында, мәсьәлә хәл ителмичә калган[84]. Шанхай Милли идарәсенең әгъзасы Сөнәгать Дүзи, ниндидер хатка нигезләнеп, халыкка мондый оешма төзүнең кирәге юк дип котырткан[85]. Нәтиҗәдә, Шанхайда Идел-Урал исеме астындагы җәмгыять оештырылмыйча калган. Менә шундый шартларда 1934 елның 7 сентябрендә «Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте» оештырылган. Әлеге җәмгыять аңарчы эшләп килгән «Шанхай төрк-татарларының дини һәм милли идарәсе» карамагындагы Төрк-татар яшьләр оешмасы нигезендә оештырылган. Бу 1 нче санлы беркетмәдәге «Шанхай төрк-татар яшьләренең мал-милке һәм көтепханәсе Яшьләр оешмасы беткәч сакланыр өчен махсус бер һәйәткә вакытлыча тапшырылган иде.

[84] №9, 10 протоколлар.
[85] Бу очракта, күрәсең, Г.Корбангалинең Габдрахман Кәримов турындагы, алда әйтелгән, хаты күздә тотылгандыр.

Хәзер, Мәдәният җәмгыяте төзелү белән, мал-милек һәм көтепханә Мәдәният җәмгыятенә күчкәнгә...» дигән карардан аңлашыла. Ә Шанхай төрк-татар яшьләре оешмасы Милли идарәнең тармагы булса да, мөстәкыйль эшләп килгән. Яшьләр оешмасы төзелгәнче Милли идарә тарафыннан кичәләр һәм лекцияләр үткәрелмәгән булган[86].

Равил Салиәхмәтнең «Шанхайда татар җәмгыяте» исемле мәкаләсен галим Әбрар Кәримуллин бастырып чыгарган иде[87]. Тик анда кайбер төгәлсезлекләр бар. Шанхайдагы Мәдәният җәмгыятенең оештырылу вакытын Равил Салиәхмәт 1934 елның «5 сентябре» дип ялгыш билгеләгән. Җәмгыять идарәсенең бу җыентыкта басыла торган җыелыш беркетмәләре дәфтәренә ул өстәп язган мәгълүматта да «5 Sintiabr 1934...» дигән сүзләр аның 1 нче санлы беркетмәнең датасындагы гарәп саны белән язылган 7 сентябрьне рим цифрындагы V кебек үк язылышы белән бутаган дип кенә аңлатырга мөмкин. Югыйсә, җәмгыятьне оештырган кешеләр үзләре «Шанхайда яшәүче төрк-татарлар 7 нче сентябрьдә булган гомуми җыелышларында Шанхай төрк-татар Мәдәни җәмгыятене тәэсис иттеләр» дип язганнар[88].

Шанхай Мәдәният җәмгыятенең низамнамәсендәге һәм идарә җыелышлары беркетмәләрендәге исемендә «Идел-Урал» атамасы язылмаган. Җәмгыятьнең исемендә моның язылмау сәбәбе, күрәсең, 1934 елның җәендә Шанхайда «Идел-Урал» исемендәге җәмгыять төзәргә тырышып та, уртак фикер табылмаганлыкка бәйле булгандыр. Әмма Мәдәният җәмгыятенең башлангычы булган «Шанхай Төрк-татар яшьләр оешмасы»ның 1934 ел 30 июньдә булган гомуми җыелышындагы карарда бу ачык әйтелгән. Ягъни, «...Шаһвәли әфәнде тарафыннан башка шәһәрләрдә Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте төзелгәне шикелле, Шанхай Яшьләр оешмасын да «Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте»нә әйләндерү тәклиф ителде. Бу фикергә бер кем дә каршы килмичә, 6 кешедән

---

[86] №11 протокол.
[87] Сәлихмәт Равил. Шанхайда татар җәмгыяте // Шәһри Казан. – 1992. – 17 декабрь; Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 74–76.
[88] Яңа милли юл. – 1934. – №12. – Б. 25.

мөрәккәб бер һәйәт сайланып, тизлектә «Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте»не вөҗүдкә чыгарырга карар кылынды» диелгән[89].

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең исемендә күрсәтелмәсә дә, аның низамнамәсендә «Идел-Урал» бәйсезлек фикеренә кушылып, шул юлны тотканлыгы берничә мәртәбә язылган. Шулай ук бу мәсьәлә җыелыш беркетмәләрендә Гаяз Исхакый идеяләренә тугрылык, Ерак Шәрыктәге Идел-Урал Мәркәзенә булышу турында язылганнар белән дә исбатлана. Җәмгыять идарәсенең 1934 ел 22 сентябрь җыелышында оешма мөһерен ясатып, аның уртасына Идел-Урал символын куйдырту турындагы сүз белән дә раслана. Бу җәмгыять тарафыннан 1936 елның апрелендә М.Колосовага җавап итеп язылган «Наш ответ» текстының ахырында эре хәрефләр белән «Комитет Идель-Урала Тюрко-татар гор. Шанхая» дип язылган. Мәдәният җәмгыятенең атамасына, бу исем соңрак бәлки кертелгәндер дә, чөнки «Милли байрак» газетасында басылган мәкаләләрдә Шанхай Мәдәният җәмгыяте «Идел-Урал җәмгыяте» яки «Идел-Урал комитеты» буларак телгә алынган.

Эчке каршылыклар дәвам иткән, Мәдәният җәмгыяте әгъзасы булган С.Дүзи 1934 елның ноябрь аенда Идел-Урал хәрәкәте фикерләренә таянып эш йөрткән Төрк-татар мәдәният җәмгыятен ябып, «Идел-Урал» җәмгыяте төзергә кирәк дигән коткы салган[90]. Ул Шанхай Мәдәният җәмгыяте Г.Исхакый юлын тотмый дигән ялган сүзләрне башка шәһәрләрдәге татар мөһаҗирләренә дә хәбәр иткән булган. Дүзинең җәнҗаллы гамәлләре Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең 9–13 нче җыелыш беркетмәләрендә язылган.

Мәдәният җәмгыяте идарәсенең беренче җыелышында бу оешма үзенең юнәлешен, «бөек юлбашчыбыз» дип атап, Гаяз Исхакый тарафдары булуын белдергән. Бу турыда җәмгыятьнең рәисе Кәшшаф Әхмәди махсус чыгыш ясаган. Җыелыш карары белән Г.Исхакый, шулай ук төрки халыкларның якты киләчәге өчен көрәшүчеләрдән азәрбәйҗанлы Мөхәммәд Әмин бәк Рәсүлзадә, кырымлы Сәед Әхмәд Җәгъфәр (1889–1960), төркестанлы Мостафа Чукай

---

[89] Идел-Уралчы. Ерак Шәрыктән // Яңа милли юл. – 1934. – №10. – Б. 26.
[90] №9 протокол.

улы Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең мактаулы әгъзалары итеп, бертавыштан сайланганнар.

Бу җәмгыять, Исхакый идеяләрен яклавын белдереп, Габделхәй Корбангали тарафдарларына каршы булуын тәгаенләп куйган. Корбангали үзе һәм Шанхайдагы аның яклы фикердәге Милли идарә җәмгыяте кайчагында Мәдәният җәмгыяте беркетмәләрендә «корбангаличеләр» дип тә телгә алынганнар[91]. 41 нче санлы беркетмәдә язылганга караганда, Милли идарә тарафындагылар Мәдәният җәмгыятенә карата «исерек коммунистлар» дигән мыскыллау гыйбарәләре дә кулланган. Ләкин Мәдәният җәмгыяте Шанхайдагы милләттәшләр өчен үткәрергә ниятләгән зур чаралар турында калада электән үк яшәп килгән Милли идарәгә белдереп барган. Эчке низаглар булуга карамастан, кичәләр һәм бәйрәмнәр еш кына бергәләп үткәрелгән.

1934 елда Мәдәният җәмгыяте Милли идарә бинасында урнашкан булган һәм Р.Салиәхмәт язганнардан 1941 елга хәтле шунда калган дип аңлашыла. Ул шулай ук 1942 нче еллардан, җәмгыятьнең матди ягы бераз яхшыра төшкәч, аерым бүлмә арендаланган булуын яза[92].

Бу җыентыкта басыла торган документаль чыганак – Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсе җыелышлары беркетмәләренең (документта «протокол» дип язылган) беренчесе 1934 елның 7 сентябрендә язылган. Бу дәфтәргә теркәлгән соңгы җыелыш – 72 нче номерлы беркетмә 1936 елның 8 июленә карый.

Дәфтәргә теркәлгәннәрне елларга бүлеп караганда, җәмгыять идарәсенең 1934 елда барлыгы уналты мәртәбә, 1935 елда кырык тапкыр һәм 1936 елда уналты мәртәбә узган җыелышларының беркетмәләре язылган.

Җыелыш беркетмәләреннән күренгәнчә, Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсе әгъзаларыннан Кәшшаф Әхмәди, Мәдинә Салиәхмәт, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа Габдрахмани, Шаһвәли Keләүле, Мансур Арсланбәк, Гайниҗамал Ильясия утырышларда даими катнашканнар.

---

[91] №8, 25, 41, 43, 56 протоколлар.

[92] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 75.



Шанхай төрк-татар Мәдәният җәмгыятенең идарә әгъзалары.
Алда (*сулдан-уңга*): Мәдинә Салиәхмәт, Гайниҗамал Ильяс, Кәшшаф Әхмәди, Латыйфа Габдрахман; артта: Кадыйр Габдрахман, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк. Шанхай. 1936 ел.
*(Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2007. – №2. – Б. 182).*

Болардан Шаһвәли Келәүле Илдар (1900–1970) – Россиядә туган, Кытайдагы төрле шәһәрләрдә яшәгән шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул 1940 елда Тяньцзинь шәһәрендә чыга башлаган, Әхмәтвәли Мәңгәр нәшер иткән «Шәрык авазы» исемле татарча журналның редакторы булган[93]. Ш.Келәүле 1949 елдан Төркиядә яшәгән һәм шунда вафат булган. Мөһаҗирлектәге татар матбугатында: «Милли байрак» газетасында (1935–1945), «Яңа милли юл» (1928–1939) һәм «Казан» (1970–1980) журналларында актив язышкан.

[93] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 48, 57.

Надир Дәүләт 1970 елда «Казан» журналында Шаһвәли Келәүленең тормышы һәм иҗаты турында язып, аның ике шигырен бастырган[94]. Мәкалә авторы Ш.Келәүленең Габдессәлам (хәзерге Башкортстандагы Әпсәләм) авылында дөньяга килеп, авыр бала чак уздырып, Дәүләкәндәге бер кибеттә сатучы булып эшләвен, 1918 елда аклар гаскәренә алынганлыгын язган. Н.Дәүләт Келәүленең гаскәр сафында Хабаровскига хәтле чигенеп, анда яралануын, Шанхайга барып эләгүен һәм күпчелек әсәрләрен шунда вакытында иҗат итүен тасвирлаган. Мәкаләдә язылганнарга караганда, 1935 елда Ш.Келәүле белән Мансур Арсланбәк «Милли байрак» газетасында эшләргә Мукден шәһәренә чакырылганнар. Келәүле анда озак тормыйча, яңадан Шанхайга кайткан. Ул еш уздырылган милли кичәләр өчен кыска комедияләр язган. Шаһвәли Келәүле 1948 елда Шанхайдан Филиппин утрауларына, аннан 1949 елда Төркиягә – Истанбул шәһәренә киткән[95]. Надир Дәүләт соңрак Ш.Келәүле турында «Казан утлары» журналында да мәкалә бастырды[96]. Анда ул Келәүленең картлык көннәре аеруча кыенлыкта узганлыгын яза.

Бу шәхес турында галим Фәрит Хәкимҗанов болай дип язган иде: «Шаһвәли Илдәр 30 нчы елларда Шанхайда яшәгәндә әдәбият белән кызыксына башлый. 1934-40 елларда Кәшшаф Салиәхмәт җитәкләгән Мәдәният җәмгыятендә активрак катнаша башлагач, поэзиягә булган омтылыш аның сәүдәгәрлек һөнәрен дә бер читкәрәк этәрә башлый. Ул хәтта, Мукденга килеп, бер ел[97] «Милли байрак» газетасы редакциясендә дә эшләп китә. Татар җәмгыятьләренең күбесенә хас бер нәрсә бар – анда ай саен диярлек сәхнә әсәрләре куела. Пьесаларга кытлык булгач, артистлар үзләре әсәрләр язалар һәм үзләре үк аны сәхнәләштерәләр. Шаһвәли әфәнде дә кыска комедияләр иҗат итә, режиссер була. Ул язган шигырьләрнең барысы да диярлек милләт язмышына, татар тормы-

---

[94] Дәүләт Н. Шаһвәли (Рияноглу Кләүли) Илдәр // Казан. – 1970. – №1. – Б. 19–21.
[95] Шунда ук. – Б. 21.
[96] Дәүләт Н. Шагыйрь Шаһвәли Келәүли иҗаты // Казан утлары. – 2000. – №2. – Б. 147–153.
[97] Мәкалә авторының «бер ел» дип язуы дөреслеккә туры килми.

шына багышланган булып, ватанны сагыну хисе белән сугарылганнар»[98].

Шанхай Мәдәният җәмгыяте идарәсенең актив әгъзаларыннан берсе, педагог һәм журналист – Мансур Арсланбәк (1915 – 1978) турында галимә Лена Гайнанова: «Мансур Арсланбәк Ерак Шәрыктә, Мукденда Гаяз Исхакый нигезләгән «Милли байрак» гәзитендә хезмәт иткән. Гәзиттә аның мәкаләләре, шигырьләре дә басыла», – дип язды. Лена ханым М.Арсланбәкнең гаилә әгъзалары белән бергә 1976 елда төшкән фотосын да бастырып чыгарды[99]. М.Арсланбәкнең 1936 елда «Милли байрак» газетасы редакциясендә Гаяз Исхакый һәм бүтән милләттәшләребез белән бергә төшкән фоторәсемен исә Лена Гайнанова матбугатта элегрәк бастырган иде[100]. Рокыя Дәүләткилде «Милли байрак» газетасында бергә эшләгән вакытларын искә алып, М.Арсланбәк турында җылы хатирәләр язган[101].

***

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең беренче җыелышында ук җәмгыятьнең уставын (низамнамәсен) язып, русчага һәм французчага тәрҗемә итү каралган. Француз теленә тәрҗемә ителүнең сәбәбе – Шанхайдагы татарларның бу шәһәрнең французлар карамагындагы өлешендә яшәгәнлегенә бәйле. (Бу турыда алда әйтелгән иде). 1934 елның 22 сентябрендәге җыелышта Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең кулланмасын әзерләп, рәсми рәвештә теркәтү мәсьәләсе турында сүз булган. Җыелыш беркетмәсендәге «кулланма» дигән сүз астында, күрәсең, җәмгыятьнең уставы һәм бүтән төрле зарур документлар күздә тотылгандыр. Кулланманы русчага, инглизчәгә һәм французчага да тәрҗемә итү турында карар чыгарылган.

---

[98] Хәкимҗанов Ф. Анадолу җирендә // Йөртә безне язмышлар...: фәнни-популяр очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б. 145–146.
[99] «Әтиемне Советлар Берлегендә укыганнар икән» // Мәдәни җомга. – 2011. – 12 август.
[100] Исхакый Гаяз. Әсәрләр: 15 томда. 5 том: Хикәяләр, повестьлар, пьесалар (1920–1947) / төз. Л.Гайнанова. – Казан, 2009. – Фоторәсемнәр кушымтасы.
[101] Рокыя Дәүләт-Килде: бер татар хатынының... – Б. 25–26.

Шанхай Мәдәният җәмгыятенең алдына куйган максатлары шактый киң булган. Җәмгыять үз эшләренең барышын белдереп, Г.Исхакый Берлинда нәшер иткән «Яңа милли юл» журналына һәм Кытайның Мукден шәһәрендә чыккан «Милли байрак» газетасына язып тору башта К.Әхмәдигә йөкләнгән. Тик 1934 елның 11 октябрь җыелышында аның урынына бу эшне башкарырга Шакир Баязитов сайланган. Җәмгыять шулай ук мөһаҗирлектә чыккан азәрбәйҗан, кырымтатар, төркестан газета-журналларын да таратуны үз өстенә алган. Шанхайда төрк-татар телендә, бер көнлек булса да, газета чыгару максаты куелган. Шулар белән беррәттән, төрки-татарларның мөстәкыйльлек фикерен чит милләтләргә аңлату өчен Шанхайдагы рус газеталарына ай саен язып тору күздә тотылган[102].

Шанхайда яшәгән төрк-татарлар арасында татар һәм башка төрки халыклар тарихы, милли хәрәкәт, татар әдәбияты, татар теле, татар музыкасы, татар театры, мәшһүр милләтпәрвәр татарлар турында лекцияләр оештыру ниятләнгән. Милли бәйрәмнәр уздыру, газеталардагы төрк-татарлар турындагы материалларга күзәтүләр ясап бару, укый-яза белмәүчелекне бетерү, латин әлифбасын өйрәнү һәм башка максатлар куелган[103]. Шулай ук милли музыка курслары ачып, бушлай өйрәтү каралган[104]. Элекке Шанхай төрк-татар яшьләр оешмасыннан калган Габдулла Тукай исемендәге китапханә Мәдәният җәмгыятенә кабул итеп алынып, аны атнага ике мәртәбә: җомга һәм якшәмбе көннәрдә ачу, ә кыйраәтханәне (уку залын) көн саен ачу карар ителгән. 1935 елның 4 ноябрь җыелышында китапханәне Мәдәният җәмгыятенә тапшыру турында сүз булган.

Шанхай Мәдәният җәмгыяте Ерак Көнчыгышта Кытай, Корея һәм Япониянең төрле шәһәрләрендәге төрк-татар милли оешмалары һәм җәмгыятьләре белән элемтәдә торган. Җәмгыять үзенең эш планын һәм идарәгә сайланган әгъзалар турындагы мәгълүматларны мөһаҗирлектә нәшер ителгән татар һәм башка төрки телләрдәге газета-журналларга, Мукден, Харбин, Токио, Кобе, Кумамото,

[102] №2 протокол.
[103] №2 протокол.
[104] №3 протокол.

Нагоя шәһәрләрендәге Идел-Урал мәдәният җәмгыятьләренә җибәргән[105].

22 сентябрь җыелышында идарә утырышларын һәр атнаның шимбә көннәрендә үткәрү билгеләнгән. Бу кагыйдә, нигездә үтәлсә дә, төрле сәбәпләр аркасында, тотрыклы сакланмаган. Ягъни, кайбер очракларда идарә җыелышлары икешәр көн рәттән узса[106], ике атнага бер мәртәбә[107], хәтта 21 көн өзеклектән соң[108], бер ай[109] һәм ике айга якын[110] өзеклек белән үткәрелгәннәре дә булган.

Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышларында каралган мәсьәләләр күп төрле һәм күпьяклы. Җыелышларда иң аз дигәндә – бер, иң күбе – сигез мәсьәлә каралган.

Җәмгыятьнең төрле игъланнарын һәм башка язма эшләрен кулдан язып күбәйтү читен булганлыктан, 1934 елның 3 октябрендәге җыелышта гектограф юнәтергә кирәклеге турында фикер әйтелгән.

Мәдәният җәмгыятенең матди ягын көчәйтү өчен татарча газета чыгару мәсьәләсе 1934 елның 9 ноябрь җыелышында аерым каралган. Анда төрле фирмаларның игъланнарын бастырып, табыш хасил итү күздә тотылган. Газетада басылачак мәкаләләрдә төрки дөньядагы вакыйгалар, Габделхәй Корбангалигә бәйле хәлләр, Шанхай Мәдәният җәмгыятенең максаты һәм аның башкарган эшләре турында язу, шулай ук Шанхайдагы авторларның әсәрләрен бастыру ниятләнгән. Газетаны бастыру чараларын күрү К.Әхмәди белән идарә әгъзасы Кадыйр Габдрахманга тапшырылган[111]. Газетаны Нанкин шәһәрендә бастыру уңайлырак булмасмы дигән фикер дә күтәрелгән. Тик анда бастыру кыйммәтрәк һәм читен булганга, Шанхайда бастырырга кирәклеге ачыкланган. Милли идарә белән ике арада чыккан низаглар аркасында, 16 декабрь утырышында газета мәсьәләсен хәл итү кичектерелгән.

Газета чыгару мәсьәләсе яңадан 1935 елның 26 сентябрь җыелышында күтәрелгән. Чыгачак газетага 3 октябрь җыелышында «Мат-

[105] №3 протокол.
[106] №8, 9, 43, 44, 49, 50 протоколлар.
[107] №6, 7, 39, 40 протоколлар.
[108] №58 һәм 59 протоколлар.
[109] №71 һәм 72 протоколлар.
[110] №44 һәм 45 протоколлар.
[111] №9 протокол.

бугат хәбәрләре», «Мәдәният чаткысы», «Яшьләр авазы», «Ерак Шәрык тавышы» дигән төрле исемнәр тәкъдим ителгән. Тик уртак фикер табылмаган. Газета өчен лозунг буларак Гаяз Исхакый, Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), Йосыф Акчура (1876–1935) кебек күренекле затларның канатлы сүзләре тәкъдим ителгән. Идарәнең 10 октябрьдә узган җыелышында газетага «Берлек» дигән, вәзгыятенә күрә бик уңышлы исем расланган. Аның бер саны 1935 елның 15 октябрендә – Матәм көне мөнәсәбәте белән чыгарылган. Ә икенче саны шул елның 28 октябрендә – Төркиянең Кортылыш бәйрәменә багышлап чыгарылырга тиеш булган[112].

1935 елның 23 гыйнвар җыелышында гарәп һәм латин әлифбаларын куллану мәсьәләсе турында сүз барган.

Гаяз Исхакыйның Шанхайга киләчәге һәм аны каршыларга әзерлек турында 1934 елның 28 ноябрендә сүз булган. 1934 елның 5 декабрь утырышында Г.Исхакыйның икегә бүленгән якларны берләштерүне кайгыртырга киңәш иткән хаты каралган. 1934 елның 26 декабрь җыелышында, Гаяз Исхакыйга язып җибәрелгән хат барып ирешмәгәнлектән, Шанхайдагы хәлләрне аңлатып һәм җыелыш беркетмәләренең копияләрен күчереп, Исхакыйга яңадан җибәрү карар ителгән.

1936 елның 25 февраль җыелышында Гаяз Исхакыйның Шанхайга киләчәге һәм аны каршылау мәсьәләсе каралган. Идарәнең 2 нче март утырышы да тулаем шул мәсьәләгә багышланган. Г.Исхакыйның Харбиннан чыкканлыгы һәм Шанхайда өч көн торачагы белдерелгән. Бу җыелыш беркетмәсендә язылганнардан Мәдәният җәмгыяте идарәсе тарафыннан Гаяз Исхакыйның ни дәрәҗәдә ихлас хөрмәтләнгәнлеге ачык күренә. Алда язылып үтелгәнчә, Г.Исхакый Шанхай шәһәренә 4 мартта килеп, 7 март көнне киткән. 10 март җыелышы беркетмәсендә Г.Исхакый Шанхайга килгәч, аның алдында уйналган кичәнең (спектакльләр, шигырьләр, җырлар һәм биюләр) нинди тәртиптә булганлыгы язылган.

1936 елның 21 март утырышында Габдулла Тукайның вафатына 23 ел тулу мөнәсәбәте белән рус телендә бер көнлек газета чыгару карары кабул ителгән. Газетада Тукайның (1886–1913) үзе һәм

[112] №50, 51 протоколлар.

әсәрләре турында мәкаләләр, шулай ук Мәдәният җәмгыятенең эшчәнлегенә багышланган язмалар бастыру күздә тотылган[113]. Ләкин мәкаләләр язылып өлгермәү сәбәпле, ниятләнгән газета чыгарылмыйча калган. Шулай да, махсус «Тукай кичәсе» оештырылган[114].

1936 елның 8 апрелендә узган идарә җыелышы Шанхайда рус телендә нәшер ителгән «Наш путь» исемле газетада Колосова фамилияле автор тарафыннан язып бастырылган мәкаләгә карата нәфрәт белдерүгә багышланган. Колосова үз мәкаләсендә Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» китабын яманлап һәм, гомумән, татарлар турында кимсетүле фикерләр язган булган. Төрк-татарларның мәдәният җәмгыяте һәм Милли идарә җитәкчеләреннән дүрт кеше сайланып, газета чыккан көндә үк «Наш путь» редакциясенә барып бу хакта сөйләшергә, Колосованың үз сүзләрен кире алуын таләп итәргә дигән карар чыгарылган. Шулай ук рус телендә аңа каршы брошюра язып бастырырга да карар ителгән. Колосовага җавап Мәдинә Салиәхмәт тарафыннан язылып, аерым бер биттә бастырылып таратылган[115].

1936 елда шагыйрь Г.Тукайның тууына һәм татар телендә беренче роман (Муса Акъегетзадәнең (1864–1923) «Хисаметдин менла» әсәре) басылып чыгуга 50 ел тулу истәлегенә китап кибете ачу тәкъдим ителгән. Анда мөһаҗирлектәге милли хәрәкәткә, тарих һәм әдәбиятка караган китаплар, журналлар сатарга дигән максат куелган[116]. Бу мәсьәләдә Мәдәният җәмгыятенең башкарма комитеты тарафыннан язылган хат «Идарәгә мәктүб» исеме астында «Милли байрак» газетасының 1936 елгы 22 май санында басылып чыккан. (Хатның тексты кушымта бүлегендә бирелде). Шул елның җәендә уку елы тәмамлану уңае белән укучыларга Габдулла Тукай рәсеме бүләк итеп бирелгән[117].

---

[113] №65, 66 протоколлар.
[114] №68 протокол.
[115] №68 протокол.
Колосова вакыйгасына бәйле мәсьәлә И.Нуруллин мәкаләсендә дә телгә алынган иде (Нуруллин И. Әдип эзләреннән – Төркиядә // Казан утлары. – 1991. – №3. – Б. 145).
[116] №69 протокол.
[117] №71 протокол.

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең эшчәнлегенә бер ел тулып узгач, идарәнең 1935 елгы 3 октябрь утырышында гомуми җыелыш үткәрү мәсьәләсе күтәрелгән. Аны уздыру көне итеп башта 7 ноябрь билгеләнгән. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында, җыелыш уздыру кичектерелгән. Гомуми җыелышта яңа идарә сайлау каралган. Яңа идарәгә рәис итеп – Шаһвәли Келәүле, сәркятиблеккә – Шакир Баязиди яисә Мансур Арсланбәк, хәзинәдар вазыйфасына Кадыйр Габдрахман сайлануы мәгъкуль күрелгән[118].

Тик 1936 елга чыккач та бу җыелыш тиз генә оештырыла алмаган. Мәсәлән, яз көне «тиз көннәрдә, Милли идарә бүлмә алу белән, гомуми җыелышны эшләргә» дигән карар булган[119]. Аннары, 18 май җыелышында, гомуми җыелыш үткәрүнең тәртибе расланган. Шулай ук Шанхайдагы вәзгыятькә карап, җәмгыятьнең низамнамәсенә үзгәрешләр кертү каралган. Ниһаять, җәмгыять идарәсенең 8 июль утырышында гомуми җыелышны уздыруның тәгаен көне – 1936 елның 13 июле дип билгеләнгән. Бу хакта рус газеталарында да игъланнар бирелгән. Мәдәният җәмгыятенең 8 июль утырышы булып, берничә көн узгач, гомуми җыелыш үткәрелгән дип фаразлый алабыз. Ул җыелыштан соң Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятендәге үзгәрешләр безгә билгесез диярлек. Һәрхәлдә, җәмгыять идарәсе җыелышларының 1934 елдан башлап протоколлары язылып барылган һәм бу җыентыкта текстлары басылган дәфтәрдә бүтән язмалар юк.

1936 елның 8 июль җыелышыннан соңгы чорда Шанхай Мәдәният җәмгыятенең эшләре турында мөһаҗирлек матбугатында язылганнарга һәм кайбер хатирә язмаларына нигезләнеп кенә фикер йөртә алабыз.

Равил Салиәхмәт хатирәләренә караганда, Мәдәният җәмгыяте 1940 нчы еллар башында Шанхайдагы Төркия илчелеге белән элемтәләр урнаштырган. Тик 1941 елда «Япониянең сугышка керүе белән оешуларга рөхсәт бирелмәде һәм җыелышлар аз булды» ди Р.Салиәхмәт[120].

---

118 №54 протокол.
119 №69 протокол.
120 Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 75.

Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәсендә Шанхайдагы Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең эшчәнлеге тукталган. Бу хакта Р.Салиәхмәт «Җәмгыять 14 ел дәвам итеп, 1948 елны ябылды» дип белдергән. Бу очракта, бәлки, җәмгыятьнең 1948 елда рәсми ябылу елы күздә тотылгандыр. Чөнки 1945–1948 еллар арасындагы сәяси хәлләр аркасында җәмгыятьнең ниндидер эш алып бара алган булуы шик уята. Ә Әбрар Кәримуллинның «...Татар җәмгыяте Шанхайда әле 50 нче еллар башында да шактый актив эшләгән»[121] дип язуы дөреслеккә бөтенләй туры килми. Билгеле булуынча, 1945 елның 2 сентябрендә Япония капитуляция Актына кул куйганнан соң һәм совет контрразведкасы тарафыннан Ерак Көнчыгыштагы Идел-Урал оешмасының җитәкчелеге кулга алынгач, аның төрле шәһәрләрдәге җәмгыятьләре ябылган.

## Җәмгыять тарафыннан үткәрелгән чаралар

Шанхайдагы бу җәмгыять, мәдәни берләшмә буларак, төп игътибарны милли һәм мәдәни кичәләргә юнәлткән. Бу мәсьәлә һәм ниятләнгән чараларның якынча планы җәмгыятьнең низамнамәсендә дә күрсәтелгән. Низамнамәнең тексты татар мөһаҗир матбугаты аша чит илләрдә яшәгән киң даирә милләттәшләргә игълан ителгән[122].

Җәмгыять тарафыннан, төрки һәм татар дөньясында мәшһүр затларга багышлап, шулай ук дини бәйрәмнәр һәм тарихи вакыйгалар мөнәсәбәте белән төрле кичәләр уздырылган. Шундый чараларның кайберләренә күзәтү ясап үтик. Мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспралы Мәдәният җәмгыяте беркетмәләрендә «бөек бабамыз» дип зурланган һәм аның вафатына 20 ел тулуга багышлап кичә үткәрү 1934 елның 30 сентябренә билгеләнгән.

Җәмгыятьнең 1934 елгы 14 сентябрь җыелышында галимнәр һәм дин эшлеклеләре Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Галимҗан Баруди (1857–1921) турында халык алдында лекцияләр сөйләү

[121] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 34–35.
[122] Яңа милли юл. – 1934. – №12. – Б. 25–26.

каралган. 1934 елда фарсы әдәбияты классигы Фирдәүсинең 1000 еллыгын билгеләп үтүгә хәзерлек булган[123].

Корбан бәйрәме уңаеннан 1935 елның 16 мартында Мәдәният җәмгыяте үткәргән кичәдә спектакль куелуы, җыр һәм биюләр башкарылуы турында «Шанхайская заря» газетасында язма басылган[124].

Казан алынган көнгә багышланган матәм кичәләре 1934 елда 14 октябрьдә, 1935 елда 15 октябрьдә билгеләп үтелгән.

Җәмгыять тарафыннан 1934 һәм 1935 елларның 28 октябрь көннәрендә Төркиянең Кортылыш (Азатлык) бәйрәме үткәрелгән.

Мәҗит Гафури (1880–1934) һәм Галимәрдан Тупчибашевның (1862–1934) вафат булулары мөнәсәбәте белән 1935 елның 3 мартында халыкны җыеп матәм кичәләре уздырылган[125].

1935 елның 19 апрелендә Габдулла Тукайның үлеменә 22 ел тулу мөнәсәбәте белән кичә үткәрү һәм рус газеталарында шул турыда язмалар бастыру күздә тотылган, рус газеталары бастырырга риза булса, шул чордагы зур югалтулар – Й.Акчура, М.Гафури һәм Г.Тупчибашевлар турында мәгълүматлар бастырырга карар ителгән[126]. Болар хакында, чынлап та, «Шанхайская заря» газетасында язмалар чыккан[127]. Мәдәният җәмгыятендә Г.Тукай, Й.Акчура, М.Гафури, Г.Тупчибаш, Ш.Мәрҗанигә багышлап кичәләр үткәрелгәнлеге турында, шулай ук бу шәхесләрнең тормышлары һәм эшчәнлекләренә багышлап М.Салиәхмәтнең Шанхайдагы рус газеталарында мәкаләләр бастырганлыгын Ә.Кәримуллин да тасвирлаган[128].

Йосыф Акчурага багышланган махсус кичә 1935 елның 26 апрелендә оештырылган[129].

1935 елның 15 маенда Ислам динен кабул итү көне билгеләп үтелгән[130].

---

[123] №4 протокол.
[124] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 141–142.
[125] №26 протокол.
[126] №33, 34 протоколлар.
[127] Черникова Л. Күрсәтелгән мәкалә. – Б. 141–142.
[128] Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 57.
[129] №23 протокол.
[130] №37 протокол.

1935 елның 12 июнендә Мәүлид бәйрәме тантаналы итеп уздырылган[131].

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте әдәби-музыкаль кичәләргә укучы балаларны да җәлеп итеп, аларны милли-мәдәни рухта тәрбияләүгә зур әһәмият биргән. Мәсәлән, 1935 елның 28 декабрендә уздырылган балалар кичәсенең нинди тәртиптә үткәрелеп, кемнәр нинди чыгыш ясаган булулары турында 57 нче санлы беркетмәдә язылган. Бу бәйрәм турында Гайниҗамал Ильяснең «Шанхайда балалар кичәсе» исемендәге мәкаләсе «Милли байрак» газетасының 1936 ел 15 гыйнвар санында басылып чыккан. (Мәкалә текстын китапның кушымтасыннан карагыз).

Җәмгыять тарафыннан оештырылган төрле кичәләрдә халкыбызның яраткан шагыйрьләре Г.Тукай һәм М.Гафури шигырьләре даими укылган.

Җәмгыять идарәсенең 1936 елгы 3 гыйнвар җыелышында, Шәркый төркестанлылар белән бергәләп, Шанхайның зур бер театрында кытайлылар алдында кичә кую мәсьәләсе күтәрелгән. Фикерләшкәннән соң, Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә» әсәрен сәхнәләштерү карар ителгән. Җәмгыятьнең 19 гыйнвар җыелышы тулаем шушы кичәгә хәзерләнүгә багышланган. Анда рольләрне башкарырга тиешле кешеләр билгеләнгән. Режиссёр итеп башта Хөсәен Габдүшне[132] чакыру тәкъдимнәре әйтелсә дә, аны чит

[131] №40 протокол.

[132] Ә.Кәримуллин китабында Х.Габдүш турында мондый мәгълүмат бар: «...Ул 1901 елда Троицк шәһәрендә туа, яшьли ятим калып, агасы Мөхәммәтвәли Ибраһим тәрбиясендә үсә. Троицкида җәдид мәктәпләрен тәмамлый. Аннан Кызылъяр (Петропавел) «Реальное училище»сына укырга керә. 16 яшендә, агасының гаиләсе белән бергә, 1917 елда Харбинга барып чыга. Харбинга килү белән, татар җәмәгать эшенә кереп чума. Татар мәктәбендә укытучы, театр оештыргач – аның артисты һәм режиссеры. Татар һәм урыс язучыларының әсәрләреннән инсценировкалар ясый. Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре», «Бәхетсез егет», Г.Исхакыйның «Зөләйха», «Алдым-бирдем», «Кыямәт» пьесаларын һәм башка әсәрләрен сәхнәләштерә. Нәфис сүз остасы сәхнәдән Тукай, Дәрдмәнд, С.Рәмиев шигырьләрен укый. Тукайга, татар әдәбиятына караган мәкаләләр яза. Күп кенә кыска хикәяләр авторы. Аның әсәрләре «Ерак Шәрык», «Яңа милли юл», «Чаткы», «Милли байрак» дигән газета һәм журналларда басылып тора. Токиода татар телендә «Дүрт хикәя» дигән китабы чыга. Берничә җыр авторы, татар җырларын башкаручы оста җырчы. Харбин татар җәмгыяте рәисе булып та эшли. 1944 елда

шәһәрдән китертүнең кыенлыклары булганга, Тәнзиннән Шәйхулла Йосыфны чакыртырга булганнар. 16 февраль җыелышында Ш.Йосыфның килә алмавы һәм уйнаучылардан Мансур Арсланбәкнең китүе сәбәпле, кичә мәсьәләсе кичектерелгән.

1936 елның 10 февраль җыелышында Ш.Мәрҗанинең вафатына 50 ел тулу уңаеннан мәҗлес оештырырга һәм русча газеталарның берсенә мәкалә язарга карар ителгән.

Җәмгыять әгъзалары тарафыннан төрле вакытларда Галиәсгар Камалның (1879–1933) «Беренче театр» спектакле һәм башка әсәрләр уйналган, Кәрим Тинчуринның (1887–1938) «Казан сөлгесе»нең бер-ике пәрдәсен һәм Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәрен сәхнәләштерү омтылышлары ясалган.

1936 елның 11 мартында Йосыф Акчураның вафатына бер ел тулуга багышлап оештырылган мәҗлес турында «Милли байрак» газетасының 1936 елгы 1 май санында хәбәр басылган. Кадыйр имзасы астында басылган «Йосыф бәк Акчура истәлеге» исемле ул язманың авторы кем булганлыгы турында тәгаен әйтә алмыйбыз. Чөнки аның Мәдәният җәмгыяте идарәсенең бер әгъзасы – Кадыйр Габдрахман яисә мондый имза-псевдоним белән мәкаләләр язганлыгы мәгълүм[133] Мәдинә Салиәхмәт булуы ихтимал.

Мәдәният җәмгыяте төрле чаралар үткәргәндә Украина миллимәдәни оешмасы (Громада) бинасын еш файдаланган, хөрмәт йөзеннән анда украин һәм грузиннарның милли хәрәкәт җитәкчеләре дә кунак итеп чакырылган[134].

Мәдәният җәмгыяте тарафыннан Габдулла Тукайга багышлап 1936 елның 17 апрелендә бик зурлап уздырылган кичә турында «Милли байрак» газетасының 8 май санында «Хәбәрче» имзасы белән мәкалә басылган.

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыятенең, безгә җыелыш беркетмәләре аша билгеле булмаган чорда да, мәсәлән, 1937 һәм 1938 елларда үз эшчәнлеген актив дәвам иткәнлеге мөһаҗирлектә нәшер ителгән татар матбугаты битләрендә басылып торган мәкалә һәм

---

41 яшендә Харбинда вафат була, шундагы татар зиратында җирләнә». (Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Б. 30–31).

[133] Усманова Л. Тюрко-татарская эмиграция Дальнего Востока... – С. 186.

[134] №30, 31, 36, 45, 46, 48, 49, 61, 71 протоколлар.

язмалардан яхшы күзаллана. Андый мәкаләләрнең кайберләре бу китапның кушымта өлешендә күчереп бирелде. Мәсәлән, 1936 елның 15 октябрендә Матәм көне билгеләп үтелгән. 1937 елның 24 февралендә әдип Гаяз Исхакыйның туган көне һәм әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте белән тантана үткәрелгән. Шул ук елның 25 февралендә мәктәп файдасына милли кичә уздырылган. 1937 елның 15 апрелендә ике вакыйга: Ризаэтдин Фәхретдиннең (1859–1936) вафатына бер ел тулу һәм Габдулла Тукайның вафат булуына 24 ел тулу мөнәсәбәте белән бу бөек затларны искә алу кичәсе оештырылган. 1938 елның 19 апрелендә Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу вакыйгасы да җәмгыять тарафыннан зурлап уздырылган. 1938 елның 14 май көнендә Мәүлид бәйрәме олылап билгеләп үтелгән.

1938 елның 20 декабрендә Мостафа Камал Ататөрекнең (1881–1938) вафат булуына 40 көн тулу татар мөһаҗирләре арасында зур матәм буларак уздырылган. Бу вакыйгага багышлап, төрле шәһәрләрдә узган матәм мәҗлесләре турында «Милли байрак» газетасының 1939 елгы 13 гыйнвар санында «Газый паша истәлекләре» исеме астында язмалар басылып чыккан. Шанхайдан «Хәбәрче» имзалы репортажда «Бөек төрек өндәре Ататөрек хәзрәтләренең кырыгы көнендә Шанхай Идел-Урал комитеты һәм Яшьләр оешмасы тарафыннан Украина клубында уздырылган зур мәҗлес бу вакытка кадәр Шанхайда булып узган мәҗлесләрдән бөтенләй аерылып, матәм төсендә, бөек ихтирам эчендә уздырылды» дип башланып, чыгыш ясаучылар һәм кичәнең узуы тасвирланган. Мәҗлесне Идел-Урал комитетының рәисе Кәшшаф Әхмәди ачкан, имам Әүхәди Җамалетдин Коръән укып багышлаган, Мәдинә Әхмәди татарча һәм русча докладлар сөйләгән. Анда шулай ук Шанхайдагы грузиннар һәм украинлыларның вәкилләре чыгышлар ясаган.

Надир Дәүләт Шанхайдагы татар җәмгыятен Ерак Көнчыгыштагы мөһаҗирлек тормышында исемнәре һәм эшчәнлекләре иң күп телгә алынган оешмаларның берсе булган дип бәяли[135].

[135] Дәүләт Н. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды... – Б. 86.

## Беркетмәләр журналының язылу үзенчәлекләре

Мәдәният җәмгыяте идарәсенең җыелыш беркетмәләренең язылу рәвешен кыскача тасвирлап китик.

Аларның күпчелеге җәмгыятьнең сәркятибе Мәдинә Салиәхмәт кулы белән язылган.

Гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган беркетмәләр, документаль чыганак булганлыктан, аларның язылу рәвеше рәсми стильдәгечә.

Җыелыш беркетмәләренең телендә XX гасыр башы татар матбугаты һәм язма теленә хас булган грамматик үзенчәлекләр бар. Бу документлар язылган 1930 нчы елларда татар халкының совет илендә яшәгән төп өлешенең язма теле 1917 елгы инкыйлабтан соң, идеологик тәгълиматка бәйле рәвештә, шактый үзгәреш кичергән. Әмма мөһаҗирлектәге татар матбугатында һәм язма телендә элеккеге традицияләр, Тукайлар чорындагы тел үзенчәлекләре озаграк сакланган. Бу күренеш Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең җыелыш беркетмәләрендә дә чагылыш тапкан. Беркетмә текстларында әүвәлдән килгән, язма телдә генә кулланылган борынгы төрки сүзләр, архаик гарәп һәм фарсы алынмалары булуы шуның ачык дәлиле. Мәсәлән, *ошбу, тугрыда, берлән, ултырыш, агыр, тәфтиш, мәсариф, җәридә, шинбә, якшәнбә, дөрест* кебек сүзләр шундыйлардан. Шул ук вакытта беркетмә текстларында диалекталь гыйбарәләр (*янгал, тарафлы, анарга, яңгы, йибәрү* һ.б.) һәм бераз рус сүзләре дә бар. Аз-маз гына булса да яңа сүзләр (неологизмнар) күренә. Мәсәлән, *бәйрәмләү, белдермә, хәбәрләндерү, эш башчы* һ.б.

Төп чыганак текстындагы архаик, диалекталь һәм иске рус сүзләре җыентык ахырындагы сүзлекчәдә туплап бирелде. Анда шулай ук мөһаҗирлек матбугатыннан алынган, китапның кереш мәкаләсендәге һәм кушымта өлешендәге текстлардагы сүзләр дә өстәлде.

Беркетмәләрнең текстлары, ашыгыч язылган булулары сәбәпле, бөтен җөмләләре дә тулы һәм төзек түгел. Кульязмада орфографик хаталар аз булса да, автоматик рәвештә кайбер сүзләр язылмыйча калган, иҗекләр һәм хәрефләр җитешмәгән очраклар бар. Урыны-

урыны белән стиль кытыршылыклары да күренгәли. Кульъязманың төп текстындагы вак-төяк орфографик хаталарны бу җыентыкта күрсәтеп тормадык. Ә төшеп калган иҗекләр һәм аерым хәрефләрне, шулай ук язылмыйча калганлыгы ихтимал дип фаразланган сүзләрне квадрат җәяләр эчендә өстәдек.

Беркетмә текстларында тыныш билгеләре һәрвакытта да тотрыклы түгел.

Югарыда күрсәтелгән сәбәпләрдән, кайбер җөмләләрнең беткән һәм икенчеләренең башланган урыннары төгәл ачык түгел. Төп текстта булмаган тыныш билгеләре безнең тарафтан өстәлде.

Кульъязмада һәр җыелыш беркетмәсенең башында язылган көн тәртибенең саны һәм тәртибе, «каралган мәсьәләләр» исемендәге баганадагы белән һәр очракта да тәңгәл килеп бетми.

Һәр беркетмәнең ахырында рәис, сәркятиб һәм әгъзалар имза куярга тиешле булсалар да, бу тәртип тотрыклы сакланмаган. Без исә, бу җыентыкта текстны бастырганда документның нәкъ үзендәгечә бирдек. Ягъни, төп текстта имзалары куелмаган булса да, «рәис» һәм башка сүзләр документтагыча бирелде.

Беркетмәләрдә бер үк сүз төрлечә язылган очраклар (мәсәлән, *газета* һәм *гәзитә*), шулай ук кеше исемнәре (*Арсланбәк* һәм *Арсланбик*) үзгәрешсез калдырылды.

Беркетмә текстларында Сөнәгать дип язылган кеше исеме бу басмада да шулай бирелде. Әлеге исемнең дөрес һәм тулы варианты – Сөнгатулла рәвешендә башка чыганакларда басылган булган[136]. Ә Сөнәгать дип язылуга килгәндә, ул гарәп теленнән кергән исемнәрне, мәсәлән, Сибгатьне – Сибәгать, Мәсгутьне – Мәсәгуть дигән кебек, татарчада үзгәртебрәк әйтелешнең бер күренеше.

Текстта кириллица хәрефләре белән һәм рус телендә язылган сүзләр төп документтагыча бирелеп, андый очраклар астөшермәдә искәртелде.

Документның төп текстындагы яңа бит башланган урыннар кыекча ике сызык һәм бит санын язып (*// 6а кәгазь* рәвешендә) күрсәтелде.

---

[136] Мәсәлән, «Милли байрак» газетасының 1938 елгы 17 июнь санында. Кушымтага карагыз.

Җыелыш беркетмәләрендә һәм бу китапның кушымта өлешендәге текстларда «төрк» рәвешендә язылган сүз «төрки» мәгънәсен, ә «төрек» атамасы Төркиянең төп халкын белдерә.

***

Бу хезмәтне басмага әзерләгәндә, «Яңа милли юл» журналы һәм «Милли байрак» газетасының аерым саннарын файдаланырга биреп торган галимә Лена ханым Гайнановага, «Яңа милли юл» журналының 1934 елгы 10 нчы санын кулланырга биргән филология фәннәре кандидаты Зөфәр әфәнде Мөхәммәтшингә, шулай ук кайбер мәгълүматларга ачыклык кертүдә ярдәмләшкән Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс әфәнде Тукаевка ихлас рәхмәтләребезне юллыйбыз.

# ШАНХАЙ ТӨРК-ТАТАР МӘДӘНИЯТ ҖӘМГЫЯТЕ ИДАРӘСЕНЕҢ ҖЫЕЛЫШ БЕРКЕТМӘЛӘРЕ

// *(2а кәгазь)* Протокол №1

7 нче сентябрь 1934 елда булган Шанхай төрк-татарларның Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, И.Әхмәди, Ш.Келәүле, М.Арсланбәк, Л.Габдрахмани, Г.Ильяси, М.Әхмәди.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Милли истикъбалебез өчен көрәшүчеләребез хакында.
2. Сәркятибкә ярдәмчеләр сайлау.
3. Һәйәтнең низамнамәсе хакында.
4. Шанхай төрк-татар яшьләренең мал-милке һәм көтепханәсе хакында.
5. «Яңы милли юл»га мөхбир сайлау.
6. Әдәбият кичәсе кую.
7. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *каралган мәсьәләләр* | *чыгарылган [карарлар]* |
|---|---|
| 1. Милли истикъбалебез өчен көрәшүчеләребез хакында. | К.Әхмәди бу тугрыда мәгъруза эшли:<br>Идел-Урал төркләренең истикъбале өчен көрәшүдә бар гомерен сарыф иткән, зиндан-сөрген газапларын күреп тә, һаман шул эшне дәвам итеп, хәзерге көндә Идел төрк истикъбаленең байрагын күтәргән бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакны, Шанхай Төрк-татарларның мәдәният җәмгыятенә фәхри рәис итеп сайлауны һәм шулай ук төркчелек өчен көрәшүчеләребез: азәрбәйҗанлы Мөхәммәд Әмин бәк Рәсүлзадә, кырымлылардан Сәед Әхмәд Җәгъфәр, төркестаннардан Мостафа Чукай угылы төркчелек көрәшендә үзебезнең юлбашчыла[ры]быз итеп санап, фәхри әгъза // *(2б кәгазь)* итеп хисаплауны. |

| | |
|---|---|
| | Оешмабыз беравыздан Гаяз әфәнденең эшләгән эшләрен һәм күтәргән байрагын тәкъдир итеп, шатлык белән аны Мәдәният җәмгыятенең фәхри рәисе итеп сайлый, калган өч милли юлбашчыларыбыз берлән күп әгъзаларыбыз таныш булмаулары сәбәпле, бу затларның эшләгән эшләренең һәм тоткан юллары белән мөфассаль рәвештә әгъзаларыбыз танышкач, аларны фәхри әгъза итеп сайлау тиешле табылды. |
| 2. Сәркятибкә ярдәмчеләр сайлау. | Эш күп булуы күздә котелеп, сәркятибкә ярдәмче уларак Мәдинә Әхмәди һәм Мансур Арсланбәк сайландылар. |
| 3. Һәйәтнең низамнамәсе хакында. | Һәйәтнең низамнамәсен әгъзаларыбыз һәм чит оешмаларга йибәрү өчен 25 данә язарга тиешле табылды. Язу эше Латыйфа, Гайниҗамал ханымнарга, Шаһвәли, Мансур, Исхак әфәнделәргә тапшырылды. Низамнамәне русчага тәрҗемә итү – Мәдинә ханыма, французча – Шаһвәли әфәндегә. |
| 4. Яшьләр оешмасының малмилке һәм көтепханәсе тугрында. | Шанхай төрк-татар яшьләренең мал-милке һәм көтепханәсе Яшьләр оешмасы беткәч сакланыр өчен махсус бер һәйәткә вакытлыча тапшырылган иде. Хәзер, Мәдәният җәмгыяте төзелү белән, мал-милек һәм көтепханә Мәдәният җәмгыятенә күчкәнгә, махсус сайлау һәйәтеннән шул милекләрне тапшыруын сорап хат язарга. |
| 5. Мөхбир. | Мәдәният җәмгыятенең әхвале «Милли юл» җәридәсенә[1] язып торыр өчен мөхбир уларак К.Әхмәди сайланды. |
| 6. Әдәбият кичәсе эшләү. | 9 нчы сентябрьдә әдәбият кичәсе һәм чәй мәҗлесе ясарга карар бирелә һәм киләчәк программы да төзелә.<br>Беренче – «Яңы милли юл»да язылган Сания Гыйффәтнең «Углан» дигән шигыре укы[лы]р.<br>Шуннан соң Төрек мәмләкәтенең чын мәгънәсе белән // *(3а кәгазь)* истикъбалияткә ирештергән газый Мостафа Камал пашаның кыскача тәрҗемәи хәле сөйләү К.Әхмәдигә тапшырыла.<br>Аннан соң Шанхай төрк-татарларыбызның тормышыннан алынып Шаһвәли Келәүле тарафлы язылган |

[1] Гарәп теленнән кергән, газета дигәнне белдерә торган «җәридә» сүзе монда ялгыш язылган. Чөнки «Милли юл» – журнал булган.

| | |
|---|---|
| | «Сүтәбез, өябез» дигән әсәр уйналачак.<br>Шулай ук Шанхай тормышыннан алып Исхак Әхмәди һәм Мансур Арсланбәк тарафлы язылган «Мохтариятчеләр җыелышы» дигән әсәр уйналачак.<br>Чәй мәҗлесе булачак.<br>Гайниҗамал, Латыйфа ханыма, Шаһвәли, Исхак, Мансур әфәнделәргә тапшырыла шушы кичәне эшләү. Чәй мәшәкатьләре Латыйфа ханым, Гайниҗамал ханыма тапшырыла. |
| 7. Тәфтиш һәйәтеннән вәкил. | Тәкъдим кертелә тәфтиш һәйәтеннән бер әгъза идарә җыелышларында булуы тиешле табыла вә шуны тәфтиш һәйәтенә белдерергә. |
| 8. Нәүбәттәге мәсьәләләр:<br>1) зур кичә;<br>2) хосусый хатлар. | 1) Алдыбызга куйган эшләребез байтак күп мәсариф белән бәйләнгәнгә, киләчәктә зур хәзерлек белән бер кичә кую кирәкле табылды. Вакыт соң булганга, бу тугрыда соңгы фикер алышу башка вакытка калына.<br>2) Бу вакыткача иҗтимагый эшләрдә эш башында торучыларыбыз һәм чит шәһәрләр, һәйәтләргә мөрәҗәгать итми, хосусый кешеләргә мөрәҗәгать итүләре иҗтимагый эш өчен күп зарар китергәнгә, моннан соң хосусый хатларга игътибар итмәскә һәм бу карарны белдереп, читтәге һәйәтләргә һәм эш башчыларыбызга язарга. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*

// *(3б кәгазь)* Протокол №2

14 нче сентябрь 1934 елда булган Шанхай төрк-татарларның Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәис[лек] итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Узган кичә турында.
2. Исмәгыйль Гаспралы хакында.
3. Эш планы карау.

| *каралган мәсьәләләр* | *чыгарылган карарлар* |
|---|---|
| 1. Узган кичә турында.<br>2. Исмәгыйль Гаспралы хакында рәиснең тәкъдиме.<br><br><br><br>3. Эш планын тикшерү һәм тәсдыйк итү. | Кичәне күңелле итеп уздыруда ярдәмдә булган ханым һәм әфәнделәргә рәхмәтләр әйтелә.<br>Бөек бабамыз Исмәгыйль Гаспралының үлүенә 20 ел тулу мөнәсәбәте илә халкыбызны аның тәрҗемәи хәле һәм эшләгән эшләре белән таныштыру өчен мәгъруза ясау тиешле табыла һәм бу эшне Шаһвәли әфәндегә тапшырылды, рәсемене диварга тагуга тәкъдим ителде.<br>Эш планы маддәләп укылып, тәсдыйк ителә.<br>1. Идел-Урал истикъля469лиятен халкыбызга аңлатыр өчен иң кыска юл – шул фикерне таратучы һәм шул юлда бар гомерен сарыф итүче бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде тарафлы чыгарыла торган «Яңы милли юл» җәридәсен[2] төрк-татарлар арасында тарату.<br>а) Шанхайда яшәүче төрк-татарларының, матди яклары авыр булу сәбәпле, берьюлы 100 сум түли алмаганга һәм шулай ук номер өчен 50 тиен Шанхай акчасыннан артык түли алмаулары игътибарга алынып, бу елга әгъзаларыбыз арасында // *(4а кәгазь)* таратыр өчен 25 данә «Милли юл»ны соратырга.<br><u>Искәрмә:</u> шул мәсьәлә турында юлбашчыбыз Гаяз әфәндегә һәм һәйәт[кә] мөрәҗәгать итеп, ярдәмдә булуларын сорарга.<br>б) Һәр айның хисабын «Яңы милли юл»га йибәреп торырга.<br>2. Идел-Урал истикъляле бөтен төрк өлкәләренең истикъляле белән баглы булганга, мөмкин булган кадәре шушы юлда баручы мәҗмугаләрне төрк-татарлар арасында таратырга тиешбез. Ул мәҗмугаләр ошбулар: Төркестан истикъляле фикерен таратучы «Яшь Төркестан», Азәрбәйҗан истикъялен – «Истикъляль», Кырымныкы «Әмәл» һәм «Чини Төркестан авазы».<br><u>Искәрмә:</u> халкыбызның матди ягы игътибарга алынып, бу мәҗмугаләр көтепханәдә генә булулары лязем.<br><u>Искәрмә:</u> Идел-Урал истикъляле җәгърафи яктан Төркестан белән күрше булулары һәм бу ике өлкәнең |

[2] «Яңа милли юл» – җәридә (газета) түгел, ә журнал булган.

мәнфәгатьләре бер-бере белән баглы булганга, Төркестан хәрәкәтене тикшереп барыр өчен әгъзаларыбызның матди яклары авыр булса да, берәр данә «Истикъляль» мәҗмугасен алулары тиешле.

Искәрмә: Шулай ук һәрбер әгъзаның өс[т]енә йөкләтенелә: дуст-ишләре арасында Идел-Урал истикълял фикерен тарату һәм «Милли юл» җәридәсен тарату.

3. Шанхайда, аена бер мәртәбә булса да, төрк-татар телендә гәзитә чыгару.

Искәрмә: Шулай ук чит милләтләргә үзебезнең истикълялиятебезне аңлату өчен рус гәзитәләрендә ай саен инфор[мация][3] эшләп тору.

4. Конферанслар эшләү:

// *(4б кәгазь)* 1. Төрк-татар тарихы.

2. 1905 нче елдан башлап милли хәрәкәт фикерен халкыбызга аңлату.

3. Төркестан тарихы.

4. Азәрбәйҗан тарихы.

5. Кырым тарихы.

6. Төркиянең тарихы һәм хәттый хәрәкәте.

7. Татар әдәбияты.

8. Татар теле.

9. Татар музыкасы.

10. Татар театры.

11. Төрк-татарларыбызның истикъбале өчен эшләгән халыкларыбызның тарихларын сөйләү.

12. Милли бәйрәмнәрне бәйрәмләү һәм шул хакта мәгърузалар эшләү.

13. Төрк-татарлар арасында уку-язу белмәүчеләрне бетерү өчен курслар ачу һәм шулай ук латинча хәрефләре белән таныштыру.

14. Мәктәп балаларын буш вакытларда милли хәрәкәт һәм милли тарих белән таныштыру.

15. Гәзитәләрдән төрк-татарларга махсус материал-

[3] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.
[4] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.
[5] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.
[6] «Акт» сүзе рус хәрефләре белән язылган.

| | |
|---|---|
| | ларны җыеп, аена бер мәртәбә инфор[мация][4] эшләү.<br>16. Идел-Урал һәм төркчелек фикерен таратучы һәйәтләр белән якын мөнәсәбәттә булу.<br>Искәрмә: Шушы эшләрне вөҗүдкә чыгару өчен кирәкле булган китапларны безнең белән бер юлда баручы һәйәтләрдән сорату.<br>Эш планы тәсдыйк ителеп, әгъзалар арасында эш бүленә:<br>1. Татар тарихын сөйләү – Шакир Баязидидан сорау.<br>2. Татарның 1905 елдан башлап милли хәрәкәт тарихы – Кадыйрга.<br>3. Төркестан тарихы – Кәшшаф Әхмәдигә.<br>// *(5а кәгазь)* 4. Азәрбәйҗан тарихы – Шаһвәли Келәүле.<br>5. Кырым тарихы – Исхак Әхмәди.<br>6. Төркия тарихы – Мансур Арсланбәк.<br>7. Татар әдәбияты, музыкасы, театр – М.Әхмәди.<br>8. Ислахчыларыбыз: Шиһаб хәзрәт – Шаһвәли; Галимҗан хәзрәт – Исхак.<br>9. Төрк-татарларга булган хәбәрләрне ай саен инфор[мация][5] эшләү – Кадыйр Габдрахман. |
| Тәфтиш һәйәтеннән вәкил. | Идарә җыелышларында тәфтиш һәйәтеннән вәкил уларак Гайниҗамал ханым тәгаенләнгәне мәгълүм була. |
| Көтепханә һәм кыйраәтханә ачу. | Көтепханәне, үз кулыбызга кучүгә Акт[6] ясап, ачарга карар ителде. Атнасына ике көн ачык булачак, җомга һәм якшәнбә көннәрне. Кыйраәтханә һәр көн ачык булачак. Назыйрә уларак Латыйфа ханым сайлана. |
| Мөһер турында. | Кадыйр әфәнде тәкъдим итә мөһер эшләтүне. Бу турыда мөфассаль рәвештә фикер алышу киләчәк җыелышка кала. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтеннән әгъза: *Г.Ильясия*

Протокол №3

1934 ел 22 нче сентябрьдә булган Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, И.Әхмәди, Шаһвәли, Мансур, Кадыйр, Латыйфа ханым, Гайниҗамал ханым.

Көн тәртибе:

1. Кулланма хакында.
// *(5б кәгазь)* 2. Мөһер.
3. Алдагы әдәбият кичәсе.
4. Латин хәрефләре.
5. Музыка курслары.
6. Көтепханә турында.
7. Эш планы.
8. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *каралган [мәсьәләләр]* | *чыгарылган [карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кулланма хакында. | Оешмабыз хәзергә мәдәният җәмгыяте булганга, кулланма да Идел-Урал исемендә булмый, «Мәдәният җәмгыятенең кулланмасы» исемендә булырга тиеш. Кулланманы русча күчерү Мәдинә ханыма тапшырылганга, тизлек белән эшләп бирүен сорарга. Соңга инглизчәгә, французчага күчерелеп, оешманы тәсдыйк иттерергә. |
| 2. Мөһер. | Мөһер эшләтү тиешле табылды. Мөһер түгәрәк булып, кырыена татарча һәм англисчә: «Шанхай төрк-татарларның Мәдәният җәмгыяте» дип яздырырга. Уртада Идел-Урал галәмәте куйдырырга. Шушыны эшләтү чараларын күрү Исхак, Кадыйр, Шаһвәли, Мансур әфәнделәргә тапшырылды. |
| 3. Зур кичә кую. | Зур күләмдә бер кичә кую 7 нче сентябрьдә сөйләнеп узган булса да, шул мәсьәлә бүген тагын карала. Ләкин уйнаучыларыбызның читкә китүләре сәбәпле һәм кулда лаек китаплар булмаганга, якын арада кичә эшләп булмаганлык мәгълүм була. Рамазан гаетенә кадәр бу кичә калдырыла. Әлбиттә, мөмкинлек килеп чыкса, тиз арада куюга каршы торылмый. Мәдәният җәмгыятенең зур кичә куярга исәбе барлыгын Милли идарәгә белдерү тиешле табылды. |
| // *(6а кәгазь)* Әдәбият | 30 нчы сентябрь, якшәнбә көн, кич сәгать 7-дә әдәбият кичәсе эшләргә һәм шул кичәдә Исмәгыйль бәк |

| | |
|---|---|
| кичәсе. | Гаспралы турында сөйләү К.Әхмәдигә тапшырыла. Әдәбият бүлемен алып бару Латыйфа ханым, Исхак, Мансур, Гайниҗамал ханым, Шаһвәли әфәнделәргә тапшырылды. |
| Музыка курсларын ачу. | Милли музыка курсларыны ачып халкыбызны бушлай өйрәтү тиешле табылып, өйрәтү эше Мансур белән Исхак әфәнделәргә тапшырылды. |
| Көтепханәнең низамнамәсе. | Көтепханәнең низамнамәсе маддәләп укылып тәсдыйк ителә. Көтепханә һәфтәдә ике көн (җомга, якшәнбә) ачык булачак, 6–8 кадәр. Кыйраәтханә һәр көн идарә ачык вакытта ачылачак. |
| Эш планы. | Эш планы турында фикер алышына. |
| Латин хәрефләре. | Латин хәрефләре белән төрк-татар галәмендә язылa торган гәзит-мәҗмугаләрне укыр өчен латин хәрефләренең ачкычларын Төркия һәм Россиядән соратырга. |
| Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Идарәнең ултырышы һәр атна шинбә көнгә тәгаенләнә. 15 нче октябрь көне – Казан алынган көн булганга, кайгы көнебез хисапланып, киләчәк җыелышта шуны үткәрү тугрында фикерләр хәзерләп килергә.<br>Эш планы, низамнамә, һәр сайланган халыклар турында ошбу йирләргә хатлар йибәрелде: Гаяз әфәндегә; «Яңы милли юл»га; «Яшь Төркестан»га; «Әмәл» мәҗмугасенә; «Истикъляль» мәҗмугасенә; Мукден, Харбин, Токио, Кобе, Кумамото, Нагоя шәһәрләрендәге Идел-Урал мәдәният җәмгыятьләренә.<br>Искәрмә: Югарыда әйтелгән җәридәләрнең бәгъзеберләренә мөрәҗәгать ителде. Оешмабыз исеменә халык арасында таратыр өчен «Яңы милли юл» – 15 данә, «Яшь Төркестан»ны, «Әмәл», «Истикъляль» // *(6б кәгазь)* – 4 данә һәм көтепханә өчен берәр данә бушлай йибәрүләрен соралды. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб:
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №4

3 нче октябрь 1934 ел булган Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышы.

Хазир булдылар: К.Әхмәди, И.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, М.Арсланбәк, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Кичә хакында. Фирдәүси хакында.
2. Казан алу көнен уздыру.
3. Журнал.
4. Көтепханә.
5. Низамнамә.
6. Протоколлар.
7. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *каралган [мәсьәләләр]* | *чыгарылган [карарлар]* |
|---|---|
| [1-1.] Кичә хакында. | Кичә киләчәк якшәнбә көн булачак. Уйналачак әсәрләр тикшерелә. Шаһвәли әфәнде тарафлы язылган «Ике хәзрәт (Бер сәяси киңәш)» исемендә әсәр укылып, бик яхшы табылып, киләчәк кичәдә шуны кую тиешле табыла. Шулай ук Мансур әфәнде // *(7а кәгазь)* яза торган әсәрнең мәфһүме сөйләнә һәм ул да кичәдә куелырга лаек табыла. Шаһвәли әфәнде шигырьләреннән алып татар тарихына лаек бер шигырь укый. Кичә өчен бу да бик мәгъкуль табыла.<br>Кичәнең программасы:<br>1. «Гали рухына» (шигырь) – М.Әхмәди.<br>2. Гаспралы тугрында мәгъруза – К.Әхмәди.<br>3. Шигырь – Шаһвәли Келәүле.<br>4. Рәшид казый[7]. Исхак шигыре.<br>5. – Латыйфа ханым.<br>6. – Шаһвәли.<br>7. – Гайниҗамал ханым.<br>8. Ике хәзрәт. Шаһвәли, Мансур һәм Исхак.<br>9. Зәгыйфь солдатлар тормышыннан. Мансур әсәре. Уйнаучылар: Мансур, Шаһвәли, Исхак. |

[7] Документта: каза. Бәлки бу сүзнең дөресе «казыйга» дип язылырга тиеш булгандыр?

| | |
|---|---|
| | Кичә тугрында игълан таралачак. Керү хакы 30 тиен, кич 7,5-да. |
| [1-2.] Фирдәүси хакында. | [Бу] көннәрдә Иран шагыйрьләреннән мәшһүр Фирдәүсинең үлүенә 1000 ел тулу мөнәсәбәте илә якшәнбә көн кичәсендә аның турында мәгъруза эшләү бик тиешле табыла. Тик аның турында йитәрлек мәгълүматыбыз булмау мәсьәләне агырайта. Бу тугрыда фикер алышканнан соң, бу йирдәге Иран консулына барып, шул тугрыда мәгълүмат алу фикере гарыз ителә һәм К.Әхмәдигә консулга барып сөйләшү тапшырыла. |
| [2.] Казан алынган көн. | Казан алынган көн – безнең тарихыбызның иң кайгылы көннәреннән булганга, [бу] көнне матәм бәйрәмебез итеп хисапларга һәм шуңар багышлап мәҗлес эшләү, халкыбызны Казан алыну тарихы белән таныштыру өчен мәгъруза эшләргә.<br>// *(7б кәгазь)* Мәгъруза эшләү Мәдинә ханым Әхмәдигә тапшырылды. Милли идарә, Ата-ана һәйәтенә хатлар язып, шул мәҗлескә иштиракь итәр өчен вәкилләр йибәрүләрен сорарга. |
| [3.] Журнал. | Мәдәният җәмгыят[ен]ең эшләгән кичәләрнең программаларын, мәгърузаларның конспектларын, язылган яңа әсәрләрен[ең] мәфһүмнәрен язып барыр өчен бер журнал вөҗүдкә китерү тиешле табыла. |
| [4.] Көтепханә. | Көтепханәнең низамнамәсен язып диварга тагарга. |
| [5.] Низамнамә. | Низамнамәләрне язып үз халкыбыз арасына таратырга. |
| [6.] Гектограф. | Игълан һәм башка язмаларны кулда[н] язу бик авыр булганга, Кадыйр әфәнде әйтә гектограф[8] эшләтүне. Бу фикер бик мәгъкуль табылып, шуны эшләп бирүне Кадыйр әфәндегә тапшырылды. Сарыфына ике сум тәгаенләнә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар]: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

[8] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

Протокол №5

11 нче октябрь 1934 ел. Шанхай төрк-татарларының Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур, Латыйфа ханым, Гайниҗамал ханым.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Кичә хакында.
2. Тарих.
3. Төркиянең Кортылыш бәйрәме.
4. Мөхбир.
5. Гәзитә «Копейка».
6. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| // *(8а кәгазь) каралган [мәсьәләләр]* | *чыгарылган [карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Кичә хакында. | 15 нче октябрьдәге Казан алу көне мөнәсәбәте илә эшләнә торган кичәнең программасы төзелә.<br>1. Казан алу тарихы – Мәдинә Әхмәди.<br>2. Хәтем.<br>3. Һәйәтләрдән һәм теләгән кешеләрдән сүзләр.<br>4. «Хан мәсҗеде» (шигырь) – Мансур.<br>5. «Татар» – Шаһвәли.<br>6. «Пар ат» – Исхак.<br>7. «Сөембикә манарасы» – Гайниҗамал.<br>8. «Татар иле» – Латыйфа.<br>Хәнифә ханымның иштиракь итүен сорап хат язарга. Белдермәләр язу Әхмәдигә тапшырыла. |
| [2.] Тарих. | 21-ендә Шакир әфәнде Баязидов тарафлы тарих укылачак. |
| [3.] Кортылыш бәйрәме. | Кортылыш бәйрәме 28 нче октябрьдә ясарга карар ителә. Бу тугрыда мөфассаль рәвештә сөйләү киләчәк җыелышта булачак. |
| [4.] Мөхбир. | Мөхбир уларак К.Әхмәди сайланган булса да, рәиснең мөхбир булуыны уңайсыз булганга, аның урынына Шакир әфәнде Баязидов мөхбир уларак сайлана һәм аны һәр җыелышка чакыру тиешле табыла. |
| [5.] Газета «Копейка». | Газета «Копейка» өчен Сөнәгать әфәндегә бушлай алдыру өчен рәхмәт хаты язарга. |

| | |
|---|---|
| [6.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Нәүбәттәге мәсьәләләрдә идарәдән кичә эшләү турында язылган хат укыла. Бу турыда ике идарәнең һәйәтенә тапшырыла. Кичә куела калса, татар бинасы файдасына дип куелу тиешле табыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар]: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*

// *(9а кәгазь)* Протокол №6

1934 ел 18 нче октябрьдә булган Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышының протоколы. Хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли, Мансур, Латыйфа ханым, Мәдинә ханым.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Кумамотодан килгән хат.
2. Кортылыш бәйрәме.
3. Тарих сөйләү.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *каралган [мәсьәләләр]* | *чыгарылган [карарлар]* |
|---|---|
| Кумамотодан килгән хат. | Кумамотодагы Идел-Урал Мәдәният җәмгыятеннән безнең Мәдәни җәмгыятенә килгән тәбрик хаты укыла. |
| 2. Кортылыш бәйрәме. | Октябрьнең 28-ендә Төркиянең Кортылыш бәйрәме булганга, шул көнне кичә ясап, төрек тарихы турында мәгъруза эшләргә.<br>Мәгъруза эшләү Мансур әфәндегә тапшырылды. Кичәгә хәзерләнү өчәүгә (Мансур, Шаһвәли, Исхакка) тапшырылды. |
| 3. Тарих сөйләү. | 21 нче октябрьдә Шакир әфәнде Баязити тарафлы татар тарихы сөйләнә башланачак. Тарихтан соң, вакыт рөхсәт итсә, «Япон мөхбире»ннән язылган ялган хәбәр һәм Галимҗан Идриси тарафлы язылган кара тапны халыкка ялган хәбәр икәнлеген белдереп сөйләү К.Әхмәдигә тапшырылды. |
| 4. Нәүбәттәге мәсьәлә. | 14 нче октябрьдә булып узган (Казан алу) мәҗлесендә иштиракь итәр өчен Милли идарәгә хат язылса да, нәмәгълүм сәбәпләргә бинаән Милли идарә тара- |

| | |
|---|---|
| // *(9б кәгазь)* «Слово» газетасындагы язма | фыннан бер вәкил дә булмады. Мәдәният җәмгыятен гаҗәпләндерде.<br>«Слово» газетасында мәдәни җәмгыять тарафлы куелачак кичә турында язылган хәбәр Мәдәният җәмгыятен хәбәрләндерде һәм моннан соң Мәдәният җәмгыятенә хаклы булган мәсьәләләр тугрында башка халыкның чыгу катгый рәвештә мәмнуг булырга тиеш. |

Рәис:
Сәркятиб:

Протокол №7

1 нче ноябрь 1934 ел. Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Мәдинә, Латыйфа ханым, Гайнинҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Зур кичә эшләү.
2. Төркия сәфиренә хат язу.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кичә эшләү. | Зуррак рәвештә бер кичә кую хакында фикер алышканнан соң мәгълүм була – рамазан аена кадәр кичә куя алмаячакбыз.<br>Гаеткә кичә кую тугрында киләчәк җыелышта тикшерергә калдырыла.<br>Сәхнәдә шушы нәрсәләр уйнау мәгъкуль табыла: «Ямьсез тормыш» һәм «Хат болгатты». |
| 2. Японияддәге Төркия сәфиренә хат язу. | Кортылыш бәйрәме белән тәбрикләп сәфиргә хат язарга карар ителде.<br>Мәҗлес шуның белән ябылды. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(10а кәгазь)* Протокол №8

9 нчы ноябрь 1934 ел. Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Кичә хакында.
2. Газета тугрында.
3. Исмәгыйль Гаспралы.
4. Музыка һәм ноталар.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кичә хакында. | Ишетелүгә күрә, Ата-аналар һәйәтендә мәктәп файдасына кичә кую тугрысында хосусый рәвештә әгъзаларыбызга сөйләгәнгә, башта аларның фикерен белергә. Кадыйр әфәнденең тәкъдиме: Ата-аналар һәйәтенең соравы буенча мәктәп файдасына кичә кую. |
| 2. Гәзитә хакында. | К.Әхмәди тәкъдим итә: Мәдәният җәмгыятенең матди ягын яхшы тоту өчен берничә татар телендә гәзит чыгарырга. Шул гәзитәгә фирмалардан игъланнар җыярга. Гәзит чыгарырга беркем дә каршы килми. Фәкать күп игъланнар җыелганда гына безгә файда булачагын күздә тотып, К.Әхмәдигә тапшырыла шул турыда мәгълүмат җыеп киләчәк җыелышка гарыз итәргә. Гәзитәнең мәфһүме тәкърибән ошбу булачак: төрк дөньясының азаккы вакытта тоткан юлы. Корбангали мәсьәләсе. Мәдәният җәмгыятенең тоткан юлы һәм өч айлык эшләре, гомумән информация[9]. Үзебезнең Шанхай язучыларыбызның әсәрләре. |
| // *(10б кәгазь)* 3. Исмәгыйль Гаспралы. | Бабамызның «Телдә, фикердә, эштә берлек» шәгаре безнең тоткан юлыбыз булганга, шуны күз алдыбызда булу тиешле табыла һәм шуны язып диварга эләргә карар ителә. «Мәдәният җәмгыятенең тоткан юлы – бөек бабамыз Исмәгыйль Гаспралы «Телдә, фикердә, эштә берлек» шәгаре» дип язарга. Язу эше Мансурга тапшырылды. |

[9] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

| | |
|---|---|
| 4. Музыка, ноталар. | Кырым татарларының көйләре нотага салынып бер кибеттә сатылуы мәгълүм була. Шуны барып карау Мәдинә ханым белән Мансурга тапшырыла. Ноталар ике данә булып, берсенең хакы – 3,50, икенчесе – 5,50. Шуларның башта берсенә йитәрлек акча табу чараларын күрергә. |
| 5. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Көтепханә ачылу көннәрен һәм сәгатьләрен белдереп диварга язып кую Мансурга тапшырылды. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №9

10 нчы ноябрь 1934 ел. Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышына хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Токио һәм Хайлар Идел-Урал җәмгыятьләренең хатлары.

// *(11а кәгазь)* 2. Газета.

3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Килгән хатлар. | Токио һәм Хайлар Идел-Урал җәмгыятьләреннән килгән тәбрик хатлары укыла. |
| 2. Гәзит турында. | Гәзитне басу юлларын-чараларын күрү К.Әхмәди белән Кадыйр Габдрахманга тапшырыла. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Мансур Арсланбәк, Мәдәният җәмгыятенең әгъзасы ударак, Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булган бер хосусый мәсьәлә белән идарә әгъзаларын таныштырып үтүне тиешле таба.<br>6 нчы ноябрь төнге сәгать 10–11-дә Арсланбәкләр тора торган бүлмәгә Сөнәгать Дүзи килеп, башта «Милли юл»ның 10 нчы санында язылган Шанхай Яшьләр оешмасы турындагы мәкалә[дә] Кәшшаф Әхмәди мак- |

| | |
|---|---|
| | таганлык һәм башка кешеләрнең эшләгән эшләрен юкка чыгарганлык таба[10]. Соңга Мәдәният җәмгыятен бетерергә кирәклекне һәм «Мәдәният җәмгыяте урынына "Идел-Урал" җәмгыятене төзәргә кирәк. Менә шушы көннәрдә шәһәребезгә Гаяз әфәнде килеп чыгачак, нинди йөз белән аны каршы алырбыз?» – ди. Тагы Мәдәният җәмгыятенә төшеп: «Рәис укымаган, надан. Аның урынына мәгълүматлы кеше куярга, мәсәлән, сез яки Шаһвәлине» дип, сахтә һәм котырту аңкып торган сүзләр сөйли.<br>Сәнгать Дүзи җәен Идел-Урал җәмгыяте корыр өчен җыелган гомуми җыелышта кемгә дә күрсәтелмәгән «хосусый» хатка таянып, Идел-Урал җәмгыятене корырга // *(11б кәгазь)* кирәкмәгәнлегене сөйләү аркасында, халыкның фикере икегә аерылып, Идел-Урал җәмгыяте төзелмичә калуга Дүзи сәбәпче икәнлегене һәркем белә. Инде хәзер бу әфәнде Идел-Урал корырга кирәк ди. Ни өчен бу әфәнде һәйәтләр белән уйный? Мәдәният җәмгыяте Идел-Урал җәмгыяте эшли торган эшләрне алып бара. Шул җәмгыятькә әүвәл баштан ук гакселхәрәкәттә булды һәм шуны һаман дәвам итә. Шуңа күрә бу әфәндегә, Мәдәният җәмгыятенең эшләп баруына аяк чалган өчен, мондый эшләрен ташлавын белдереп тәнбиһ хаты язарга карар ителә. Моннан соң да дәвам итсә, иҗтимагый хәятнең каты җәзаларын анарга биреләчәк. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №10

15 нче ноябрь 1934 ел. Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар, Зиннур, кунак уларак Хәсән әфәнде Ибраһим.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[10] Бу мәкаләнең тексты шушы җыентыкның кушымтасында басылды.

Көн тәртибе:
1. Гәзитә.
2. Әдәбият кичәсе.
3. Мукден, Харбинга хат.
4. Харбиннан хат.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.
[6. Әгъзалар тугрында.]

| // *(12а кәгазь)* *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Гәзитә хакында. | Гәзитәне бу йирдә бастырудан Нанкиндә бастыру уңайрак булмасмы дип сөйләшү өчен һәм Хәсән әфәндетенең гәзит бастыру эшләрен яхшы белгәнгә, аны бу мәҗлескә чакыру тиешле табылды. Хәсән әфәнде Нанкингә кайткач, бу мәсьәлә тугрында мөфассаль рәвештә белгәч, хат язып белдерергә булды.<br>Моннан соң Мәдәният җәмгыятенең өч айлык эшләре тугрында К.Әхмәди Хәсән әфәндене, милли эшләр белән янучы бер зат улганга, таныштыы[р]уны тиешле таба һәм шул тугрыда мәгъруза эшли.<br>Мәгъруза беткәч Хәсән әфәнде: «Узган ел Яшьләр оешмасының эшләре тугрында бераз таныш идем һәм хәзерге Мәдәни җәмгыятьнең эше барышы тугрында мине таныштыру өчен рәхмәтләр укыйм. Бу йиргә килмәс борын мин Мәдәният җәмгыяте тугрысында күңелсез хәбәрләр ишеткән идем – “Сез Гаяз әфәнде сызган юлдан бармыйсыз”. Бу хәбәрләр, алай булса, ниндидер кара көчләр тарафлы таратылды».<br>К.Әхмәди андый кара көчләр барлыгын һәм шуларның бере Сөнәгать Дүзи икәнлеген әйтеп, Сөнәгать Мәдәният җәмгыятене җимерергә йөрүе тугрында мәгълүмат бирелә.<br>Кадыйр әфәнде Милли идарәнең тарихын сөйли. «Идарәгә Сөнәгать советник булып биш ел буе торган вакытта фәкыйрьләргә 2–3 тәнкә ярдәм итүдән башка бер эш эшләмәгәнене, хәзер Мәдәният җәмгыяте аның катнашыннан башка үзенең милли вазыйфасын матур итеп йиренә йиткереп баруы «мин генә бар эшне эшләдем» дигән кешегә, әлбиттә, бик күңелсез. Шуңа күрә |

| | |
|---|---|
| | төрле юллар белән ул аның эшенә каршы төшә» ди. |
| | Шаһвәли әфәнде: «Сөнәгать Дүзи җәен “Идел-Урал” җәмгыяте корырга теләгәндә каршы төште, ул һәркемгә мәгълүм, монда сөйләнгән сүзләр барысы дөрест» – ди. |
| | Сөнәгать Дүзинең Мукденда иҗтимагый эштә ямьсез роль // *(12б кәгазь)* уйнаганлыгы турында Хәсән әфәндедән сөйләвен үтенелә. |
| | Хәсән әфәнде: «Мукден идарәсе икегә аерылу вакытында мин анда юк идем. Ләкин Мукденга кайткач миңа Сөнәгать Дүзи фикеремне белергә теләп “Кемдә гаеп?” диюгә мин “Гаеп сезнең якта” дим. Мәсьәлә башлана идарә эшләгән зур кичәдә. Сөнәгать Дүзигә идарәгә шул тапшырмаганлыктан, яңы идарә төзелә. Абызов идарәдән чыгарыла. Дүзи аның белән бергә булып, икенче идарә төзде. Беренче идарәне таратырга сәбәпче булды. Яшьләр оешмасы төзелә, Сөнәгать Дүзи шуны тәсдыйк итәргә барганга каршы полисага донос эшли. Димәк, тарих кире кайта. Гаяз әфәнде Ерак Шәрыккә килеп, истикъляль алып барырга хәзерләү өчен корылмаган йирләрдә оешмалар кора, корганнарын тугры юлга күндерә, Шанхайда Мәдәният җәмгыяте Гаяз әфәнде корган юл белән бара. Хәзердә шундый вакыйгалар чыгу, әлбәттә, бик күңелсез. |
| [2.] Мукденга, Харбинга хат. | Тәкъдим ителә: Сөнәгатьнең Мукденда эшләгән эшләре тугрысында Мукден Милли идарәсенә һәм Харбинда Ибраһим Дәүләтгилдигә хатлар язу. |
| | Шаһвәли: «Сөнәгатькә тәнбиһ хаты йибәрелгән, бәлки ул гафу үтенер. Шуңа, хәбәр булганчы, хатлар язмаска». Бу тәкъдимгә башкалар да кушыла. Фәкать Кадыйр үз фикерендә кала. |
| [3.] Әдәбият кичәсе. | Алдагы якшәнбә, ноябрьдә Әдәбият кичәсе эшләргә, шунда Хәсән әфәндедән үтенергә Ерак Шәрыктәге Идел-Урал турында мәгъруза эшләүне. Хәсән әфәнде кабул итә. |
| | «Ике хәзрәт» икенче кат уйнарга. |
| | Кичәнең программасын төзү Латыйфа, Гайниҗамал, Мансур, Шаһвәли әфәнделәргә тапшырыла. Керү хакы – буш. |
| *//(13а кәгазь)* | Харбиннан мәрхүм Гыйнәятулла хәзрәтнең кабе- |

| | |
|---|---|
| [4.] Харбиннан килгән хат. | ренә истәлек ташы кую өчен төзелгән һәйәтнең килгән хат[ы] укыла[11] һәм иганә җибәрү өчен иганә кәгазе йибәрелүе мәгълүм була. Әдәбият кичәсендә халыкка буны мәгълүм итәргә, Висайдта[12] иганә җыю Кадыйр[13] әфәндегә тапшырыла. |
| [5]. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Җыелыш дәвам иткәндә К.Әхмәдигә Милли идарәдән мәктүб тапшырыла. Мәктүб укылып чыга. Фикер алышканнан соң, бу хатта язылган мәсьәләләр Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булганга, бу хатка җавап бирү Мәдәният җәмгыятенең эше. Мәктүбтә К.Әхмәди «Милли юл»ның 10 нчы санында язган мәкаләсе өчен гаепләнә. |
| [6.] Әгъзалар тугрында. | Гомуми җыелыш буенча әгъза булып күренеп тә, шушы көнгәчә әгъзалык бәдәле түләмәгән кешеләргә хатлар язып, үзләрен әгъза итеп саныйлар[мы]-юкмы – шуны белергә хат язылган. Мөхәммәтнур Хәлиуллин, Сәйфи әфәндегә, Сөнәгать Дүзигә 14 нче ноябрьдә тәнбиһ хаты йибәрелгән. |

[Рәис]: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъза]: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №11

17 нче ноябрьдә 1934 ел булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Милли идарәгә җавап хаты.
2. Гаризалар.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

[11] Бу һәйәт Гыйнәятулла хәзрәтнең вафатына 8 ел тулу уңаеннан каберен зиярәт иткәндә Гаяз Исхакый тәкъдиме белән оештырылган. Гыйнәятулла хәзрәткә кабер ташы 1935 елның 9 июлендә куелган.

[12] Висайд – урам исеме. Ул мондагы беркетмә текстларында «Шанхай төрк-татарларының милли вә дини оешмасы» (Милли идарә) урнашкан адрес буларак телгә алынган.

[13] Бу исем урынына документта ялгыш «кайбер» дигән сүз язылган.

| // *(13б кәгазь) [каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Милли идарәгә җавап хаты. | Милли идарә тарафлы К.Әхмәди исеменә йибәрелгән хат, канцелярия хаталыгы белән генә анарга йибәрелгән булып, мәфһүме Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булганга, маддәләп тикшерелә һәм җавап язылә.<br>Җавап 3 маддәгә бүленеп, кыскача мәфһүме ошбу:<br>1. Мәдәният җәмгыяте мөстәкыйль оешма, гайни максатка эшләгән оешмалар берлән бер юлда бара һәм бер вакыткача үзенең низамнамәсеннән чыкканы юк.<br>2. Яшьләр оешмасы Милли идарәнең тармагы булса да, мөстәкыйль булып эшләп килде. Аның эшләре тугрында «Милли юл»да «Идел-Уралчы» исеменнән язылган мәкалә дөрест табыла.<br>3. Яшьләр оешмасы булганга кадәр кичәләр һәм конферанслар булма[ган]лыгы тугрында Милли идарә үз протоколларыннан тикшерү тәүсыя ителә.<br>Бу хатны алдагы көннәрдә Милли идарәгә тапшырырга карар ителә. |
| [2.] Гаризалар. | Мөхәммәтнур Хәлиуллиннан һәм Сөнәгать Дүзидән Мәдәният җәмгыятеннән әгъзалыктан чыгуларын белдереп язылган гаризалары укыла һәм кабул ителә. |
| [3.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Мәдәният җәмгыятенең тәнбиһ хатына каршы Сөнәгать Дүзидән килгән хатның конверты К.Әхмәди белән Мансур Арсланбәккә язылса да, «Ачык хат»ы Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булганга, бу хатны хәзергә тикшерү тиешле табылмый. Ләкин Сөнәгать Дүзинең эшләгән эшләре тугрында тәфтиш папкасы ачып, шунда бар мәгълүматны җыярга һәм бу хатны да шунда беркетергә. Дүзинең үзенә идарә исеменнән кыска гына хат язып, йибәргән хатын тикшереп, тәфтиш папкасына беркетелгәнлекне белдерергә һәм шулай ук истигъфасы кабул ителгәнлекне дә белдерергә карар ителде.<br>Дүзи тугрында мәгълүматны Мукден һәм Дәүләтгилдидән язып сорарга. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*

Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(14а кәгазь)* Протокол №12

28 нче ноябрь 1934 ел идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Кадыйр Габдрахмани, Мәдинә, Латыйфа һәм Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Милли идарә хаты.
2. Дүзи тәкъдиме.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Милли идарәнең хатына җавап. | Милли идарәнең 273 сан берлән килгән хатына җавап уларак, 17 нче ноябрьдә Мәдәният җәмгыяте үзенең җавабын биргәнлекне тәкрарларга. |
| 2. Дүзи тәкъдиме. | Шанхай Төрк-татарларының милли вә дини оешмасына һәм Шанхай Төрк-татарлар мәдәният җәмгыятенә язган Дүзинең «тәкъдим»е укыла. Бу затның иҗтимагый хәяттә ямьсезлек күреп тә, хәзер бар мәсьүлиятне ике оешма өстенә ташлап, үзе читтә калу нияте белән язылган хаты тикшерелмичә, үзенә кире кайтарылып йибәрелә. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Гаяз әфәнденең килү вакыты безгә мәгълүм булмаганга – аны ни рәвештә каршы алу мәсьәләсе хәзергә ачык кала. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(14б кәгазь)* Протокол №13

5 нче декабрь 1934 ел җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, К.Габдрахмани, М.Арсланбәк, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:
1. Гаяз әфәнденең хаты.
2. Кичә.

| *каралган мәсьәләләр* | *чыгарылган карарлар* |
|---|---|
| 1. Гаяз әфәнденең хаты. | Гаяз әфәндедән килгән хат укыла һәм аны бу йиргә чакыртыргамы дигән мәсьәлә тикшерелә. Әлбәттә, Гаяз әфәнде килсә, безнең гайре табигый төс алган иҗтимагый хәятебез төзәлер иде. Милләткә җинаять итүче Сөнәгать Дүзинең эшләренә чик куелыр иде. Ләкин Гаяз әфәнденең алдында зур мәсьәлә – Корылтайга хәзерлек торганга, аны үзебезнең шау-шу өчен генә бу йиргә чакырып борчу тиешле табылмый. Фәкать үзебезнең әхваль белән аны таныштыр[у] өчен бар мәсьәләне яшерен аяк язу тиешле табыла.<br>Шанхай Мәдәният җәмгыяте Гаяз әфәндегә каршы бер оешма дип танылмасын өчен һәм эшләгән эшләребез, тоткан юлыбыз ул теләгән юл белән барамы-юкмы икәнлеген белер өчен һәм, гомумән, без аны аңладыкмы? Шуларны үзебез белеп һәм Гаяз әфәндегә белдерер өчен Мәдәният җәмгыятенең бар эшләгән эшләрен, протоколларын, Дүзи һәм Милли идарә белән язышкан хатларның копияләр[р]ен алып, // *(15а кәгазь)* Гаяз әфәндегә йибәрергә тиешле табылды. Бу эшләр күп вакытка тартылу күздә тотылып, шушы көннән үк бу эшләргә тотынырга карар ителә. |
| 2. Кичә. | Гаяз әфәнденең хатыннан аңланыла – ике якка бүленгән халыкларны ничек тә берләштерү юлларын табу кирәклеге. Шуңа күрә, безгә аерылган халык арасына кереп эшләү кирәк. Аны хәзергә фәкать кичә белән генә эшли алабыз. Алар үзләре дә бездән кичә куюны сораганнар иде. Шуның белән файдаланып, бигрәк тә аларны кызыктырыр өчен, файданың 25 фаизын аларга тәгаенләп бер кичә эшләргә кирәк. Бу хакта башта үзебезнең Милли идарәнең президиумы белән сөйләшеп, соңга өч идарә бергә бер утырыш эшләргә тиешле табыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәте: *Г.Ильясия*

Протокол №14

16 нчы декабрь 1934 елда булган Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, К.Габдрахмани, М.Арсланбәк, Л.Габдрахмани, М.Әхмәди, Г.Ильяси.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. К.Әхмәдинең мәгърузасы.
2. Мәктәп мәсьәләсе.

[3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.]

| // *(15б кәгазь) [каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. К.Әхмәдинең сүзе. | 15 нче декабрьдә Милли идарә җыелышына чакырылып, Милли идарәнең рәисе Әүхәди Җамал тарафлы миңа Мәдәният җәмгыятеннән китү таләп ителә. Сәбәп уларак халык мине теләмәү күрсәтелә. Мин сөальгә: «Ул кем уларак бу сүзне әйтә?» диюемә, Милли идарә исеменнән әйткәнлеген белдерә. Мин боңа Милли идарәнең миңа буны таләп итәргә һич хаккы юкны – «Чөнки без бер мөстәкыйль оешма» дигәч, Рәхмәтулла Фәтхуллин: «Юк, без Мәдәният җәмгыятенең әгъзалары уларак әйтәбез» диеп төзәтте. Мин бу сүзгә каршы: «Без бу йирдә Мәдәният җәмгыятенең әгъзалары 2–3 кеше генә. Сез яхшы белергә тиешсез – минем хуҗам гомуми җыелыш булганлыгын. Җыегыз аны, миңа гомуми җыелыш «кит» дисә, мин аңа буйсыначакмын, ә сезнең сүзегез белән мин китәчәк түгелмен» дидем. Сүзгә кителде, тавыш купты. Шунда Гариф Сәйфи миңа: «Син провокатор!» – диде. Мин кызып, өстәл сугып: «Телегезне кыскартыгыз! Күрсәтегез минем провокаторлыгымны!» – дигәч, «Син “Милли юл”да да провокационный чыктың!» – диде. Тавыш зурайды. Мин җыелышны ташлап чыктым. Мәҗлеснең рәисе: «Вон![14]» дип кычкырып калды.<br>Кадыйр: «Мәдәният җәмгыяте мөстәкыйль оешма. Милли идарәнең һич хаккы юк үз җыелышына чакырып башка бер һәйәтнең рәисенә: «Син кит!» дип әй- |

[14] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

| | |
|---|---|
| | тергә. Әгәр алар коткы белән йөрмәсәләр, хакыйкатьне генә күздә тотсалар иде – алар безнең җыелышка килеп, Мәдәният җәмгыятенең әгъзалары уларак, шул мәсьәләне безгә гарыз итәргә. Ләкин алар фетнә генә таратталар. Аларның дөрест юл белән баруларына безнең иманыбыз югалды. Икенче көчкә таянып, урынсыз йирдә фикерләрен әйтәләр. Шуңа күрә, Мәдәният җәмгыятенең әгъзалары саналган Рәхмәтулла Фәтхулла һәм Әүхәди // *(16а кәгазь)* шул оешманың дисциплинаны[15] бозулары өчен тәртипкә тартырга, Гариф Сәйфине чакырып, нинди мәнбәгъдән алып «Ул провокатор» дип әйткәнен сорарга. Гомумән, бу халык үзләренең ямьсез хәрәкәтләре аркасында Милли идарәне түбәнсеттеләр.<br>Бу фикергә бар идарә әгъзалары кушыла. |
| [2.] Мәктәп мәсьәләсе. | Мәдинә ханым югарыда язылган вакыйгадан соң Милли идарә мәктәбендә укытмаячагын белдерә. Милли идарә Сәйфинең әйтелгән сүзләрен әйтелмәде дип тана. Ләкин Мәдәният җәмгыятенең 4 кешесе һәм читтән бер кеше бу сүзләрне ишетеп тордылар. Балаларны мәктәпсез калдырмас өчен Мәдәният җәмгыяте үзенең низамнамәсе буенча курслар ачарга имкяне бар. Шуңа күрә дин, татар тел[е] дәресләре өчен Мәдәният җәмгыяте курслар ача. Бина Милли идарә белән уртак булганга, шинбә көн 3–4-кә, якшәнбә көн 12–4 сәгатьләргә Мәдәният җәмгыятенә бина кирәклеген белдереп, Милли идарәгә хат язарга карар ителә. |
| [3.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Хәсән Ибраһимнан килгән хатта газетны Нанкиндә бастыру кыйммәтрәк һәм уңайсызрак булганлыгын яза. Шуңа күрә газетны Шанхайда бастыру чараларын күрү тиешле табыла. Ләкин бу, үз арада чыккан гайре табигый мәсьәләләр аркасында, гәзит чыгару мәсьәләсен соңга калдырырга мәҗбүр итә.<br>Ибраһим Дәүләтгилдинең Сөнәгать Дүзинең Мукден иҗтимагый хәятендә тудырган җинаятьләре тугрында язган хаты укыла һәм Дүзинең эшләре өчен ачылган папкага беркетелә. |

Рәис: *К.Әхмәди*

[15] «Дисциплина» сүзе рус хәрефләре белән язылган.

Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәте: *Г.Ильясия*

// *(16б кәгазь)* Протокол №15

20 нче декабрь 1934 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа Габдрахман, Гайниҗамал Ильяси, Мансур Арсланбәк, Мәдинә Әхмәди, Кадыйр Габдрахман.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Мәктәп мәсьәләсе.

| *[каралган мәсьәлә]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәктәп мәсьәләсе. | 18 нче декабрьдә ата-аналар һәм Милли идарә белән бергә булып узган җыелыш мәктәп мәсьәләсен чишә алмады, нәтиҗәсез үтте, хәзерге көнне үзара һич аңлашу булачак түгеллекне күрсәтте. Милли идарәдә Сәйфи дә «провокатор» сүзе әйтмәде дип таналар.<br>Мөгаллимә: «Бу сүз әйтелде һәм бу сүз бер К.Әхмәдине генә пычратмый, аның гаиләсенә дә гомерлек тап булып калганга», әгәр дә Сәйфи бу сүзне кайтарып алмаса, Милли идарә исеменнән мәктәптә укытучы булмаганлыгын сөйләсә дә, Милли идарә бу сүзләргә игътибар итми, үз сүзендә кала. Мәҗлес бер нәтиҗәсез тарала.<br>Балаларны укудан мәхрүм итмәс өчен Мәдәният җәмгыяте үзе мәктәпне ала. Шуны белдереп Милли идарәгә хат яза. Әгәр Милли идарә мәктәп өчен бүлмәне бирмәсә, Украина иптәшләребездән аларның бүлмәсен атнасына ике көнгә сорарга карар ителә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(17а кәгазь)* Протокол №16

26 нчы декабрь 1934 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Мәдинә, Гайниҗамал.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Гаяз әфәнденең хаты.
2. Гаяз әфәндегә язылган мәгъруза.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Гаяз әфәнденең хаты һәм каршы җавап. | Гаяз әфәнде үзенең моннан алда Шанхай әхвален сорашып язган хатына җавап шушы көнгәчә алынмаганга, тагын шуны катлап сорап яза һәм үзенең пошынуын белдерә.<br>Мәдәният җәмгыяте үзенең 5 нче декабрьдә булган җыелышында чыгарган карары буенча үзенең эшләгән эшләре, тоткан юлы һәм, гомумән, Шанхай әхвале тугрындагы мәгърузасы һәм протоколларның копияләре язылып хәзер булганга, шушы алдагы көннәрдә шуларны Гаяз әфәндегә йибәрергә карар ителә. |

Рәис: *К.Әхмәди*

Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*

Әгъзалар: *Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(17б кәгазь)* Протокол №17

6 нчы гыйнвар 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли, Мансур, Кадыйр, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Кобе мәркәзенең хаты.
2. Корылтайда иштиракь итү, мәгърузалар.
3. Вәкил.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кобе мәркәзеннән | Кобе мәркәзеннән февраль аеның башларында Мукден шәһәрендә булачак корылтай һәм шунда Мәдәният |

| | |
|---|---|
| килгән хат. | җәмгыятеннән вәкилләр сайланып йибәрелергә тиешлеге тугрындагы хат һәм Беренче Ерак Шәрык корылтаена сайлау низамнамәсе белән булачак корылтайның программасы укылып чыгыла.<br>Бу хәбәрне Мәдәният җәмгыяте зур шатлык белән каршы ала. |
| 2. Корылтайда иштиракь итү. | Мәдәният җәмгыяте корылтайда ничек кенә булса да иштиракь итәргә тиеш һәм үз тарафыннан мәгърузалар хәзерләргә бүгеннән үк башларга тиешле таба.<br>Мәгърузалар хәзерләү эшен кешеләргә тапшырыла:<br>1. Шанхай иҗтимагый тормышының тарихы – Кадыйр Габдрахман.<br>2. Шанхай Яшьләр оешмасы һәм // *(18а кәгазь)* Шанхай Мәдәният җәмгыятьләренең тарихлары һәм эшләгән эшләре тугрында – Шаһвәли Келәүле.<br>Мәктәп мәсьәләсе – Мәдинә Әхмәди.<br>Милли фонд – Кәшшаф Әхмәди. |
| 3. Вәкил тугрында | Мәдәният җәмгыяте корылтайга ничек кенә булса да бер вәкил йибәрергә тиеш. Ләкин Мәдәният җәмгыятенең әгъзаларының матди яклары агыр булганга, бүген үк катгый карар ул тугрыда чыгарып булмый. Кирәк читтән ярдәм эзләргә. Шул эш Мәдәният җәмгыятенең һәр әгъзасына йөкләнелә.<br>Вәкил უларак Мәдәният җәмгыяте Кәшшаф Әхмәдине күздә тота. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №18

10 нчы гыйнвар 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахмани, Мәдинә Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле, Гайниҗамал.

Көн тәртибе:

1. Иганә кәгазе.
2. Гомуми җыелыш.

3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Иганә кәгазе. | Шәһәребезгә Япониядән килгән Гамилә ханым Мәдәният җәмгыятеннән корылтайга вәкил йибәрүдә ярдәмдә // *(18б кәгазь)* булачагын белдереп, үз ягыннан 30 иен [бирәчәген] әйтә. Ләкин ул акчаны Япониягә кайткач йибәрергә була. Дәхи белеш-танышлары арасыннан шул максатка акча җыяр өчен иганә кәгазе сорый. Мәдәният җәмгыяте Гамилә ханымның һиммәтенә зур рәхмәтләр укый һәм шуны белдереп аңа язу язарга һәм дә иганә кәгазе хәзерләп бирергә карар итә. Җыйган акчаларны Гамилә ханым 20 нче гыйнвардан соңа калдырмый йибәрергә вәгъдә итә. |
| 2. Гомуми җыелыш. | Гамилә ханымның вәгъдәсеннән соң Мәдәният җәмгыяте корылтайга вәкил йибәрә алачагына иманы ныгый. Бер иганә кәгазе әҗнәбиләр арасында җыяр өчен Шәрәфи әфәнде Мөхәммәтҗановка бирергә карар ителә. Һәм вәкил сайлар өчен гомуми җыелыш тугрында фикер алышылына. Бәгъзе сәбәпләргә бинаән, гомуми җыелыш соңгарак эшләргә тиешле табыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №19

12 нче гыйнвар 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбик, Кадыйр Габдрахман, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Милли идарәдән килгән чакыру кәгазе.
2. Кичә мәсьәләсе.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Милли идарәнең хаты. | Милли идарә 12 нче гыйнварга кичен Мәдәният // *(19а кәгазь)* җәмгыяте әгъзаларын үзенең идарә җыелышына чакыра. Нинди мәсьәлә тугрында чакырылу күрсәтелмәсә дә, соңгы вакытларда үзара чыккан низаг тугрында булырга тиеш дип уйланыла. Мәдәният җәмгыятенең әгъзасы Шаһвәли Келәүле Милли идарә белән соңгы вакытларда чыккан низаглар вакытында шәһәрдә булмаганга, кайтуы белән аңа бу тугрыда Мәдәният җәмгыяте үз тарафыннан тулы мәгълүмат бирде. Икенче тарафтагы мәгълүмат белән танышып, бу чыккан кызу мәсьәләләрдә битараф калганлыгы сәбәпле, Мәдәният җәмгыяте аңа ирек бирде үз исеменнән (Шаһвәли) низагларны бетерү чараларын күрү юлында тәшәббестә булуны. Шаһвәли әфәнде Милли идарә әгъзалары белән хосусый рәвештә сөйләгән шул сүзләрнең нәтиҗәсе уларак, ошбу җыелышта тәгаен ителгән булырга тиеш.<br>Хәзер бу җыелышта Мәдәният җәмгыяте нинди юл тотарга тиеш?<br>Кадыйр: «Безнең үзебезнең платформабыз булырга тиеш. Платформа уларак Мәдәният җәмгыятенең мөстәкыйль оешма икәнлеген алабыз һәм шул ноктаи нәзардан сөйләргә тиешбез» ди.<br>Бу фикергә башкалар да кушыла.<br>Мәдәният җәмгыяте килешүгә каршы түгел, мәктәпне дә кире бирә. Ләкин «коткы белән әйтелгән нахак сүзләр кире алынсын» ди. |
| 2. Кичә мәсьәләсе. | Килешү булып, алда кичә мәсьәләсе чыкса – Мәдәният җәмгыяте кичәне Шанхайдагы бар оешмалар белән бергә кую фикерендә булырга тиеш. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(19б кәгазь)* Протокол №20

23 нче гыйнварда 1935 елда булган Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Корылтайга язылган мәгърузаларны тикшерү.
2. Вакытлы рәис сайлау, сәркятиб сайлау.
3. Гомуми җыелыш эшләү.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәгърузалар тикшерү. | 1. Кадыйр әфәнде тарафлы язылган «Шанхай иҗтимагый хәяте тугрындагы тарихи мәгъруза»да күп йирдә аерым шәхесләргә тию күренә. Мәдәният җәмгыяте корылтайга шәхесләр, низаглар тугрында бер нәрсә белән дә керергә тиеш түгел. Шуңа күрә Кадыйр әфәнденең мәгърузасы төзәтелергә, шомартылырга тиеш.<br>2. Шаһвәли әфәнде Шанхай төрк-татарларының Яшьләр оешмасы һәм Шанхай Мәдәният җәмгыятьләре тарихлары, эшләгән эшләре тугрындагы мәгърузасы укылып чыгыла. Мәгърузаның бер йирендә Мәдәният җәмгыяте хәятендә килеп чыккан фетнәчеләр һәм шуннан туган низаг тугрындагы йирен төшереп калдырырга, башка йирләре мәгърузаның бик яхшы табылып, кабул ителә.<br>3. Мәдинә ханым тарафлы урта мәктәп тудыр[у] тугрындагы мәгъруза укылып чыгыла.<br>Имля мәсьәләсендә байтак фикер алышына. Мансур әфәнде: «Иске имля булырга тиеш», – ди. Шулай ук «Латин хәрефләренә дә күчәргә тиеш түгелбез, аның өчен – Коръәнебез гарәп хәрефләр[е] белән язылган» – ди. Мәгърузачы // *(20а кәгазь)* яңы имляның һәр тавыш өчен төзек хәрефе булуы, балалар өчен шуның уңайлылыгы мисаллар белән күрсәтеленә. «Латин хәрефләренә без шулай ук күз йомарга тиеш түгел. 35 миллион Россиядәге төрк-татарлар һәм 18 миллион Төркия төркләре шул хәрефләр белән язалар» – ди. Мәгърузада бөтенләй |

| | |
|---|---|
| | латинга күчү әйтелмәгән, гарәп хәрефләре кала, ләкин латин хәрефләре дә күрсәтелергә тиеш. Яңы имля белән язганда Коръән укыр өчен гарәп әлифбасы искечә кала.<br>Кадыйр әфәнде: «Бер имля мәктәпләр өчен генә булмый, бар матбугатыбызга шул бер имля булдыры[р]га тиеш» – ди. «Беренче башлангыч мәктәпләребезнең программалары башка әҗнәби мәктәпләре белән бер булырга тиеш» тәклифен кертә. Мәгъруза кабул ителә.<br>4. Кәшшаф әфәнде Милли фонд тугрындагы мәгърузасын укый. «Һәр балигъ булган төрк-татар кенөнә бер тиен милли салым түләргә тиеш» дигән маддәгә Кадыйр әфәнде каршы килә. Ләкин күпчелек бу фикерне яхшы таба һәм мәгъруза кабул ителә. |
| 2. Вакытлы рәис сайлау, сәркятиб сайлау. | К.Әхмәдинең корылтайга китү ихтималы булганга, вакытлы уларак рәис сайланыла. Рәислеккә Шаһвәли Келәүле сайланыла. Исхак Әхмәди китү белән баш сәркятиблеккә Мансур Арсланбәк сайлана. |
| 3. Гомуми җыелыш. | Корылтайга вәкил сайлау һәм мәгърузаларны тәсдыйк иттерү өчен гомуми җыелыш 2 гыйнварга тәгаенләнә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар]: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(20б кәгазь)* Протокол №21

3 нче февраль 1935 елда булган җыелышта хазир булды: Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Латыйфа, Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси.

Рәислек итә: Келәүле.

Көн тәртибе:

1. Корылтайга тәбрик телеграмы.
2. Низамнамә.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Корылтайга телеграм. | Корылтай ачылу көне – 4 нче февральгә Мәдәният җәмгыяте исеменнән телеграм йибәрергә карар ителә һәм мәфһүме төзелә. |
| 2. Низамнамә. | Низамнамә шушы көнгәчә русчага тәрҗемә кылынмаганга, шуны ашыгычлык белән хәзерләргә карарлана. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Кадыйр әфәнде тәкъдим кертә Мәдәният җәмгыятен «Саро»га[16] регистрациягә кертергә. Бу тәкъдим кабул ителә. |

Рәис: *Шаһвәли Келәүле*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъза]: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(21а кәгазь)* Протокол №22

8 февраль 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси.

Рәислек итә: Шаһвәли Келәүле.

Көн тәртибе:

1. Корылтай вәкиленең хаты.
2. Корылтай ачылуын халыкка игълан итү.
3. Кичә мәсьәләсе.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Корылтайдагы вәкилдән хат. | Корылтай ачылгач, вәкил тарафлы язылган хат укылып чыгыла. Мәдәният җәмгыятенең вәкиле корылтайга кертелмәгән диеп халык арасына таратылган сүзнең провокация булып чыгуы җәмгыять әгъзаларын сөендерә. |
| 2. Корылтай ачылуын белдерү. | Халык арасына корылтай 4 нче февральдә ачылуын белдереп, шул шатлык белән халкыбызны тәбрикләп, «Аңлатма» чыгарырга карар ителә һәм мәфһүме языла. |

[16] «Саро» сүзе гарәп хәрефләре белән дә рус хәрефләре белән дә язылган.

| | |
|---|---|
| 3. Кичә мәсьәләсе. | Киләчәктә бер кичә кую алдыбызда торганга, шуңа алдан ук хәзерлек күрергә тиешле табыла. |

Рәис: *Шаһвәли Keләүле*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъза]: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(21б кәгазь)* Протокол №23

12 нче февраль 1935 ел. Җыелышта хазир булдылар: Шаһвәли Keләүле, Кадыйр Габдрахман, Мансур Арсланбәк, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал.

Рәислек итә: Шаһвәли Keләүле.

Көн тәртибе:

1. Корылтайдагы вәкилдән хат.
2. Протест хаты.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Корылтайдагы вәкилдән хат. | 4 нче февральдә Мукден шәһәрендә ачылган корылтайга вәкил итеп йибәрелгән К.Әхмәдидән килгән хат укыла. «Мәдәният җәмгыяте тарафлы йибәрелгән вәкилне корылтайга кертелмәсен» дип, 28 имза белән Милли идарә тарафлы телеграм бирелгәне мәгълүм була. |
| 2. Протест хаты. | Шанхай Милли идарәсенең бу хәрәкәте милли эшкә зур җинаять итеп хисапланып, бу тугрыда корылтайга вәкил сайлаганда Милли идарә үзе нинди янгал юллар тотканын ачып хат язарга карар ителә. |

Рәис: *Шаһвәли Keләүле*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(22а кәгазь)* Протокол №24

19 нчы февраль 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: Шаһвәли Keләүле, Кадыйр–Латыйфа Габдрахмани, Мансур Арсланбәк, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси.

Рәислек итә: Шаһвәли Keләүле.

[Көн тәртибе]:
1. Корылтайдан килгән бюллетень.

| *[каралган мәсьәлә]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Корылтай бюллетене. | Корылтай ачылганнан соң чыгарылган беренче сан бюллетень укылып чыгыла. Ачылу мәрасиме һәм Гаяз әфәнденең нотыгы зур тәэсир калдыра.<br>Корылтай бюллетене бер генә сан килгәнгә, халкыбызның күпчелеген шуның белән таныштырыр өчен бюллетеньнең мөндәрәҗәсен кыскартып, халык арасына «Аңлатма» рәвешендә тарату тиешле табыла. Шуны тизлек белән эшләп бирү Мәдинә Әхмәдигә тапшырыла. |

Рәис: *Шаһвәли Keләүле*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №25

22 нче февраль 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбик, Кадыйр–Латыйфа Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяси.

Рәислек итә: К.Әхмәди.
[Көн тәртибе]:
1. Корылтай вәкиленең мәгърузасы.

| *[каралган мәсьәлә]* | *[чыгарылган карар]* |
|---|---|
| 1. Мәгъруза. | Корылтайдан кайткан Мәдәният җәмгыятенең вәкиле // *(22б кәгазь)* К.Әхмәди үзенең мәгърузасында корылтайның әһәмияте, тоткан юлы һәм эшләгән эшләре тугрында мәгълүмат бирә. Бар Ерак Шәрыктәге оешмаларның вәкилләре күтәренке рух белән милли эшләребезне тикшереп, барыбыз өчен дә бер сызык сыздылар, эшләребезне алып барыр өчен шәгъбәләр төзделәр, низамнамәләр, карарлар чыгардылар.<br>Ерак Шәрыктә милли эшләребезгә аяк чала торган Корбангали һәм руслар һөҗүме вәзгыятебезне ифрат |

| | |
|---|---|
| | агырайта. Шуңа күрә үзара дуслык белән хәрәкәт итәргә безгә куштылар.<br>Мәркәз белән йирле оешмаларны баглар өчен һәр шәһәрдә вәкилләр сайланды, Шанхайдагы Милли идарәдән Рәхмәтулла Фәтхулла, Мәдәният җәмгыятеннән Шаһвәли Келәүле тәгаенләнгәннәрен белдерде.<br>Тиз көннәрдә гомуми халык өчен Милли идарә вәкиле белән бергә мәгъруза эшләүгә карар ителде. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(23а кәгазь)* Протокол №26

26 нчы февральдә 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахмани, Латыйфа, Гайниҗамал, Мәдинә ханымнар, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбик.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Галимәрдан Тупчибаш һәм Мәҗит Гафуриларны яд итү.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Милләтебез өчен гомер буе эшләп, бар көчләрен шул юлда сарыф итүче бөек юлбашчыбыз Галимәрдан Тупчибаш һәм шагыйребез Мәҗит Гафуриларның вафат булулары мөнәсәбәте илән аларның рухына Коръән укып, аларның тәрҗемәи хәле һәм эшләгән эшләре белән халкыбызны таныштырыр өчен мәҗлес эшләү тиешле табыла. Мәҗлес көнен 3 мартка тәгаенләп, Милли идарәдән шул көнгә бүлмә сорап хат язарга карарлана.<br>Тупчибаш тугрында сүз – К.Әхмәдигә, Мәҗит Гафури тугрында – Шаһвәли Келәүлегә тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар]: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №27

1 нче март 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Латыйфа–Кадыйр Габдрахмани, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар, Мансур Арсланбәк.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Кичә эшләү.

2. Хәсән әфәнденең хаты.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1. Кичә эшләү]. | 1. 15 нче мартта, Гает көнендә кечкенә күләмдә кичә кую тиешле табыла. Уйнар өчен // *(23б кәгазь)* Галиәскәр* Камалның «Беренче театр»ы һәм «Өйләндерү» сайланыла. Соңга әдәбият бүлеме булып, мәктәп шәкертләре дә иштиракь итәчәкләр.<br>Уйнаучылар: Гайниҗамал, Латыйфа, Фатыйма, Шаһвәли, Мансур.<br>Кичәнең хисабын алып бару Шәрәфи Мөхәммәтҗанга, музыка – Гали Дүзи, Мансур, Мәдинәгә, сценариус – Гали Дүзи, суфлёр – Мәдинә, режиссёр – Шаһвәлигә тапшырыла. Билет сату – Фатыйма ханым Мөхәммәтҗан, Фатыйма ханым Дүзи, Гали Дүзи, Латыйфа ханым Габдрахманга тапшырыла.<br>Кичәнең фатирасы Мәркәз нәшрият фатирасы дип тәгаенләнә. |
| 2. Хәсән әфәнденең хаты. | Хәсән әфәнде Ибраһимның хаты укылып чыгыла. Хәсән әфәнде мәрхүм Гыйнәят хәзрәтнең кабер[е] өстенә һәйкәл куяр өчен Харбиннан Мәдәният җәмгыятенә йибәрелгән язылма кәгазе алып, Нанкиндә белешләре арасында 32 сум 50 тиен акча җыйганын мәгълүм итә һәм шул акчаны үзе Харбингә йибәрәчәген белдерә. |

Рәис: *К.Әхмәди*

Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*

Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

* Документта: Галигаскәр.

// *(24а кәгазь)* Протокол №28

8 нче март 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Бәйрәм тәбрикләре.
2. Кичә мәсьәләсе.
3. Хатлар.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Бәйрәм тәбрикләре. | Бәйрәм [белән] тәбрикләп ошбу затларга, оешмаларга хатлар язарга: Гаяз әфәндегә, Мәркәзгә, Мукден Идел-Урал җәмгыяте һәм Яшьләр оешмасына, Харбин Идел-Урал җәмгыяте һәм Яшьләр оешмасына, Хайлар Идел-Урал җәмгыяте һәм Яшьләр оешмасына, Чанчунь, Дайрен, Тәнзин, Кейҗо, Нагоя, Токио, Кумамото, Кобе Идел-Урал мәдәният җәмгыятьләренә һәм Нанкиндәге шәркый вә казаший җәмгыятьләренә һәм Хәсән әфәндегә.<br>Шул язулар өчен каты кәгазь алып, шунда Идел-Урал байрагын эшләргә Латыйфа ханым белән Мәдинә туташка тапшырыла. |
| 2. Кичә мәсьәләсе. | Шаһвәли Келәүле: «Кичәнең файдасы Милли идарәгә дә булсын иде» – ди. Бу тугрыда идарәдә бер фикергә дә килә алмыйча, алдагы җыелышка бу мәсьәләне чишүне калдырыла. |
| 3. Хатлар язу. | Хәмит әфәнде Рамазанидан ярты ел «Милли юл» өчен 3 айга һәм Зөһрә ханым Яушевадан ярты ел «Яшь Төркестан» өчен акчаларны сорап, хатлар язарга карар ителә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*



Беркетмәләр дәфтәре. 24а кәгазь.

// *(24б кәгазь)* Протокол №29

10 нчы март 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Кадыйр Габдрахмани, Мансур Арсланбәк, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Кичә эшләү-эшләмәү.
2. Кичәнең файдасы.
3. Көтепханә.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кичә мәсьәләсе. | Кичә мәсьәләсе бер кат каралып, эшләргә тиешбез дип карарланса да, тагын шул тугрыда сүз күтәрелә. Икенче мәртәбә кичә кую тиешле табыла һәм көне 16 нчы мартка тәгаенләнә. |
| 2. Кичәнең файдасы. | Кичәнең файдасы ничек булу тугрысында кыз[у]-кызу сүзләр була. Рәис тәкъдим итә: «Кичә файдасының 50% – Мәркәз нәшрият файдасына, 20% – Милли идарәгә, 30% – Мәдәният җәмгыяте файдасына».<br>Мәдинә ханым: «Кичәнең файдасы фәкать нәшрияткә», Латыйфа ханым: «Милли идарәгә без файда чыгарырга тиеш түгел, аның өчен – алар кичәгә катнашмыйлар һәм карарга да килмиләр» – ди.<br>Уза ошбу тәкъдим: 10% – Мәркәзгә, 30% – Мәдәният җәмгыятенә, 60% – Нәшрият файдасына.<br>Шаһвәли, Милли идарә файдасына 20% файда бирелмәгәнгә, кичәдә иштиракь итмәячәген белдерә. Шуның белән, кыска мөддәт эчендә аның урынына кеше табылмаганга, кичәнең ясалмыйча калуында мәсъүлият Шаһвәли өстендә кала. |
| 3. Көтепханә. | Көтепха[нә]не Милли идарәнең үзенә кире кайтарып бирү эше Кадыйр Габдрахманга тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*

Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*

Әгъзалар:

Тәфтиш һәйәте[нең әгъзасы]: *Г.Ильясия*

// *(25а кәгазь)* Протокол №30

16 нчы март 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Китүче әгъзаларыбызга зыяфәт бирү.
2. Бүләк тәкъдим итү.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Зыяфәт бирү. | Башта Яшьләр оешмасында, соңга Мәдәният җәмгыятендә күп эшләр эшләгән әгъзаларыбыз Мансур Арсланбик белән Шаһвәли Келәүленең Шанхайдан китүләре мөнәсәбәте белән, аларны тәкъдир итү йөзеннән, Мәдәният җәмгыяте зыяфәт бирергә тиешле тапты[17]. Зур күләмдә эшләргә матди ягыбыз кушмаганга, үзара бер мәҗлес эшләп, керү хакын 50 тиен тәгаенләргә һәм Украина иптәшләрдән шул көнгә бина сорарга. Һәр эстәгән кеше бу мәҗлескә иштиракь итә ала.<br>Шул эшне оештыру Кадыйр Габдрахманга тапшырыла. |
| 2. Бүләк тәкъдим итү. | Шаһвәли әфәнде Келәүле белән Мансур әфәнде Арсланбиккә Мәдәният җәмгыяте бүләк бирүне тиешле таба.<br>Әлбәттә, матди ягыбыз кушса иде, бу затларга зур бүләк тә тәкъдим ителер иде. Ләкин матди агырлык кечкенә генә жетоннар гына бирергә рөхсәт итә. Шуңа күрә көмештән ике жетон эшләргә бирү К.Әхмәди белән Гайниҗамал Ильяска тапшырыла. Жетонда «Мәдәният җәмгыятеннән фәлән әфәндегә – милли көрәшчебезгә» дип язылырга тиеш. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәте[нең әгъзасы]: *Г.Ильясия*

[17] Монда М.Арсланбәк белән Ш.Келәүлене Мукден шәһәренә озату турында сүз бара.

// *(25б кәгазь)* Протокол №31

19 нчы март 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Латыйфа–Кадыйр Габдрахман, Шаһвәли Келәүле, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяс.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Зыяфәт тугрында.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Китүче әгъзаларыбыз Шаһвәли, Мансур әфәнделәр шәрәфенә ясалачак мәҗлес 20 нче мартка тәгаенләнелә. Кадыйр әфәнде шул мәҗлескә булган хәзерлек тугрында мәгъруза эшли. Барлыгы 16 кеше язылган, тагын берничә кешенең язылуы күздә тотыла.<br>Өстәл хәзерләү Латыйфа ханым, Гайниҗамал ханым һәм Мәдинә ханымнарга тапшырыла.<br>Мәҗлес Украина клубында булып, сәгать 7-дә башланачак.<br>Мәҗлеснең тәртибе: Мәдәният җәмгыяте исеменнән сөйли – К.Әхмәд[и]. Бүләк бирелә. Соңга Латыйфа, Гайниҗамал, Мәдинә ханымнар һәм эстәгән халыкка сүз биреләчәк.<br>Украина Громадасының һәйәт башкарма әгъзалары кунак уларак чакырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*

Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*

Әгъзалар: *Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(26а кәгазь)* Протокол №32

21 нче март 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк, Латыйфа–Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяс.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Кичә хисабы.
2. Хәзинәдардан хисап алу.
3. Громадага хат.
4. Газетага чыгу.
5. Протокол дәфтәре алу.
6. Хәмид Рамазановка хат.
7. Зөһрә ханымга хат.

8. «Яңы милли юл»га хат.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1-2. Хәзинәдардан хисап алу. | Хәзинәдар Шаһвәли әфәнде китү сәбәпле, анардан бар хисапларны йолыгып, тикшереп алу эше Гайниҗамал ханым белән Кадыйр әфәндегә тапшырыла. |
| 3. Громадага хат. | Украина Громада идарәсенә 20 нче мартка бушлай бина тәкъдим итүләре өчен рәхмәт хаты язу Мансур әфәндегә тапшырыла. |
| 4. Газетка чыгу. | Мансур, Шаһвәли әфәнделәрнең зыяфәтләре турында рус газетасына язу эше Кадыйр әфәндегә тапшырыла. |
| 5. Протокол дәфтәре алу. | Яңы протокол дәфтәре алырга карар ителә. |
| 6-7. Хатлар язу. | Хәмид Рамазанов белән Зөһрә ханыма журналлар өчен тиешле акчаларны сорап язарга. |
| 8. [«Яңы милли юл»га хат]. | «Милли юл» журналының идарәсенә моннан соң фәкать 5 данә генә «Милли юл»ны йибәрүне сорап язарга һәм // *(26б кәгазь)* ай өчен тиешле хисаптан ...[18] акчаны Шаһвәли әфәнде белән Мансур әфәндегә биреп, Мукденда шуны йибәрергә тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №33

31 нче март 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Тукай көнен уздыру.

---

[18] Бу урында ничә сум икәнлеге язылмыйча, буш урын калдырылган.

| [чыгарылган карарлар] |
| --- |
| 17 нче апрельдә, шагыйребез Тукайның үлүенә 22 ел тулу мөнәсәбәте илән, шул көнне ничек тә билгеләп узарга тиешбез. Кичә эшләп, мәгъruзалар укылырга тиеш. Шулай ук мәктәп балалары да бу кичәгә катнашырга тиешләр. Шул көнне рус газеталарында да Тукай тугрында мәгълүмат бирелергә тиеш.<br>Кичә эшләү тугрында фикер йөртү Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнарга тапшырыла.<br>Матди як соңга каралачак. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: [*М.Салиәхмәд*]
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(27а кәгазь)* Протокол №34

10 нчы апрель 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханым.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:
1. Тукай көне.
2. Балалар кичәсе.
3. Йосыф Акчура мәҗлесе.

| [каралган мәсьәләләр] | [чыгарылган карарлар] |
| --- | --- |
| 1. Тукай көне. | Тукай үлгән көнне рус газеталарында чыгарга мөмкин булуны белешер өчен «Заря»[19] белән «Слово»[20] газеталарының мөхәррирләре белән кереп сөйләшү Кәшшаф Әхмәдигә тапшырыла. Әгәр бу газеталар Тукай тугрындагы мәгълүматны басарга алынсалар, шуның белән файдаланып, соңгы көннәрдәге зур югалтуларыбыз – Йосыф Акчура, Галимәрдан Тупчибаш һәм Мәҗит Гафурилар тугрында да мәгълүмат бирүне К.Әхмәди тәкъдим итә. Тәкъдим кабул ителеп, эш бүленә:<br>Тукай тугрында язу – М.Әхмәдигә,<br>Мәҗит Гафури – Шакир Баязид, |

[19] «Заря» сүзе гарәп хәрефләре белән дә, рус хәрефләре белән дә язылган.
[20] Бу атама рус хәрефләре белән язылган.

| | |
|---|---|
| | Тупчибаш – Кадыйр Габдрахман,<br>Йосыф Акчура – К.Әхмәди.<br>Газет 17-сенә чыгарга тиеш. |
| 2. Балалар кичәсе. | Балаларга кичә эшләү тиешле табыла. Ләкин Громада[21] бинасы фәкать 19-ында гына буш була. Шул көнгә мәҗлес тә тәгаенләргә. |
| 3. Йосыф Акчура мәҗлесе. | «Милли юл» җәридәсенең хәбәренә күрә, бөек төркче юлбашчыбыз Йосыф Акчураның вафаты мәгълүм була. Мәдәният җәмгыяте аңа багышлап бер мәҗлес ясауны Мәркәздән хәбәр алу белән // *(27б кәгазь)* соңга калдыра. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *Мәдинә Әхмәдия*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №35

18 нче апрель 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шакир Баязиди, Кадыйр, Латыйфа Габдрахман, Гайниҗамал Ильяс, Мәдинә Әхмәдия.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:
1. Тукай мәҗлесенең тәртибе.
2. Мәркәз хаты.
3. Йосыф Акчура тугрында рус газеталарына чыгу.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Тукай мәҗлесе тәртибе. | 19 нчы апрельдә булачак Тукай мәҗлесенең тәртибе:<br>1. Коръән.<br>2. Тукай көненең әһәмияте – К.Әхмәди.<br>3. Шагыйребезгә караш – Мәдинә Әхмәди.<br>4. Тәрҗемәи хәле – Надия туташ.<br>5. Балалар бүлеге.<br>6. «Теләү бетте» – Латыйфа. |

[21] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

| | |
|---|---|
| | 7. «Тукайга ядкәр» (Гафури шигыре) – Гайнижамал.<br>Соңга килгән халыкка чәй эшләр[гә] карар ителә.<br>Керү хакы – буш. |
| 2. Мәркәз хаты. | Мәркәздән Йосыф Акчура тугрында мәгълүмат килә һәм 26 нчы апрель көнен матәм көне санап, // *(28а кәгазь)* мәҗлес эшләргә кушылган. Мәдәният җәмгыяте шул көнне мәҗлес эшләячәк һәм рус газеталарында да Йосыф Акчура тугрында чыгачак. Йосыф Акчураның клишесен[22] эшләтергә карарлана. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | 1. Тукай мәҗлесендә Корьән укыр өчен мулла Әүхәди Җамалны хат белән чакырырга.<br>2. 71 нче санлы Милли идарәнең кәгазе алынды, эшләргә беркетелде. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Әхмәдия*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №36

23 нче апрель 1935 елда булган ултырышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Шакир Баязид, Латыйфа, Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайнижамал Ильяс.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Йосыф Акчура хакында.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Рус газеталарында Йосыф Акчура тугрындагы Мәркәздән килгән мәгълүматны русчага тәрҗемә итеп язуны Ибраһим Мамли үз өстенә алуны белдерә. Мәдәният җәмгыяте шул эшне аңа тапшыра. Мәҗлес, Мәркәз кушканча, 26-сында Громада[23] бинасында 7½ сәгатькә тәгаенләнә. Шуны белдереп игъланнар таратылырга тиеш.<br>Тукай мәҗлесенә мулла Әүхәди Коръән укырга килмәгәнгә, бу мәҗлескә Коръән укуны башка кешегә тапшырырга.<br>// *(28б кәгазь)* Мәҗлеснең тәртибе:<br>1. Коръән. |

[22] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.
[23] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

| |
|---|
| 2. Тәрҗемәи хәле – Латыйфа Габдрахман.<br>3. Йосыф Акчура тугрында – Шакир Баязид.<br>4. Безнең вазыйфабыз – Кадыйр Габдрахман.<br>5. Төрк даһие һәм «Төрк йорды» – Кәшшаф Әхмәди. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Әхмәдия*
[Әгъзалар]: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №37

6 нчы майда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа-Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәдия, Гайнижамал Ильяс.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Мәркәздән килгән хат.
2. Мәгърузалар хәзерләү.
3. Милли салымны җыю.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәркәз хаты. | Мәркәздән килгән иҗтимагый әхвалебез тугрында сорап язган хат укыла. Мөзакәрә кылына. |
| 2. Мәгърузалар хәзерләү. | Мәркәз хатына бинаән, без Мәркәзгә үзебезнең әхвалебез тугрында мәгъруза язып йибәрергә тиешбез. Мәдәният җәмгыяте 3 мәгъруза язарга тиеш:<br>// *(29а кәгазь)* 1. Эшләгән эшләр тугрында – М.Әхмәдия.<br>2. Мөнәсәбәт тугрында – К.Әхмәди.<br>3. Шанхайдагы иҗтимагый һәйәтләр – Кадыйр Габдрахман.<br>Шуларны тизлек белән хәзерләп йибәрергә тиешбез. |
| 3. Милли салым. | Мәркәздән килгән Милли салым тугрындагы №282 сан белдермә укыла. Шуңа бинаән, тизлек белән бер тиенлек Милли салымны җыеп йибәрү тәшәббесендә булырга тиешбез. Акча савытларын эшләтү кирәкле табыла. Бу эшне Кадыйр әфәндегә тапшырыла. |
| 4. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | 15 нче майда булачак Ислам кабул иткән көнне билгеләп узар өчен Кадыйр әфәнде тәкъдим итә ислам ка- |

| | |
|---|---|
| | бул итү тарихын язып, халык арасына таратырга. Тәкъдим кабул ителә. Мәдәният җәмгыяте шул көнгә багышлап «Аңлатма» чыгара.<br>Бу тугрыда мәкалә язу Мәдинә ханыма тапшырыла. «Аңлатма»ны язу эше Латыйфа, Гайниҗамал, Кадыйр әфәнделәргә тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Әхмәдия*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №38

9 нчы май 1935 ел. Җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа-Кадыйр Габдрахман, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Мәркәзгә хәзерләнгән мәгърузалар хакында.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәгърузалар. | 1 нче. Мәдәният җәмгыятенең тәшкиленнән // *(29б кәгазь)* башлап эшләгән эшләр тугрында тәфсилле рәвештә мәгъруза Мәдинә ханым тарафлы хәзерләнгән. Мәгъруза укылып тәсдыйк ителә һәм Мәркәзгә йибәрергә карарлана.<br>2 нче. Шанхай иҗтимагый хәяте хакындагы мәгърузаны Кадыйр әфәнде эшли. Мәгъруза тәсдыйк ителә һәм Мәркәзгә йибәрергә карарлана. |
| 2. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | К.Әхмәди тәкъдим итә: Йосыф Акчура турында мәгълүмат йыйып, шуны китап рәвешендә рус телендә бастырырга. Мәсьәлә хәзергә ачык кала. |

Рәис: *Кәшшаф Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар:
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №39

22 нче май 1935 ел. Хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр әфәнде, Мәдинә, Латыйфа ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Украина иптәшләргә вәкил йибәрү.
2. Азәрбәйҗан кардәшлә[ре]безнең Кортылыш көнен билгеләү.
3. Мәгариф шәгъбәсенең хаты.
4. Шанхай Милли идарәсенең хаты.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Вәкил тәгаенләү. | 25 нче майда Украина юлдашчыларыбызның Петлюра шәрәфенә эшлә[нә] торган мәҗлестә иштиракь итәр[гә] Кадыйр әфәнде сайлана. |
| 2. «Аңлатма» чыгару. | 28 нче майда була торган азәрбәйҗан кардәшләребез истикъляль бәйрәменә багышлап Мәдәният җәмгыяте «Аңлатма» чыгарырга карар итә.<br>Азәрбәйҗанның истикъляль тугрында язу – М.Әхмәдия.<br>Төрк-татар халкының 1905–1917 [елга] кадә[р] милли хәрәкәте – К.Әхмәди. |
| 3. Мәгариф шәгъбәсенең хаты. | // *(30а кәгазь)* Мәгариф шәгъбәсеннән мәктәп һәм укучылар тугрындагы сорау кәгазенә мәгърузаны язу – М.Әхмәдиягә тапшырыла. |
| 4. Шанхай Милли идарәсенең хаты. | Шанхай Милли идарәсеннән Мәдәният җәмгыятенең милкен Латыйфа ханымнан сорап язылган хат Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булганга, укылып папкага куелды. |

Рәис: *К.Әхмәди*

Сәркятиб: *М.Әхмәдия*

[Әгъзалар]: *Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №40

5 нче июнь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Мәркәз аңлатмасы.
2. Мәктәп мәсьәләсе.
3. Мәүлүд бәйрәме.
4. Киңәш мәҗлесе.
5. Иганә кәгазе.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәркәздән килгән аңлатма. | Мәркәздән килгән аңлатма укыла һәм игътибарга алына. |
| 2. Мәктәп турында. | Мәктәп ябылу көне 7 июньгә тәгаенләнә. |
| 3. Мәүлүд бәйрәме. | Мәүлүд бәйрәменә кечкенә рәвештә мәҗлес эшләп үткәрү тиешле табыла. Мәктәп балалары тарафлы Коръән, салават укылачак һәм Мәркәздән килгән // *(30б кәгазь)* Мәүлүд бәйрәме өчен махсус язылган аңлатма укылачак. Мәҗлес өчен үз арада акча җыела. Мәҗлес 12 июньдә булачак. |
| 4. Киңәш мәҗлесе. | Үзара аңлашыр өчен бер киңәш мәҗлесе эшләү тиешле табыла. Шунда Шәрәф Мөхәммәтҗан, Шакир Баязид, Хәниф Мамлиларны чакыр[у] тиешле табыла. |
| 5. Иганә кәгазе. | Газзә абыстайның Харбин–Хайларга китүе мәгълүм булгач, Шанхай Мәдәният җәмгыяте идарәсенә шул шәһәрләрдәге белеш-танышлар арасыннан акча җыяр өчен иганә кәгазе Газзә абыстайга тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар]: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №41

1 нче июль 1935 [ел]. Җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа ханым, Шакир Баязиди, Хәниф Мамли.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Мөвакъкат кятиб: Баязиди.

Каралачак мәсьәләләр:
1. Рәиснең мәгърузасы.
2. Корбангали мәсьәләсе.

3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Рәиснең мәгърузасы. | 1. Кәшшаф әфәнде аңлы милләтчелек юлында нык нигездә булган әфәнделәрне дини, милли оешмаларга һәм аларның идарәләренә үткәреп, милли оешмаларны хакыйкый милләтчелек нигезенә тәэсис итәргә тәкъдим итә һәм кандидатлар күрсәтә.<br>// *(31а кәгазь)* 2. Шакир Баязиди: «Хәзерге көндә тугры юл ачык – үзебезнең барлыгыбызны саклау өчен Ерак Шәрыктә яки Аурупада булсын, төрк-татар мәдәнияте җәмгыятьләредер».<br>3. Хәниф әфәнде Мамли тәкъдим итә: «Мәдәният җәмгыяте тарафыннан булган әфәнделәр корбангаличеләр арасына кереп, идарәләргә үтепме яки башка юллар белән ике якны бер итәргә сызык сызарга хезмәтче булырлар ид[е]» ди.<br>Карар: Кәшшаф әфәнде белән Хәниф Мамлиларның мәгърузалары тыңланып, шул карар чыгарылды: «Теге» як әфәнделәр арасында милли юлны таратуга һәм милләтчелек юлында бер фикердә булган әфәнделәрне бергә туплаштыру тәшәббесләренә керү. |
| 2. Корбангали тугрында. | Корбангали Харбингә бару хакында чыккан «Слово»[24] газетасындагы хәбәргә каршы чыгарга карар ителде. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Әүхәди Җамалның Висайдка барып: «Шакир Баязиди исерек коммунистларга ияреп гариза биреп чыгып китте» дигән сүзләренә җавап кайтару Шакир әфәнденең үзенә йөкләнелә. Һәм шулай ук Хәниф әфәнденең докладыннан чыккан мәсьәләләрнең чараларына керүне дә үз өстенә алды. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб:
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

[24] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

// *(31б кәгазь)* Протокол №42

22 нче июль 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа ханым, киңәшчеләр уларак: Шакир Баязиди, Хәниф Мамли, Шәрәфи Мөхәммәтҗан.

Рәислек-кятиблек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Төркия тугрында мәгъруза эшләү.
2. Мәркәз хаты.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Төрек кардәшебез Рәүф әфәндедән мәгъруза эшләвен сорау. | Төрек кардәшләребездән Рәүф әфәнденең Шанхайда булуы белән файдаланып, Төркиядәге тәшкилят, төркчелек һәм Ерак Шәрык вакыйгыяте хакында мәгъруза эшләвен сорау.<br>Шуның өчен 23 нче июльдә (Роут Валлон, 500)[25] чәй мәҗлесе эшләп, Мәдәният җәмгыяте әгъзаларын һәм башка берничә кешене чакырырга. |
| 2. Мәркәз хаты. | Милли мәркәздән килгән «Милли-дини оешмалар һәм милләтчеләр дикъкатенә» дигән кәгазьне язып, бөтен төрк-татарларга тарату эше Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнарга тапшырыла. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Шанхай Милли идарәсе тарафлы Мәркәзгә Гали Дүзи һәм Ибраһим Мамли тугрындагы мәгълүматның копиясе (№269) Мәркәздән Мәдәният җәмгыятенә йибәрелә. Шул тугрыда Мәркәзгә мәгълүмат бирергә карарлана. |

Рәис-кятиб: *К.Әхмәди*

Әгъзалар: *Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(32а кәгазь)* Протокол №43

27 нче июль 1935 елда булган идарә ултырышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Шакир Баязиди, Хәниф Мамли, Шәрәфи Мөхәммәтҗан.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[25] Җәя эчендәге сүзләр адресны белдерә.



Беркетмәләр дәфтәре. 32а кәгазь.

Мөвакъкат кятиб: Шакир Баязиди.
[Көн тәртибе]:
1. К.Әхмәдинең мәгърузасы.
2. Мохтариятчеләр тарафыннан мәгъруза.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1. К.Әхмәдинең мәгърузасы.] | 1. Мәдәният җәмгыятенең рәисе Кәшшаф Әхмәдинең мәгърузасы: 26 июльдә Висайдтагы «корбангаличеләр» Милли вә дини оешмасында булган гомуми җыелышларында бер кыйсем төрк-татарлар үзләрен «мохтариятчеләр» дип игълан итеп, Милли вә дини оешмага наразыйлык игълан итеп, гомуми җыелышны ташлап чыкканнар. Һәм үзләрен моннан соң Милли вә дини оешма әгъзалары дип хисапламаенча, Шанхай төрк-татар Мәдәният җәмгыяте белән бер сафта эшләргә дип тәкъдим итеп вәкилләр күндерәләр. Вәкил униарак килгәннәр ошбу: Фәйзрахман Максуди һәм Хисаметдин Зыятдин әфәнделәр. |
| [2. Мохтариятчеләр тарафыннан мәгъруза.] | 2. Вәкилләрнең тәкъдиме шуннан гыйбарәт: без, мохтариятчеләр, үзебезгә Шанхайда якын булган оешмалардан Шанхай Мәдәният җәмгыятен якын табып һәм аның эшләгән эшләрен күз алдында тотып, истикъбальдә бер сафта милләт өчен эшләргә тәкъдим итәләр.<br><u>Карар:</u><br>1. Бу мәгърузалар һәр җәһәттән тәфтиш ителеп, шундый карарга килен[д]е.<br>Бөтен Ерак Шәрыктә яши торган Милли мәркәзгә табигъ булган төрк-татарларның оешмаларының вәзгыятьләрен күз алдында тотып (ягъни, димәк милләтчелек һәм Идел-Урал истикъляль фикерен химая итүне үзенең беренче вазыйфасы дип танып), милләтчелеккә гакселхәрәкәт итүче хаин корбангаличеләрдән аерылып чыккан мохтариятчеләрне тәдриҗи рәвештә милли истикъляль фикере һәм милли матбугат белән таныштырып, истикъбальдә милли сыйныфны ныгыту фикерендәбез.<br>2. Шушы югарыда күрсәткән фикерләрне игътибарга алып, мохтариятчеләр белән бер ултырыш ясарга, |

| | |
|---|---|
| | шул утырышта мәгърузаны Кәшшаф Әхмәдигә тапшыру.<br>3. Шул утырышта нәтиҗәләр сәмәрәле булса, мөвакъкат уртак бер һәйәт тәшкил итәргә. // *(32б кәгазь)* Шул һәйәткә Шакир Баязидины һәм Кадыйр Габдрахманины үткәзергә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Мөвакъкат кятиб:
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №44

28 нче июль 1935 ел. Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Шакир Баязиди һәм Шанхайдагы мохтариятчеләр фиркасеннән вәкилләр: Ф.Максуди, Х.Мамли, З.Хисам.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Мөвакъкат кятиб: Шакир Баязиди.

Көн тәртибе:

1. Ике тарафның да мәгърузаларын тыңлау һәм эш планнары белән танышу.
2. Мәгърузаларның эченнән чыккан мәсьәләләр хакында фикер алышу.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1. Ике тарафның да мәгърузаларын тыңлау һәм эш планнары белән танышу.] | Ике тарафның да мәгърузалары тыңланып, һәр җәһәттән тәфтиш ителеп, фикер алышканнан соң, мохтариятчеләрне Мәдәният җәмгыяте белән якынлаштыру өчен бер һәйәт төзергә булды.<br>Бу һәйәтнең исеме, Шанхай төрк-татарларының вәзгыятенә бинаән, түбәндәге исемне бирергә булынды: «Иниц[иативная] группа по созданию нац[ионального] объединения Т[юрко-]татар г. Шанхая».<br>Бу һәйәткә түбәндәге әгъзалар сайлана: Ф.Максуди. З.Хисам, Ш.Баязиди. К.Габдрахмани.<br>Бу һәйәт үзенә киләчәктәге эшләячәк эшне сызыклар сызып, киләчәктә ике якка да тәкъдим итәчәк.<br>Бу утырышның протоколларының копияләрен Милли мәркәзгә йибәрелергә тиеш. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб:
Әгъзалар:

// *(33а кәгазь)* Протокол №45

23 нче сентябрь 1935 елда булган идарә җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар, Мансур Арсланбәк, Шакир Баязиди.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Мәктәп мәсьәләсе.
2. Иганә кәгазьләре.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәктәп мәсьәләсе. | Уку елы бетү сәбәпле, Мәдәният җәмгыятенең дин һәм ана теле өчен ачылган курсларын дәвам иттерү тәшәббесләрен күрү тугрында фикер алышына. Милли идарәнең беренче вазыйфасы мәктәп булып та, шушы көнгәчә һич хәбәрсез торуы сәбәпле, Мәдәният җәмгыяте бу юлда курсларны дәвам иттерергә тиеш. Хәзергә үзебезнең бүлмәбез булмаганга, Украина юлдашчыларыбыздан атнасына ике көнгә биналарын сорарга һәм шулай ук атнасына бер көн кыйраәтханә һәм канцелярия өчен дә сорарга. Шуны сорау һәм хакын белү К.Әхмәдигә тапшырылды. |
| 2. Иганә кәгазьләре. | Газзә абыстайның сүзенә бинаән, Хайлар төрк-татарлары Шанхай Мәдәният җәмгыятенә ярдәмдә булырга вәгъдә бирүләрен күздә тотып, Хайлар Милли идарәсенә бер иганә кәгазе язып йибәрергә карар итеlә һәм шулай ук англиз телендә бер иганә кәгазен Шәрәфи Мөхәммәтҗанга бирергә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(33б кәгазь)* Протокол №46

26 нчы сентябрь 1935 ел җыелышында хазир булдылар: К.Әхмәди, Баязиди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа Габдрахман, Гайниҗамал Ильяс, Мәдинә Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле, Шә[р]әфи Мөхәмммәтҗан.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Мәктәп ачу.
2. Газета чыгару.
3. Октябрь Матәм көнебезне уздыру.
4. Мәркәз әгъзасы Келәүледән мәгъруза эшләрен сорау.
5. Бер тиенлек милли салым.
6. Эшләребезне тәртипкә салу.
7. Язылу кәгазьләре чыгару.
8. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

[Искәрмә:] Көн тәртибенең 3 нче маддәсе 2 нчегә күчерелеп кабул ителә.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәктәп ачу. | Мәктәп мәсьәләсе узган җыелышта каралып, ачарга карарланса да, бу җыелышта күп әгъзаларыбыз җыелу сәбәпле, яңгыдан карала һәм Мәдәният җәмгыяте узган елдагыча курсларны ачарга тиеш дип табыла. Мәктәп өчен бүлмәне хәзергә Украина юлдашларыбыздан алырга. Мәгълүм була – Украина иптәшләр бинаны бирә алалар, ләкин хакы күпме булачагын алдагы көннәрдә әйтәчәкләр. Киләчәк якшәнбәгә бар татар ана-аналарны җыярга тәгаенләнә. |
| 2. 15 нче октябрь. | Матәм көнебезнең билгесе уларак газета чыгарырга карар ителә[26]. Мәҗлес эшләү хәзергә ачык кала. |
| 3. Газета чыгару. | Газетаны чыгару тиешле табыла. Исеме тугрында фикер алышу киләчәк мәҗлескә калдырыла. |
| 4. Мәркәз тугрында мәгъруза. | 4. Мәркәз тугрында мәгъруза эшләүне Шаһвәли әфәндедән сорала. Ул кабул итә. Шулай ук Әхмәд Салидан Харбин вәзгыяте тугрында мәгъруза эшләвен сорарга. |

[26] Монда ниятләнгән газета «Берлек» исеме белән чыгарылган. Аның турында тулырак мәгълүматны китапның кушымта өлешеннән карагыз.

| | |
|---|---|
| 5. Бер тиенлек салым. | Мәркәз өчен көнлек бер тиенне җыяр өчен // *(34а кәгазь)* тартмалар эшләтү эше Шаһвәли Келәүлегә тапшырыла. |
| 6. Эшләрне тәртипкә салу. | Алдагы көннәрдә гомуми җыелыш булуын күздә тотып, протоколларны, китапханәне тиз вакыт эчендә тәртипкә куяр өчен һәйәт сайлана. Һәйәткә Кадыйр, Латыйфа, Гайниҗамал, Мәдинә ханымнар сайланалар. |
| 7. Язылу кәгазьләре чыгару. | Газзә абыстай белән Шәрәфи әфәндегә язылу кәгазьләре белән иганә җыеп бирүләренә рәхмәт хатлары язарга һәм узган җыелышта карарланган иганә кәгазьләре берсе Шәрәфи әфәндегә тапшырыла. Икенчесе Хайларга йибәрелә. |
| 8. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Шәрәфи әфәнде: «Үзебезнең бүлмәбез, үз почмагыбыз булсын иде» дип тәкъдим кертә. Шуны вөҗүдкә китерер өчен үз ягыннан иганә кәгазенә күбрәк акча җыярга вәгъдә бирә. Мәдәният җәмгыяте бу фикерне бик мәгъкуль күрә һәм алдан бүлмә караклашып торуны карар итә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Әхмәдия*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №47

29 нчы сентябрь. Мәдәният җәмгыяте тарафлы чакырылган Ата-аналар һәйәте белән бергә булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Гайниҗамал ханым, Сәйфи әфәнде.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

[1.] Мәктәп ачу.

[2.] Укытучы чакыру.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| // *(34б кәгазь)* 1. Мәктәп ачу. | Гариф әфәнде әйтә: Берничә мәртәбә ул Милли идарә кешеләреннән мәктәп ачу тугрында сораса да, шушы көнгәчә Милли идарә мәктәп ачу тугрында бер адым да эшләмәгән. Мәдәният җәмгыятенең мәктәп |

| | |
|---|---|
| 2. Укытучы чакыру. | ачуын шатлык белән каршы ала.<br>Укытучы уларак Мәдинә ханымны чакырырга карарлана. |

Рәис-кятиб: *К.Әхмәди*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №48

3 нче октябрь 1935 ел. [Мәдәният җәмгыятенең идарә җыелышында хазир булдылар]: К.Әхмәди, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяс, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арсланбәк.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. 15 нче октябрь.
2. Газета мәсьәләсе.
3. Мәктәп ачу көне.
4. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. 15 нче октябрь. | 15 нче октябрь – Матәм көнебездә бар төрк-татарларны җыеп, мәгъруза эшләргә һәм шул мәҗлес өчен Украина Громадасын сорарга.<br>Мәгъруза эшләү Шакир Баязидигә тапшырыла. |
| 2. Газета мәсьәләсе. | К.Әхмәди газетабызның исеме һәм тотачак юлы тугрында сөйли. Исем тәкъдим итәргә сорый.<br>Шакир Баязиди – «Матбугат хәбәрләре», // *(35а кәгазь)* К.Әхмәди «Идел», Мәдинә Әхмәдия – «Мәдәният чаткысы», Келәүле – «Яшьләр авазы» яки «Ерак [Шәрык] тавышы».<br>Исем мәсьәләсендә бер фикергә киләлмичә, киләчәк җыелышка калдырыла.<br>Чыгарылачак газетада тәфтиш, мөхәррир[лек] итү эше Мәдинә ханыма тапшырыла.<br>Газетага мәкаләләр:<br>Баш мәкалә – Мәдинә ханым;<br>Тарихи караш – Мансур;<br>Тарихтан – Шакир Баязиди.<br>К.Әхмәди газетага ошбу шигарьләрне тәкъдим итә: |

| | |
|---|---|
| | «Яшүсмерләр, бөек төрк юлбашчыларыбызның шигарьләрен тикшерегез!»;<br>1. «Телдә, фикердә, эштә – берлек» (Исмәгыйль Гаспралы).<br>2. «Юлыбыз тугры, теләгебез хак, халкыбыз иманлы, милләтебез көчле» (Гаяз Исхакый).<br>3. «Һәр төркнең ике кыйбласы: берсе – Ватаны, икенчесе – Төркия».<br>4. Мансур әфәнде тәкъдиме: «Төрклек үлмәс, юк булмас... Төрклек – төрк Тәңресе кебек мәңгелектер» (Йосыф Акчура). |
| [3.] Мәктәп ачу тугрында. | Сайланган Ата-аналар һәйәтенең кятибәсе Латыйфа ханым мәгърузасы: «Мәктәпнең ачу көне шушы алдагы көннәрдә булачак, укытучы Мәдинә ханыма аена 15 сум мәгаш, имкян булу белән 20 су[м] итәргә. Беренче, икенче уку китапларын Мәркәз мәгариф шәгъбәсеннән соратырга». |
| [4.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Ел тулып узганга, без тиз арада гомуми // *(35б кәгазь)* җыелыш эшләргә тиешбез. Шуңа күрә эшләрне тәртипкә салырга дип сайланылган һәйәттән сорый тизлек белән эшләрен бетерүләрен. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Мәдинә Әхмәдия*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №49

9 нчы октябрь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле, Латыйфа–Кадыйр Габдрахман, Гайниҗамал ханым.

Рәислек-кятиблек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Мәктәп мәсьәләсе.
2. Төркиянең Кортылыш бәйрәме.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәктәп мәсьәләсе. | Украина Громадасында мәктәп өчен бина алынды. Шимбә 3–6-га кадәр, якшәмбе 9–12-гә кадәр.<br>Ачылу мәҗлесе 11 нче октябрь, кичен сәгать 7-дә. Мәктәп ачыла шимбә – 12-сендә. Бина өчен ... сум[27].<br>Мәҗлес тәртибе: Коръән, Мәдәният җәмгыяте исеменнән сүз – К.Әхмәди, Ата-аналар һәйәтеннән – Мәрьям ханым Сәйфи. Мәктәп ачу тугрында игълан таратырга карар ителә. |
| 2. Төркиянең Кортылыш бәйрәмен уздыру. | К.Әхмәди тәкъдим итә – 28 нче октябрьдә була торган Төркиянең Кортылыш бәйрәмен тантаналы рәвештә уздырырга. «Кортылыш көне тугрында мәгъруза булырга тиеш, газета чыгарылырга һәм бина төрек, Идел-Урал, // *(36а кәгазь)* Азәрбәйҗан, Кырым, Төркестан байраклары белән бизәкләнергә тиеш». Тәкъдим кабул ителә. |

Рәис-кятиб: *К.Әхмәди*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №50

10 нчы октябрь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Мансур Арсланбәк, Шаһвәли Келәүле, Кадыйр–Латыйфа Габдрахман, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

Көн тәртибе:

1. Газетаның исеме, мөндәрәҗәсе.
2. Сәед Әхмәд Җәгъфәр тугрында.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Газетаның исеме. | Шанхай Мәдәният җәмгыяте тарафлы чыгарыла торган газетага «Берлек» дип исем бирелә.<br>28 нче октябрьдә чыгарылачак газетаның мөндәрәҗәсе: |

[27] Суммасы язылмыйча, буш урын калдырылган.

| | |
|---|---|
| 2. Сәед Җәгъфәр тугрында. | 1. Баш мәкалә – М. Әхмәдия.<br>2. Төрк тарихыннан – Мансур Арсланбәк.<br>3. «Яңы милли юл»дагы Мөхәммәдзадәнең «Идел-Урал хәрәкәте һәм бәйнәлмиләл әһәмияте».<br>К.Әхмәди тәкъдим итә: Сәед Әхмәд Җәгъфәр әфәндедең төрк милләте өчен эшләвенә 26 нчы сентябрьдә 25 ел тулу мөнәсәбәте белән, аны тәкъдир итү өчен:<br>1. Сәед Әхмәд әфәндене үзебезнең юлбашчыбыз итеп Мәдәният җәмгыятенең фәхри әгъзасы // *(36б кәгазь)* итеп сайларга.<br>2. Рәсемен Мәдәният җәмгыяте бүлмәсендә куярга.<br>3. Шуларны хат белән Сәед Әхмәд Җәгъфәр әфәндегә белдерергә тәкъдим бертавыштан кабул ителә. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №51

23 нче октябрь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр, Келәүле, Мансур Арсланбик, Гайниҗамал, Мәдинә ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Мәркәз хаты.
2. Төркиянең Кортылыш бәйрәме.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Мәркәздән килгән хат. | Мәркәздән килгән хатта, безгә зур сөенеч хәбәре уларак, Мукден шәһәрендә атналык «Милли байрак» исемендә гәзит чыгуны белдерде.<br>Бу газетаның чыгуы бик тиешле һәм бик вакытлы табылып, шатлык белән алкышланды. Мәдәният җәмгыятенең һәр әгъзасы бу газетаны алдыр[ыр]га тиеш дип карар ителде һәм Мәдәният җәмгыяте әгъзаларының да бу газетада иштиракь итүләре тиешле табылды. |

| | |
|---|---|
| 2. Кортылыш бәйрәме. | Кортылыш бәйрәменә багышланып чыгарыла торган Мәдәният җәмгыятенең «Берлек» исемендәге газетасының мөндәрәҗәсе:<br>// *(37а кәгазь)* 1. Баш мәкалә – М. Әхмәдия.<br>2. Төркия тарихыннан – Мансур Арсланбәк.<br>3. Ерак Шәрыкта соңгы вакыттагы милли хәрәкәт – Шаһвәли Келәүле.<br>4. «Милли байрак» – К.Әхмәди.<br>Токиодагы Төркия сәфиренә Кортылыш көнен тәбрикләп хат язу. |
| 3. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | 15 нче октябрь – Матәм көне ошбу тәртип белән уздырылды:<br>1. Матәм көне хакында – К.Әхмәди.<br>2. Төрк-татар тарихыннан мәгълүмат – Шакир Баязиди.<br>3. Соңгы көндәге милли хәрәкәт – Шаһвәли Келәүле.<br>Мәдәният җәмгыяте тарафлы чыгарылган «Берлек» газетасы моннан соң дәвамын тукта[та]. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Сәркятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *М.Әхмәди*
*Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №52

4 нче ноябрьдә 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Шаһвәли, Мансур әфәнделәр, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе]:

1. Гомуми җыелыш хакында.
2. Килешү һәйәтенең әгъзасының мәгърузасы.
3. Мәгърузадан чыккан мәсьәләләр.
4. Ата-аналар һәйәтенең мәгърузасы.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| // *(37б кәгазь)* 1. Гомуми җыелыш. | 7 нче ноябрь, җомга көн булачак гомуми җыелышка хәзерлек ултырышының тәртибе:<br>1. Мәдәният җәмгыятенең эшләгән эшләре хакында – К.Әхмәди.<br>2. Канцелярия эшләрен тәртипкә салу – М.Әхмәдия, Латыйфа ханым, Мансур.<br>3. Көтепханәне тәртипкә салу – Кадыйр Габдрахман.<br>4. Хәзинә эше – Ш.Келәүле. |
| 2. Килешү һәйәтенең әгъзасының мәгърузасы. | Шаһвәли Келәүле әфәнде мәгъруза эшли: «Мәркәздән килгән хатка бинаән, килешү һәйәтенең ултырышында ошбу фикерләр тугды. Мәктәпне күз алдында тотып, халыкны туплау өчен чаралар күрү – һәр ике идарә фикер алышып, килешү тәшәббесләренә керү өчен 5 нче ноябрьдә бергә җыелыш ясау». |
| 3. Мәгърузадан чыккан мәсьәләләр. | К.Әхмәди тәкъдиме: ике ида[р]әнең җыелышында ошбуларны тәкъдим итәргә:<br>1. Милли идарә тарафлы идарәдән чыгарылган Мәдәният җәмгыятенең әгъзаларын Милли идарә үзенең бер җыелышында «Бу эш хаталык-кызулык белән эшләнгән» дип, шул карарны аннулировать итәргә һәм протоколга фиксировать итәргә. Соңга гомуми җыелышта да шулай ук протокол аша уздырырга.<br>2. Милли идарәдә гомуми җыелыш ясап, яңы сайлаулар эшләргә.<br>3. Милли-мәдәни эшләр Мәдәният җәмгыятенә тәгаллекъле булганга, хәзерге көндә Милли идарә кулындагы Габдулла Тукай исеменә ачылган китапханәне Мәдәният җәмгыятенә тапшырырга.<br>4. Мәктәп эше – дини-милли оешманың турыдан-туры вазыйфасы булганга, бу көндә М[әдәният] җ[әмгыяте] кулындагы милли мәктәпне Милли идарәгә тапшырырга.<br>// *(38а кәгазь)* 5. Иҗтимагый һәйәтләребезнең матди яклары агыр булганга, ике идарә бер-беренә һәрвакыт матди вә мәгънәви ярдәмдә булырга.<br>Тәкъдим кабул ителә. |
| 4. Ата-аналар һәйәтенең | Латыйфа ханым, Ата-аналар һәйәтенең кятибәсе уларак, ошбу мәгърузаны эшли: «Ш.Т-Т.М.Җ. [Шанхай |

| | |
|---|---|
| мәгърузасы. | төрк-татар Мәдәният җәмгыяте] карамагында булган мәктәп янындагы Ата-аналар һәйәте үзенең 4 нче ноябрьдә булган ултырышында, мәктәпнең матди ягы начар булганга, фикер алышканнан соң, ике ихтыяри иганә кәгазьләрен Мәдәният җәмгыятеннән сорарга тиешле табылганын белдерә һәм Рамазан гаетендә мәктәп файдасына кичә куярга».<br>Фикер алышканнан соң, бер иганә кәгазе бирергә карар ителде. |
| 5. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Кичә кую мәсьәләсе киләсе җыелышка калдырылды.<br>«Берлек» газетасы халык арасында таратылды. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №53

12 нче ноябрь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Мәдинә Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахманнар, Гайниҗамал Ильяс, Мансур Арсланбик.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе]:

1. Гомуми җыелышка мәгърузалар.
2. Мәктәп.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| // *(38б кәгазь)* 1. Гомуми җыелышка мәгърузалар. | Гомуми җыелыш 7 нче ноябрьгә тәгаенләнгән булса да, мәгърузалар хәзер булмаганлыктан, җыелмады. К.Әхмәди хәзерләнгән мәгърузасын укып чыга һәм кабул ителә.<br>Кадыйр әфәнде китапханә хакындагы мәгърузасын хәзерли алмаган. Шулай ук башкаларныкы да хәзер түгел. Шуңа күрә, гомуми җыелыш 24 нче ноябрьгә калдырыла. |
| 2. Мәктәп. | Мәктәпне Милли идарә үзенә алырга дисә дә, шушы көнгә кадәр М[әдәният] җ[әмгыяте] карамагында ка- |

| | |
|---|---|
| | лып, мәктәп мәсарифе М[әдәният] ж[әмгыятенә] ялгызына авыр булганга, мәктәпне Украина клубыннан Латыйфа ханымның бүлмәсенә, Милли идарә алгынчага кадәр күчереп торырга карар ителә. Шәрәфи Мөхәммәтҗан тарафлы мәктәп өчен язылу кәгазе буенча җыелган акча – 12 доллар Мәдәният җәмгыятенә тапшырыла. |

Рәис: *К.Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №54

24 нче ноябрь 1935 ел. Җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Латыйфа–Кадыйр Габдрахман, Гайниҗамал Ильяс, Мәдинә Әхмәди, Мансур Арсланбәк.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

// *(39а кәгазь)* [Көн тәртибе]:

1. Гомуми җыелышка хәзерләнгән мәгърузалар.
2. Мәркәз хаты.
3. Гомуми җыелыш.
4. Җәгъфәр Сәед бәк хакында.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Мәгърузалар. | 1. К.Әхмәдинең М[әдәният] ж[әмгыяте]нең төзелгәненнән башлап, шушы көнгә кадәр эшләгән эшләре хакындагы тулы мәгърузасы укылып, кабул ителә. 2. Кадыйр Габдрахманның китапханәдәге китаплар хисабы тугрындагы мәгърузасы кабул ителә. 3. Латыйфа ханымның хуҗалык тугрындагы мәгърузасы кабул ителә. |
| [2.] Мәркәз хаты. | Мәркәзнең №791 хаты укыла. М[әдәният] ж[әмгыяте] тарафлы ошбу кешеләргә «Милли байрак» соратыла: Шамил Акбирди, Шакир Баязиди, Гариф Сәйфи, Ш.Келәүле, Гайниҗамал Ильяс, К.Әхмәди, өч данә – фәкыйрьләргә бушлай таратыр өчен йибәрүләрен сорап язарга. |

| | |
|---|---|
| | Хәбәрче тәгаен кылу мәсьәләсе гомуми җыелышка калдырыла. |
| [3.] Гомуми җыелыш. | Гомуми җыелыш 1 нче декабрь, кич сәгать 6-га тәгаенләнелә. Кворум тулмаса, 7 сәгатьтә икенче җыелыш тәгаенләнелә.<br>Гомуми җыелыш тәртибе:<br>1. М[әдәният] җ[әмгыяте] эшләре хакында – К.Әхмәди.<br>2. Кыйраәтханә, китапханә – Кадыйр Габдрахман.<br>3. Хуҗалык – Латыйфа Габдрахман.<br>4. Хисап – Ш.Келәүле (ул булмаса, Кадыйр Габдрахман).<br>// *(39б кәгазь)* 5. Тәфтиш һәйәтеннән – Гайниҗамал ханым эшләячәге мәгълүм булына.<br>6. Яңы идарәгә башкарма әгъзалары сайлау.<br>7. Тәфтиш һәйәте сайлау.<br>8. Нәүбәттәге мәсьәләләр.<br>Мәдәният җәмгыяте үз тарафлы яңы идарәгә ошбу кешеләрнең үтүен мәгъкуль күрә: рәислеккә – Шаһвәли Келәүле, кятиб – Шакир Баязиди яки Мансур Арсланбәк, хәзинәдар – Кадыйр Габдрахман, әгъзалар: Шамил Акбирди, Надия Габдрахман, Рәшид, тәфтиш һәйәтенә Гайниҗамал, Мәдинә ханымнар, Шәрәфи Мөхәммәтҗан. |
| [4.] Сәед Җәгъфәр хакында. | Төрек халк[ы] өчен Сәед Җәгъфәр бәкнең эшләгән эшләре ифрат күп булганын тәкъдир итү йөзеннән, 25 еллык юбилей мөнәсәбәте белән М[әдәният] ж[әмгыяте]нә үзенең фәхри әгъзасы итеп сайлавын гомуми җыелышта тәсдыйк ителүе тиеш. |

Рәис: *Кәшшаф Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №55

5 нче декабрь 1935 елда булган ултырышта хазир булдылар: К[әшшаф] һәм Мәдинә Әхмәдиләр, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Гайниҗамал.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]
1. Гомуми җыелыш.
2. Бәйрәм мәҗлесе.
// *(40а кәгазь)* 3. Абунә һәм тәбрик.
4. Рус матбугатына чыгу.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Гомуми җыелыш. | Идарә әгъзалары Шаһвәли һәм Мансур әфәнделәрнең ашыгыч рәвештә провинциягә киткәнгә, гомуми җыелыш мәгълүм түгел вакытка кичектерелде. |
| 2. Бәйрәм мәҗлесе. | Алдагы көннәрнең берсендә Ата-аналар һәйәте белән ултырыш эшләп, бәйрәмдә мәҗлес эшләү хакында сөйләшергә. |
| 3. Абунә һәм тәбрик. | 7 кеше исеменнән «Милли байрак»ны сорап хат язарга һәм абунә хакын 1 нче гыйнварга йибәреләчәген белдерергә. Рамазан гаетен тәбрикләп, «Милли байрак»ка язарга карар ителә. |
| 4. Рус матбугатына чыгу. | К.Әхмәдинең рус матбугатында үзебезнең хәрәкәтебез хакында мәгълүмат бирер өчен брошюралар чыгару тугрындагы тәкъдиме, күп фикер алынса да, хәзергә ачык кала. Киләчәк җыелышта тагын бу мәсьәлә каралачак. |

Рәис: *Кәшшаф Әхмәди*
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №56

17 нче декабрь 1935 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф–Мәдинә Әхмәдиләр, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Гайниҗамал Ильяс.
// *(40б кәгазь)* [Рәислек итә: К.Әхмәди.]
[Көн тәртибе:]
1. Рус телендә брошюр.
2. Бәйрәм мәҗлесе.
3. Тәбрик.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Рус телендә брошюр. | Узган җыелышта бу тугрыда бер карарга киленә алынмаса да, К.Әхмәди бу мәсьәләне тагын кузгата. Кечкенә гәзит йә брошюра рәвешендә бастыру мәсарифе 1500 данәнең 21 сум булачагын белешкән. «Рус әфкяре гаммәсе безнең хәрәкәтне яңлыш аңлый һәм Корбангали кебек хаиннәр шулай аңлатырга тырышалар. Шуңа күрә Ерак Шәрыктәге төрк-татарларның тарихи Идел-Урал хәрәкәте, Гаяз абзыйның тоткан урыны һәм хаиннәр тугрында язарга тиешбез» ди. Күп фикер алышканнан соң, бу эшне башкару Мәдинә ханыма тапшырыла. |
| [2.] Бәйрәм мәҗлесе. | М[әдәният] җ[әмгыяте] бәйрәмдә кичә эшләүне тиешле таба һәм бу тугрыда Ата-аналар һәйәтен җыеп, уртак киңәш мәҗлесе эшләүне кирәкле таба. |
| [3.] Тәбрик. | «Милли байрак»та бәйрәм тәбриге М[әдәният] җ[әмгыяте] һәм Ата-аналар һәйәте исеменнән булуы тиешле табыла. 6 [сум] 50 тиенлек мәсариф ике һәйәткә уртак бүленә. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(41а кәгазь)* Протокол №57

3 нче гыйнвар 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Шаһвәли Келәүле, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Узган кичә.
2. Нанкиннән хат.
3. Шул тугрыда карар.
4. Гомуми җыелыш.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| 1. Кичә. | 28 нче декабрь 1935 елда булган балалар кичәсе тәртибе[28]:<br>1. «Саран күрше» (пьеса).<br>Уйнаучылар: Нияз, Тасия Габдрахманнар, Рәшидә Ильяс, Равил Әхмәди.<br>2. Әдәбият бүлеме:<br>1. «Чынгыз бабам» (күмәк җыр).<br>2. «Борынгы заман» – Равил.<br>3. «Диябез» – Тасия.<br>4. «Төрк сүзе» – Нияз.<br>5. «Киләчәк-булачак» – Рәшидә.<br>6. Идел-Урал маршы.<br>7. Бию – Рәшидә, Тасия. |
| 2. Нанкин хаты. | Нанкиннән Мансур әфәндедән килгән хат укыла. Шәркый Төркестан кардәшләребез белән ултырдаш булган вакытта Шанхайда бергәләп кичә ясау мәсьәләсе хакында язган.<br>Бүген Шанхайга килгән Гайсәбәк әфәнде белән күрешеп сөйләшүе тугрында Кәшшаф Әхмәди дә мәгълүмат бирә: «Гайсәбәк әфәнде бер зур кичә куюны тәкъдим итә. Кичә Кытай халкы каршында булырга тиеш» ди. Шанхайның бер зур театрында сәхнә эше – сездә булып, башка мәшәкатьләрен Гайсәбәк әфәнде үзе башкарырга алыначагын сөйләгән. |
| // *(41б кәгазь)*<br>3. Бу тугрыда чыккан карарлар. | Кичә эшләү фикере бик мәгъкуль табыла. Күп фикер йөрткәчтен, «Таһир белән Зөһрә»не кую матлуб табыла. Кичәдән йыйылачак файда тугрында Гайсәбәк әфәнде белән сөйләшкән вакытта без үзебезгә дигән өлешне Мәркәз файдасына икәнлеген белдерергә һәм иртәгәсе көнгә Гайсәбәк әфәндене чәй мәҗлесенә чакырып, кичә хакында катгый карарга килергә тәгаенләнә. |
| 4. Гомуми җыелыш. | Алдагы көннәрдә, имкян булу белән, гомуми җыелыш эшләргә карарлана. |

[28] Бу кичә турында «Милли байрак» газетасының 1936 ел 29 гыйнвар санында язылган. Шунда ук кичәдә катнашучылар һәм аны оештыручыларның фоторәсеме дә басылган.

| | |
|---|---|
| 5. Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Шаһвәли әфәнде шәһәрдә булмаганга, соңгы вакыттагы иҗтимагый хәяттәге вакыйгалар һәм 2 нче гыйнварда Милли идарә белән булган уртак җыелышта нинди уртак фикерләргә килгәнебез хакында мәгълүмат бирелә. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №58

19 нчы гыйнвар 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф–Мәдинә Әхмәдиләр, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Гайниҗамал Ильяс, Мансур Арсланбик һәм кичә хакында киңәшер өчен чакырылган: Шакир Баязиди, Рәхмәтулла Фәтхулла, Әхкям Зыятдин, Гали–Фатыйма Дүзиләр, Миргали Багдан.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Кичә хакында.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| // *(42а кәгазь)* К.Әхмәдинең мәгърузасы:<br>«Узган елда Шәркый Төркестанлы кардәшләребез белән бергәләп бер зур кичә эшләү мәсьәләсе кузгалган иде. Быел инде шул фикерне вөҗүдкә китерү алдындабыз. Гайсәбәк әфәнде белән сөйләштек. Сәхнә эшен без үтәргә тиешбез. «Таһир белән Зөһрә» – Бурнаш әсәре мәгъкуль табылды. Аның өчен – чит милләт халыклары өчен күренешкә бай матур әсәр булуы лязем. Шул әсәрне куя алабыз» ди. Кичәнең безгә тигән фатира өлеше Мәдәният җәмгыяте Ерак Шәрык төрк-татарларының дини-милли мәркәз идарәсенең матбагасы өчен тәгаенләнә.<br>Шакир Баязиди: «Кием, декорация, пьесада күрсәтелгән дәвергә муафыйк булып, бик художественный булырга тиеш. Шул чакта гына муаффәкыятле чыгачак».<br>Мәдинә Әхмәди: «Шундый мәсьүлиятле кичәне уздыру өчен режиссёр кирәк. Бу эшне башкарырлык кеше – фәкать Хөсәен Габдүш».<br>Габдүшне китертү күп авырлыклар белән баглы булганга, Гайсәбәк әфәнде күрсәткән Тәнзиндәге Шәйхулла Йосыфка тукталына һәм аны чакыртып хат язарга карар ителә. |

| |
|---|
| Шулай ук пьесага йитешмәгән кешеләрне дә Тәнзиннән яки башка йирдән чакыртырга. Анысы Шәйхулла әфәнде килгәч мәгълүм булачак.<br>Хәзергә рольләр шулай тәгаенләнде:<br>Хан – Шаһвәли;<br>Ханча – Латыйфа;<br>Зөһрә – Нәдия;<br>Вәзир – Гали Дүзи;<br>Шаһзадә – Рәхмәтулла;<br>Гаскәр башлыгы – Миргали;<br>Кияү – Рәшид;<br>Гарәп – Мансур;<br>Сакчылар – Әхкям, Шамил.<br>Таһир белән кызларын уйнаучылар юк.<br>Тизлек белән Шәйхулла әфәндегә хат язарга карарланды. |

Рәис:
Кятиб:
Әгъзалар: *Мәдинә Салиәхмәд*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(42б кәгазь)* Протокол №59

10 нчы февраль 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф Әхмәди, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

Рәислек итә: Кәшшаф Әхмәди.

[Көн тәртибе:]

1. Шиһаб хәзрәт хакында.
2. Мәркәзнең бер еллык билгесе.
3. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Шиһаб хәзрәт тугрында. | «Бу ел Шиһаб хәзрәтнең үлүенә 50 ел тулу көнен «Милли байрак» һәм Яурупадагы матбугатта күп мәкаләләр булды. Бу йирдә дә без, рус газетасы аркылы булса да, аны яд итәргә тиешбез» дигән фикерне Кәшшаф Әхмәди тәкъдим итә. Тәкъдим кабул ителә һәм русча язу эше Мәдинә Әхмәдигә тапшырыла.<br>Мәҗлес эшләргә. Мәгъруза эшли – К.Әхмәди. Ул ук «Әмәл» мәҗмугасындагы мәкаләне укып тикшерә. |

| | |
|---|---|
| [2.] Мәркәзнең бер еллык билгесе.<br>[3.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Мәркәзнең бер яше тулу көнен ядлап, мәркәзгә тәбрик хаты язарга һәм рус газетасына чыгарга. Рус газетасына язу эше Кадыйр Габдрахманга тапшырыла.<br>«Милли байрак»ның бушлай килә торган 3 данәсен волонтёрларга, берсен Байгилдигә бирергә тиешле табыла.<br>Мәктәп хакында – Шәрәфи белән барып сөйләү Кадыйр белән Кәшшафка тапшырыла. |

Рәис:
Кятиб: *Мәдинә Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(43а кәгазь)* Протокол №60

16 нчы февральдә булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф–Мәдинә Әхмәдиләр, Кадыйр–Латыйфа Габдрахманнар, Гайниҗамал Ильяс.

[Рәислек итә: Кәшшаф Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

[1.] Зур кичә.
[2.] Бәйрәм кичәсе.
[3.] Бәйрәм тәбриге.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Зур кичә. | Зур кичә эшләү мәсьәләсе хәзергә тукталып тора. Сәбәпләре: Шәйхулла Йосыфның килә алмау хәбәре, уйнаучыларның берсенең тагын кимүе (Мансур Арсланбәк), Мәркәзгә язган хатка (уйнаучылар һәм Габдүшне йибәрү чаралары тугрында) җавап алмау.<br>Әхвальне Гайсәбәк[кә] язарга карар ителә. |
| [2.] Бәйрәм кичәсе. | Бәйрәм киле[п] йитү сәбәпле, бәйрәм кичәсенә хәзерлекләр күрергә тиешле табыла. Кәрим Тинчураның «Казан сөлгесе»нең бер-ике пәрдәсен кую күздә тотыла. Шул тугрыда 18-ендә киңәш мәҗлесе эшләү тәгаенләнә. Бинаны яһүдләрдән белешү эше К.Әхмәдигә тапшырыла. |
| [3.] Бәйрәм тәбриге. | «Милли байрак»ка Мәдәният җәмгыяте һәм Ата-аналар һәйәте исеменнән тәбрик язу карар ителә. Мәсарифның яртысын (30 сумы) Мәдәният җәмгыяте ала. |

| | |
|---|---|
| [4.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Мәктәп өчен җыелган акчаны Мәрьям Сәйфи тарафлы мәктәп мәсарифенә бирелмәве тугрында фикер алышына. Бу тугрыда алу чараларын күрү кичәдән соңга калдырыла. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(43б кәгазь)* Протокол №61

19 нчы февральдә булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф Әхмәди, Латыйфа Габдрахман, Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Гайниҗамал Ильяс.

[Рәислек итә: Кәшшаф Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

[1.] Бәйрәм кичәсе.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Зур кичә мәсьәләсе, уйнаучыларның булмав[ы] сәбәпле, вакытлыча кичектерелә. Хәзер бәйрәмгә үзара кичә кую хәзерлеген күрү тиешле табыла. Хәзерге җыелыштагы тәкъдим: «Зөләйха»ны уйнау яки үткәндәге «Казан сөлгесе»н кую мәгъкуль табылмый. <br> Зурлар өчен «Уйнаш», балалар өчен «Беренче театр» сайлана. Балаларны хәзерләү Мәдинә ханыма тапшырыла. <br> Бина украиннардан сорарга карарлана. <br> Билет бәһаләре: 50 тиен, 1 сум, 2 сум булып, ертылып сатылачак. Шулай ук өстәл дә хәзерләнәчәк. |

Рәис:
Кятиб: *М.Әхмәди*
Әгъзалар: Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №62

25 нче февраль 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф–Мәдинә Әхмәдиләр, Латыйфа–Кадыйр Габдрахман[нар], Гайниҗамал Ильяс.

[Рәислек итә: Кәшшаф Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Гаяз абзыйның килүе.

| *[чыгарылган карар]* |
|---|
| Мансур Арсланбәктән килгән хат укыла. Гаяз абзыйның тиздән Аурупага сәфәре булачагын мәгълүм иткән. Гаяз абзый авыру булганга, тантаналы каршы алулар булмавын сораган. Бу тугрыда фикер алышканнан соң, Милли идарәгә бу хәбә[р]не мәгълүм итеп, бер киңәш мәҗлесе эшләргә тиешле табыла. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(44а кәгазь)* Протокол №63

2 нче март 1936 [ел]. Җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Кадыйр Габдрахман, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар, Рәхмәтулла Фәтхулла, Әүхәди Җамал.

Рәислек итә: К.Әхмәди.

[Көн тәртибе:]

1. Гаяз абзыйны каршы алу.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Бүген килгән телеграмнан Гаяз абзыйның Харбиннан чыгуы мәгълүм була. Олуг әдибебез һәм юлбашчыбызны ни рәвештә каршылау һәм бу йирдә торачак өч көнне ничек уздыру хакында фикерләр алышына һәм ошбу карарлар чыгарыла.<br>Гаяз абзыйны каршы алыр өчен 4 кешедән гыйбарәт һәйәт сайлана. Сайланган әгъзалар: К.Әхмәди, Әүхәди Җамалетдин, Рәхмәтулла Фәтхулла, Шаһвәли Келәүле.<br>Пароход килеп туктагач ук Гаяз абзый янына керер өчен таможнядан рөхсәт кәгазе алу Кәшшаф, Шаһвәли әфәнделәргә тапшырыла.<br>Хосусый квартирда бер бүлмә һәм шулай ук отельдә бүлмә белешеп кую тиешле табыла. Кайсына төшү Гаяз абзыйның карамагына калдырыла.<br>Ханымнарга бөек кунагыбызны сыйлау эше тапшырыла.<br>Гаяз абзыйның килүен белдереп халык арасына игълан тарату тиешле табылмый (юлбашчыбыз авыру булу сәбәпле).<br>Гаетнең беренче көненә тәгаенләнгән кичә икенче көненә күчерелә.<br>Гаяз абзыйның кәефе мөсагәдә итсә, беренче кичәне ике һәйәт әгъзалары җыелып, киләчәк көндә киңәшү мәҗлесе эшләү тиешле табыла. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Шаһвәли Келәүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №64

10 нчы март 1936 [ел]. Хазир булдылар: Кәшшаф, Кадыйр, Шаһвәли әфәнделәр, Мәдинә, Латыйфа, Гайнижамал ханымнар.
// *(44б кәгазь)* [Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]
1. Гаяз абзый алдында булган бәйрәм кичәсенең тәртибе.
[2. Гомуми җыелыш.]
[3. Ата-аналар һәйәтенең мәгърузасы.]
[4. Кичәнең хисабы.]
[5. Йосыф Акчура ел билгесе.]
[6. Рәхмәт хаты.]
[7. Кичәнең хисабын «Милли байрак»ка йибәрү.]

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1. Гаяз абзый алдында булган бәйрәм кичәсенең тәртибе.] | 1. Балалар тарафлы «Беренче театр» уйналды. Уйнаучылар: Рәшидә, Искәндәр, Тасия, Равил, Нияз.<br>2. Зурлар тарафлы «Каениш» уйналды. Уйнаучылар: Латыйфа, Гайнижамал, Фатыйма ханымнар һәм Шаһвәли, Гали әфәнделәр.<br>3. Әдәбият кыйсеме:<br>– «Төрк баласы» (күмәк җыр);<br>– «Киләчәк-булачак» – Рәшидә;<br>– Татар маршы – Тасия;<br>– «Төрк сүзе» – Нияз;<br>– «Бәйрәм бүген» (җыр) – Тасия, Рәшидә;<br>– Бию – Рәшидә, Надия;<br>– «Бибисара» – Гайнижамал;<br>– Шигырь – Шаһвәли;<br>– Җыр – Фатыйма, Камәр ханымнар.<br>Шаһвәли әфәнденең Гаяз абзыйның бу йирдә булган вакытлары хакында язган мәкаләсе укылып, «Милли байрак»ка йибәрергә карар ителә. |

| | |
|---|---|
| 2. Гомуми җыелыш. | Мәдәният җәмгыятенең керем-чыгу эшләрен тәртипкә кертү эше Кадыйр әфәндегә тапшырыла. |
| 3. Ата-аналар һәйәтенең мәгърузасы. | Ата-аналар һәйәтенең рәисәсе Мәрьям Сәйфи язылу кәгазе буенча җыелган акчаны бирмәве сәбәпле, мәктәп бер тиенсез тора. Мәсарифләр бар. Шуңа күрә Ата-аналар һәйәтенең кятибәсе Латыйфа ханым М[әдәният] ж[әмгыятеннән] сорый мәктәп мәсарифы өчен акча биреп торуны.<br>Фикер алышканнан соң, Латыйфа ханыма мәктәп кирәге өчен кирәкле акчаны биреп тору карарлана. |
| 4. Кичәнең хисабы. | Кичәнең хисабы кабул ителә. |
| // *(45а кәгазь)* 5. Йосыф Акчура ел билгесе. | 11 нче мартта Йосыф бәк Акчураның ел билгесе булганга мәҗлес эшләп, шунда мәгърузачы уларак Шаһвәли әфәнде тәгаенләнә. |
| 6. Рәхмәт хаты. | Мөхәммәдгали Хаҗи әфәндегә мәктәп өчен биргән иганәсенә рәхмәт хаты язарга карарлана. |
| 7. Кичәнең хисабын «Милли байрак»ка йибәрү. | Кичәнең хисабын «Милли байрак»ка йибәрү тиешле табыла. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Шаһвәли Keләүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №65

21 нче мартта 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф, Кадыйр әфәнделәр, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Тукай көненә хәзерлек.

| *[каралган мәсьәлә]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Тукай көне. | Шагыйребез Габдулла Тукайның үлүенә 23 ел тулу мөнәсәбәте белән аңа багышлап рус телендә бер көнлек газет чыгару – К.Әхмәди тәкъдим итә. Тәкъдим кабул ителә.<br>Шулай ук мәгълүм итә: «Слово» газетасының мөхәррире шул газетаны 22 (егерме ике) сумга бастырып бирергә сүз биргәнен.<br>Газетаның мөндәрәҗәсе шул рәвештә булырга тиешле табыла:<br>Баш мәкалә, Тукайның тәрҗемәи хәле, аның әсәрләре хакында – бу эшне Мәдинә ханыма тапшырыла. Шунда ук М[әдәният] ж[әмгыяте] хисабы һәм эшләгән эшләре // *(45б кәгазь)* хакында мәгълүмат бирү.<br>Газетны чыгару өчен рөхсәт алу эше Кадыйр әфәндегә тапшырыла.<br>Газетаның мәсарифы игъланнар белән капланачак. Игълан җыю эшен Кәшшаф Әхмәди үз өстенә ала. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №66

26 нчы март 1936 ел. Җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф, Кадыйр әфәнделәр, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Газета хакында.
2. Нанкингә бару.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Газета хакында. | Газета хакында фикер алышынила. Газетаның күләме гади газет рәвешендә булып, ике бите мәкаләләр, өченче битендә хисап, Мәдәният җәмгыятенең барышы хакында, калган урыннар игъланнарга. |

| | |
|---|---|
| [2.] Нанкингә бару. | Газетны бар оешмаларга сатар өчен таратырга. Җыелган акча Мәркәз идарәсенә. Шанхайда урамда сатарга.<br>Кадыйр әфәнде рөхсәт өчен Апрелевка барган, ләкин ул Мәдәният җәмгыятенең әгъзаларының тәрҗемәи хәлләрен язып китерүне сораган. Бу эш Кадыйр әфәндегә тапшырыла.<br>Гайсәбәк әфәнделәр мәктәп шәкертләрен // *(46а кәгазь)* һәм сәхнәдә уйнаучы зурларны Нанкиндә дә уйнар өчен чакырырга исәпләре булганны белдергән. Чакыру тиз булу ихтималын күздә тотып, балаларны хәзерләү эше Мәдинә ханыма тапшырылына. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №67

8 нче апрель. Җыелышта хазир булдылар: К.Әхмәди, Мәдинә, Латыйфа ханым, Гайниҗамал ханым һәм чакырылган халык: Әүхәди әфәнде, Шамил, Ибраһим, Исмәгыйль Мамлиләр, Бәдри Йосып.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Рус газетасында Гаяз әфәнденең «Идел-Урал» китабы хакында язылган мәкалә.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| Колосова тарафлы язылган мәкалә халкыбызның барысын ифрат возмущать[29] иткән. Шуңа нинди хәрәкәт кирәклеге тугрында фикер алышыныла.<br>Кәшшаф әфәнде тәкъдим итә: халкыбызны барысын җыеп, шушы мәкаләне укып чыгарга һәм Колосова үзенең мәкаләсендә безне тәхкыйр иткәнен халыкка аңлатырга. Шуның белән рус артыннан йөрүче халыкларыбызга русларга каршы караш тудырылачак. Икенче – бик каты мәкалә язарга. Әлбәттә, рус газеталары аны язмас, шуңа күрә брошюра рәвешендә шуны язып барыбер аңлатырга.<br>Ибраһим Мамли тәкъдим итә: «Наш путь» газетасының редакция- |

[29] Бу сүз рус хәрефләре белән язылган.

| |
|---|
| сенә барып сөйләшергә һәм Колосова үзен[ең] сүзен кире алсын» ди. Бу фикергә күпчелек катнаша һәм бүген үк шунда барыр өчен Кәшшаф Әхмәди, Әүхәди Җамал, Бәдри Йосыф, Мәдинә Әхмәди сайланалар[30]. |

Рәис:

Кятиб: *М.Әхмәди*

[Әгъзалар:] *Габдрахмани*

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(46б кәгазь)* Протокол №68

15 нче апрель 1936 [ел]. Хазир булдылар: Кәшшаф, Кадыйр әфәнделәр, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал ханымнар, Рәхмәтулла Фәтхулла һәм Шәриф Дүзи.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Колосовага җавап.

2. Тукай кичәсе.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Колосовага җавап. | Мәдинә ханым тарафлы Колосовага язылган җавап укылып чыгыла һәм шуны летучка рәвешендә бастырырга карарлана. Басу мәсарифе 8 [сум] булачак. Бастыру эше Кәшшаф әфәндегә тапшырыла. Летучкаларны бар йирләргә йибәрергә тиешле табыла[31]. |

[30] М.Колосова мәкаләсе басылган газета исеме җыелыш беркетмәсендә «Наш путь» дип язылган булса да, башка чыганаклардан аның «Новый путь» исемле булганлыгы ачыкланды. Ихтимал, бу мәсьәлә шул бер үк газетаның башта «Наш путь» исеме белән чыгып, атамасы «Новый путь» дип үзгәртелгәнгә бәйледер. Совет разведкасының 1934 елгы бер документында ак эмигрантларның «Наш путь» исемендәге газетасы «фашистик» дип телгә алынган. (Гаяз Исхакый: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт.: С.Рәхимов, З.Мөхәммәтшин, А.Заһидуллин. – Казан: Җыен, 2011. – Б. 733).

[31] Колосованың «Новый путь» газетасының 1930 елгы 150 нче санында басылып чыккан мәкаләсенә каршы М.Салиәхмәтнең «Наш ответ» исемендәге язмасының фоторәсеме һәм бу вакыйганың тарихы Ә.Кәримуллинның «Язмыш, язмыш..» китабында (53–55 битләрдә) басылган иде. Тик Ә.Кәримуллинның бу хәлләрне 1934 елда (53 бит) булган дип язуына гына төзәтмә таләп ителә. Бу нәфрәт язмасы ничек таратылуы турында Кәримуллин болай дип язды: «Кадыйр әфәнде Габдрахман велосипедка атланып, бу листовкаларны таратып йөри, стеналарга ябыштыра. Һәрхәлдә, ак эмигрант урыс шовинистларына тиешле җавап җиткерелә» (54 бит). «Наш ответ» документының тексты бу китапның кушымтасында бирелде.

| | |
|---|---|
| [2.] Тукай кичәсе. | Шагыйребезнең ел билгесенә багышлап чыгарырга уйлаган газет, мәкаләләр язылып өлгермәү сәбәпле, чыга алмады. Ләкин кичә эшләргә карарланды.<br>Кичәнең тәртибе:<br>– Тукай хакында баш сүз – К.Әхмәди,<br>– Коръән – балалар тарафлы укылачак,<br>– Тукай тугрында мәгъруза – М.Әхмәди,<br>– Тукай маршы (күмәк җыр).<br>Балалар кыйсеме:<br>– Кечкенә шигырь – Рифгать,<br>– «Сөткә төшкән тычкан» – Равил,<br>– «Эш» – Камал,<br>– Тасия, Нияз, Рәшидә – «Таз малай», «Су анасы» балалар тарафлы уйналачак.<br>Йыйу: кичәнең мәсарифын халыктан иганә кәгазе белән йыярга. Чәй хәзерләргә.<br>Акча җыю эше Мәһәрбану ханым белән Мәрьям ханыма тапшырыла. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(47а кәгазь)* Протокол №69[32]

Хазир булдылар: Кәшшаф әфәнделәр[33], Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Тукайның илле еллыгын яд итү.
2. Нанкингә бару.
3. Украиналарга бару.
4. Мәктәп хакында.
5. Нәүбәттәге мәсьәләләр.

[32] Датасы язылмаган. Тик Х.Габдүшнең монда телгә алынган мәкаләсе «Милли байрак» газетасының 1 май санында чыкканлыгын исәпкә алганда, бу җыелыш май ае башында узгандыр дип фаразларга мөмкин.
[33] Кадыйр исеме башта язылып аннан соң сызылган.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Тукайның 50 еллыгын яд итү. | Быел шагыйребезнең тууына 50 ел тулганга, шул көнне 12 нче июньдә, беренче роман[34] чыгуга 50 ел вакыт тулган көнне эшләү тугрында Хөсәен Габдүшнең фикерен куәтләп, шул көннәрнең ядкаре уларак, Кәшшаф әфәнде тәкъдим итә Мәркәз янында китап кибете ачуны. Шунда бар мөһаҗәрәттә чыга торган безнең хәрәкәтебезгә, тарихыбызга, әдәбиятыбызга гаид әсәр, мәҗмугаларны китерергә, шуның фондына 12 нче июньнән ят җирләрдә акча туплап.<br>М.Әхмәди тәкъдим итә – Мәркәз янында матбага вөҗүдкә китерү, шуның өчен акча җыю.<br>Соңгы тәкъдим кабул ителә. Шуны «Милли байрак»ка язарга карар ителә. |
| [2.] Нанкингә хат. | Балаларның әҗнәби мәктәпләрендә хәзер имтиханнарга кызу хәзерлекләр барганга, Нанкингә имтиханнар беткәч кенә барырга имкян булачагын белдереп язарга. |
| [3.] Украиналарга бару. | Алдагы украиналарның милли бәйрәмнәре мөнәсәбәте белән эшләнәчәк мәҗлесләренә Мәдәният җәмгыятеннән күбрәк әгъзалар бару матлуб табыла. |
| // *(47б кәгазь)*<br>[4.] Мәктәп хакында. | Мәктәпнең мөгаллимәсенә 2 ай мәгаш түләнмәгәнгә, Мәрьям ханым Сәйфидән тиешле акчаны Милли идарәгә тапшыруын сорап хат язарга. |
| [5.] Нәүбәттәге мәсьәләләр. | Ничек тә тиз көннәрдә, Милли идарә бүлмә алу белән, гомуми җыелыш эшләргә. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

Протокол №70

18 нче май 1936 [елда] булган җыелышта хазир иделәр: Кәшшаф, Шаһвәли әфәнделәр, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Низамнамә.
2. Гомуми җыелыш.

[34] Муса Акъегетзаднең 1886 елда Казанда басылып чыккан «Хисаметдин менла» әсәре күздә тотыла.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Низамнамә. | Низамнамәгә, Шанхай вәзгыятенә карап, кайбер маддәләрне үзгәртү кирәклеген Кәшшаф әфәнде тәкъдим итә. Низамнамә маддә-маддә тикшерелә һәм ошбу маддәләргә төзәтү кертелә:<br>6 маддә – Мәдәният җәмгыятенә әгъза булырга эстәгән кеше Мәдәният җәмгыятенең Башкармасының карамагы буенча гына әгъзалыкка алынырга тиеш.<br>7 [маддә] – Фәкать рәис кенә гомуми җыелыш тарафлы сайла[на].<br>8 [маддә] – Башкарма 5 әгъзадан дүрт // *(48а кәгазь)* урын ясаудан мөрәккәб булырга тиеш.<br>10 [маддә] – Җәмгыятьнең хәзинәсе әгъзалык бәдәленнән, иганәләрдән, кичәләрдән килгән виргәләрдән гыйбарәт. Әгъзалык бәдәле 20 тиен тәгаенләнелә.<br>14 [маддә] – Җәмгыять ябылган тәкъдирдә, мал-милек Мәркәз идарә карамагына тапшырыла. |
| [2.] Гомуми җыелыш. | Гомуми җыелыш өчен Мәдәният җәмгыятенең низамнамәсен 20 данә язып хәзерләү эше Гайниҗамал ханыма тапшырыла.<br>Гомуми җыелыш ошбу тәртип белән уздырылырга тиеш:<br>1. Фәхри рәислеккә сайланылган Гаяз әфәндене тәсдыйк иттерү.<br>2. Фәхри әгъзалыкка сайланылган Сәед Җәгъфәр әфәндене тәсдыйк иттерү.<br>3. Мәдәният җәмгыятенең мәгърузасы – рәис.<br>4. Сәяси мәгъруза – рәис.<br>5. Хисап – Шаһвәли Келәүле.<br>6. Тәфтиш һәйәтенең мәгърузасы.<br>7. Низамнамәгә кертелгән яңгалыклар хакында мәгъруза.<br>8. Идарәгә рәис сайлау.<br>9. Әгъзалар сайлау.<br>10. Тәфтиш һәйәте сайлау.<br>11. Нәүбәттәге мәсьәләләр. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*

[Әгъзалар:] *Шаһвәли Keләүле*
*Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

// *(48б кәгазь)* Протокол №71

8 нче июнь 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф, Мәдинә, Латыйфа, Гайниҗамал.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Мәктәп ябу һәм шуннан чыккан мәсьәләләр.
2. Нанкингә хәзерлек.

| *[каралган мәсьәләләр]* | *[чыгарылган карарлар]* |
|---|---|
| [1.] Мәктәп ябу. | Быелгы уку елын тәмамлау көне 14 нче июньгә тәгаенләнелә.<br>Мәҗлеснең тәртибе:<br>1. Мәктәп хакында мәгъруза.<br>2. Балалар бакчасы хакында мәгъруза – М.Салиәхмәд.<br>3. Балаларга шагыйребез Тукайның рәсемен бүләк итеп бирү.<br>4. Хәтем.<br>Ябу мәҗлесе украиннарда 14-ендә, кичке сәгать 5-кә тәгаенләнелә.<br>Балаларны рәсемгә алу тиешле табыла. |
| [2.] Нанкингә хәзерлек. | Нанкингә чакыру килсә, балалар тарафлы ошбу нәрсәләр уйналачак: «Беренче театр», Тукайның «Таз», «Су анасы».<br>Уйнаучылар: Тасия, Рәшидә, Нияз, Равил, Камал.<br>Уйналачак әсәрләрнең мәфһүмен язып Нанкингә йибәрергә карарлана. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
[Әгъзалар:] *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*



Беркетмәләр дәфтәре. 48б кәгазь.

// *(49а кәгазь)* Протокол №72

8 нче июль 1936 елда булган җыелышта хазир булдылар: Кәшшаф Әхмәди, Шаһвәли Келәүле, Латыйфа, Мәдинә, Гайниҗамал ханымнар.

[Рәислек итә: К.Әхмәди.]

[Көн тәртибе:]

1. Гомуми җыелышта иштиракь итәргә хаклы[35] халык.
2. Игъланнар хәзерләү.
3. Гомуми җыелышның көне һәм тәртибе.
4. Гомуми җыелышта укылачак мәгърузалар тәсдыйк итү.

| *[чыгарылган карарлар]* |
|---|
| 1. Рус газеталарында язарга «Гомуми җыелышта фәкать Мәркәзгә табигъ булган Милли идарәнең генә әгъзалары керә ала» дип. Мөхалифләр ягындагы кешеләр гомуми җыелышка кертелмиләр.<br>2. Гомуми җыелышның вакытын белдереп игълан таратырга.<br>3. Гомуми җыелышның көне 13 нче июль 1936 [ел], Ав. Фош, 720[36] булачак. Гомуми җыелыштагы бар халыкны әгъза итеп хисапларга.<br>Гомуми җыелышның көн тәртибе Протокол №70-чә кала. Фәкать 7 мәсьәлә уларак китапханә һәм хуҗалык кертелә.<br>4. Гомуми җыелышта укылачак Идарәнең мәгърузасы, хисап, китапханә хисабы, хуҗалык хисаплары укылып кабул ителәләр. |

Рәис:
Кятиб: *М.Салиәхмәд*
Әгъзалар: *Габдрахмани*
Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильясия*

[35] Бу сүз документта ялгыш «халыклы» дип язылган.
[36] «Ав. Фош, 720» – җыелыш узачак адресны (Авеню Фош) белдерә.

# ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ

Абызов – протокол №10
Акбирдин Шамил – пр. №№54, 58, 67
Акчура Йосыф – пр. №№34–36, 38, 48, 64
Апрелев – пр. №66
Арсланбәк (Арсланбик) Мансур – пр. №№1–32, 45, 46, 48–55, 57, 58
Әхмәди Исхак – пр. №№1–4, 20
Әхмәди (Салиәхмәт) Кәшшаф – пр. №№1–20, 23, 25–72
Әхмәди (Салиәхмәт) Равил – пр. №№57, 64, 68, 71
Багдан Миргали – пр. №58
Байгилди – пр. №59
[Баруди] Галимҗан – пр. №2
Баязиди (Баязид, Баязидов) Шакир – пр. №№2, 5, 6, 34–36, 40–46, 48, 51, 54, 58
Бурнаш [Фәтхи] – пр. №58
Габдрахмани Кадыйр – пр. №№2–4, 8–72
Габдрахмани Латыйфа – пр. №№1–18, 20–50, 53–72
Габдрахман Надия – пр. №№35, 54, 57, 58
Габдрахман Нияз – пр. №№57, 64, 71
Габдрахман Тасия – пр. №№57, 64, 68, 71
Габдүш Хөсәен – пр. №№58, 60, 69
Газзә абыстай – пр. №№40, 45, 46
Гайсәбәк әфәнде – пр. №№57, 60
Гамилә ханым – пр. №18
Гаспралы Исмәгыйль – пр. №№2–4, 8, 48
Гафури Мәҗит – пр. №№26, 34, 35
Гыйффәт Сания – пр. №1
Дәүләтгилди Ибраһим – пр. №№10, 11, 14
Дүзи Гали – пр. №№27, 42, 58, 64
[Дүзи] Искәндәр – пр. №64
Дүзи Сөнәгать – пр. №№5, 9–14
Дүзи Фатыйма – пр. №№27, 58, 64
Дүзи Шәриф – пр. №68
Җамал (Җамалетдин) Әүхәди – пр. №№14, 35, 36, 41, 63, 67
Җәгъфәр Сәед Әхмәд (Җәгъфәр Сәед) – пр. №№1, 50, 54, 70
Зиннур әфәнде – пр. №10
Зыятдин Әхкям – пр. №58
Ибраһим Хәсән – пр. №№10, 14, 27, 28
[Ибраһимов] Габдеррәшид – пр. №4
«Идел-Уралчы» – пр. №11
Идриси Галимҗан – пр. №6
Ильясия (Ильяси, Ильяс) Гайниҗамал – пр. №№1–5, 7–43, 45–72
Ильяс Рәшидә – пр. №№57, 64, 68, 71

Исхакый (Исхак) Гаяз – пр. №№1–3, 9, 10, 12, 13, 16, 24, 28, 48, 56, 62–64, 67, 70
Йосыф (Йосып) Шәйхулла – пр. №№58, 60, 67
Камал Галиәсгар – пр. №27
Камәр ханым – пр. №64
Keләүле Шаһвәли – пр. №№1–7, 11, 17–32, 46, 48–52, 54, 55, 57, 63, 64, 70, 72
Колосова [М.] – пр. №№67, 68
Корбангали [Габделхәй] – пр. №№8, 25, 41, 43, 56
Максуди Фәйзрахман – пр. №№43, 44
Мамли Ибраһим – пр. №№36, 42, 67
Мамли Исмәгыйль – пр. №67
Мамли Хәниф – пр. №№40–44
[Мәрҗани] Шиһабетдин – пр. №№2, 59
Мәһәрбану ханым – пр. №68
[Мостафа] Камал – пр. №№68, 71
Мостафа Камал паша – пр. №1
Мөхәммәтҗанов (Мөхәммәтҗан) Шәрәфи – пр. №№18, 27, 40, 42, 43, 45, 46, 53, 54, 59
Мөхәммәтҗан Фатыйма – пр. №27
Мөхәммәтзадә – пр. №50
Петлюра – пр. №39
Рамазани (Рамазанов) Хәмит – пр. №№28, 32
Рәсүлзадә Мөхәммәд Әмин бәк – пр. №1
Рәүф әфәнде – пр. №42
Рәшид – пр. №№54, 58
[Салиәхмәд] Гыйнәятулла хәзрәт – пр. №10
Салиәхмәд (Әхмәди, Әхмәдия) Мәдинә – пр. №№1–40, 45, 46, 48, 50–72
Сали Әхмәд – пр. №46
Сәйфи Гариф– пр. №№10, 14, 15, 47, 54
Сәйфи Мәрьям – пр. №№49, 60, 64, 68, 69
Тинчура Кәрим – пр. №60
Тукай Габдулла – пр. №№33–36, 52, 65, 68, 69, 71
Тупчибаш Галимәрдан – пр. №№26, 34, 35
Фәтхуллин (Фәтхулла) Рәхмәтулла – пр. №№14, 25, 58, 63, 68
Фирдәүси – пр. №4
Хаҗи Мөхәммәдгали – пр. №64
[Хаҗи] Рифгать – пр. №68
Хәлиуллин Мөхәммәтнур – пр. №№10, 11
Хәнифә ханым – пр. №5
Хисаметдин (Хисам) Зыятдин – пр. №№43, 44
Чукай Мостафа – пр. №1
Яушева Зөһрә  – пр. №№28, 32

## ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ

Азәрбәйҗан – протокол №№2, 39, 49
Аурупа (Яурупа) – пр. №№41, 59, 62

Дайрен – пр. №28

Ерак Шәрык – пр. №№10, 17, 25, 41–43, 48, 51, 56, 58

Идел – пр. №1
Идел-Урал – пр. №№1–3, 6, 9–11, 28, 43, 49, 50, 56, 57, 67
Иран – пр. №4

Казан – пр. №№3–6, 60, 61
Кейҗо (Сеул) – пр. №28
Кобе – пр. №№3, 17, 28
Кумамото – пр. №№3, 6, 28
Кырым – пр. №№2, 49
Кытай – пр. №57

Мукден – пр. №№3, 10, 11, 14, 17, 20, 23, 28, 32, 51

Нагоя – пр. №№3, 28
Нанкин – пр. №№10, 14, 27, 28, 57, 66, 69, 71

Россия – пр. №№3, 20

Тәнзин (Тяньцзинь) – пр. №№28, 58
Токио – пр. №№3, 9, 28, 51
Төркия – пр. №№1–3, 5–7, 20, 42, 48, 49, 51
Төркестан – пр. №№2, 3, 28, 49, 57

Украина – пр. №№15, 31, 32, 39, 45, 46, 48, 49, 53, 69

Хайлар – пр. №№9, 28, 40, 45, 46
Харбин – пр. №№3, 10, 27, 28, 40, 46, 62, 63

Чанчунь – пр. №28

Шанхай – пр. №№1–3, 5, 8–10, 12–14, 16, 17, 19, 20, 23, 25, 30, 37–40, 43–45, 50, 52, 57, 66, 70, 71
Шәркый Төркестан – пр. №№57, 58

Япония – пр. №№7, 18

# ҖЫЕЛЫШ БЕРКЕТМӘЛӘРЕ ЯЗЫЛГАН ДӘФТӘРНЕҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең 1934–1936 еллардагы җыелыш беркетмәләре язып барылган, хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «685т» шифры белән саклана торган кульъязма дәфтәр 20х27,5 см зурлыкта. Катыргы тышлыгының өслеге кара, ә төп ягы һәм кыйгачлап эшләнгән ике почмагы кызыл төстәге дермантин белән тышланган. Һәр битенә тонык кына юллар төшерелгән бу дәфтәр XX гасырның беренче яртысында Европада эшләнгән, ул чор өчен гадәти «контора дәфтәре».

Дәфтәрнең гомуми күләме 58 кәгазьдән гыйбарәт. 2а–49а кәгазьләре язулы, ә калган 49б–58б кәгазьләре язусыз.

Сакланышы яхшы.

Кульъязма 2а кәгазьдә «Протокол №1» дигән сүзләр белән башлана һәм ул 1934 елның 7 сентябренә карый. Кульъязманың ахыры 49а кәгазьдә, 1936 елның 8 июленә караган «Протокол №72» белән тәмамланган.

Кәгазендә латин хәрефләре белән язылган филиграньнар бар.

Дәфтәрдәге текстлар төрле төстәге химик каралар белән язылган. Ягъни, 2а–7а, 9а–13а, 16а–37б кәгазьләрдә – шәмәхә, 7б–8а, 49а кәгазьләрдә – ачык зәңгәр, 8б кәгазьдә – караңгы зәңгәр, 13б–15б кәгазьләр һәм 37б кәгазьнең яртысыннан 48б кәгазьгә хәтле – ачык һәм караңгы көрән төсләрдәге каралар белән язылган.

Дәфтәрнең 1а–13а кәгазьләрендәге 1–11 нче санлы протоколлар ачык аңлаешлы язу белән теркәлгән. Ул, күрәсең, баштагы караламадан пөхтә итеп күчерелгән. Боларның кем кулы белән язылганлыгы мәгълүм түгел. Кульъязманың бу өлеше гарәп язуының нәсех төренә карый. Ә 13б–49а кәгазьләрдәге 11 нче протоколның яртысыннан алып 72 нче санлы протоколга хәтле барлык текстлар Мәдинә Салиәхмәт тарафыннан язылганнар. Бу өлеше гарәп язуының тәгъликъ һәм рокга төрләренә якынрак дип әйтергә ярый.

Беркетмәләрне язган кеше тарафыннан төп текстта ялгыш язылган сүзләр кайбер очракларда төзәтелгән, сызылган яисә, хата икәнлеген билгеләү өчен, ике ягыннан җәяләр белән аерып куелган.

Дәфтәрнең 8б кәгазендә 4 нче санлы протоколның башындагы берникадәр өлеше ялгыш икенче мәртәбә күчерелгән. Аннан соң, шул ук битнең түбәнге өлешенә мондый искәрмә язылган:

«4 нче нумер протокол икенче мәртәбә язылганга, бу протоколны санамаска.

Рәис: *Кәшшаф Әхмәди*

Сәркятиб:

Әгъзалар:

Тәфтиш һәйәтенең әгъзасы: *Г.Ильяс*».

Беркетмәләр журналының палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, кайбер сүзләрдә «б» хәрефе урынына «п» язылган. Мәсәлән, 6а кәгазьдәге «ошбу» сүзе «ошпу» дип язылган. Хәрефләр бер-берсенә ялганып бетмичә язылган урыннар бар һәм алар укылышны читенләштерә. Шулай ук өч нокталы хәрефләрнең нокталары, гадәттә, бер яисә параллель ике кыска сызык белән белдерелгән. Текстлар, нигездә, гарәп әлифбасының иске имлясы белән язылган булса да, яңа имля хәрефләре кушып язылган очраклар да бар. Мәсәлән, «а» хәрефенең сүз башында язылу шәкеле (آ һәм ئا), шулай ук «у» хәрефенең дә сүз башындагы язылышы (او һәм ئو) бер үк текстта, ике төрле имлядагыча, катыштырып язылган. Мәдинә Салиәхмәтнең «гайн» хәрефенең сүз башындагы (ع рәвешле) язылышын, ашыгычлык сәбәпледер, үзенчәлекле язган булуы да текстның укылышын кыенлаштыра. М.Салиәхмәт почеркында «гайн» хәрефенең өске ыргаксыман ярымтүгәрәк өлеше бөтенләй язылмаган.

Дәфтәрнең битләренә куелган үз пагинациясе бар. Ул 1–69 битләрдә (2а–36а кәгазьләрдә) шәмәхә, 70–81 битләрдә (36б–42а кәгазьләрдә) көрән төстәге каралар белән һәм 82–105 битләрдә (42а–49а кәгазьләрдә) гади карандаш белән язылган.

Кульязма дәфтәр китапханәгә Америка Кушма Штатларының Калифорния штатында яшәүче татарлар җәмгыяте президенты Равил Салиәхмәттән 1993 елда алынды. Р.Салиәхмәт тарафыннан дәфтәрнең 1б кәгазендә соңгы чорда латин хәрефләре белән түбәндәгечә язып куелган:

«Şanghai Turko-Tatar Cemgiyeti idaresi cıılışlari

5 Sintiabr 1934 –

K.Ahmedi = Keşşaf Seliahmet

Ş.Klauli = Şahgadi İldar

M.Ahmedi = Medine Seliahmet»

Р.Салиәхмәтнең Ш.Келәүлене Шаһгади (Шаһһади) рәвешендә язуы хата булса кирәк. Чөнки бу кешенең исеме безгә билгеле булган бүтән чыганакларның барысында да фәкать Шаһвәли буларак кына язылган.

Бу кулъязма турында моңарчы мәгълүмат басылды:

1. Мәрданов Р. Серле китап, кулъязмалар... / Әңгәмәдәш – Энже Гәрәева // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 13 май.

2. Мәрданов Р. Энҗе-алмаслар югалмас... // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1997. – №3/4. – Б. 22.

3. Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2002. – №1. – Б. 19.

4. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 136.

5. Мәрданов Р.Ф. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – Б. 20, 74. – («Татар археографиясе» сериясе; 5 нче китап).

6. Мәрданов Р. Татарстан Милли китапханәсендә татар һәм көнчыгыш кулъязмаларын туплау һәм өйрәнү тәҗрибәсеннән // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения: материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / составители: Р.Ф.Исламов, С.Ф. Галимов. – Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2011. – Б. 50.

# КУШЫМТА

## ЕРАК ШӘРЫКТӘН

Шанхайда яшәүче төрк-татарлар 1933 ел 17 нче декабрьдә «Шанхай Төрк-татар яшьләр оешмасы» төзеделәр. Шушы оешма үзенең эшләгән эшләре хакында 1934 ел 30 нчы июньдә гомуми җыелыш ясап хисап бирде. Кыска гына мөддәт эчендә эшләнгән эшләр тугрында рәис К.Әхмәди әфәнде тарафыннан мәгъруза ясалды. Яшьләр оешмасы шул мөддәт эчендә 4 конферанс бирдергән:

1) Шәркый Төркестан ватандашларымызның хәтты хәрәкәте хакында – Гайсәбик әфәнде;

2) Нанкин дарелфөнүнендә укучы Шәркый Төркестан ватандашларымыз җәмгыяте хакында – Әдһәм әфәнде;

3) Яшьләр арасында милли хәрәкәт – Хәсән Ибраһим;

4) Идел-Урал истикъляль хәрәкәте һәм Гариф Кәриминең тәрҗемәи хәле; төркчелек юлында эшләнгән хезмәтләр хакында – К.Әхмәди.

Бу арада 3 мәртәбә милли тормышыбыздан сәхнәдә пьесалар уйналган. Кичәләрдә милли көй, җырлар җырланып, яшь шагыйрьләремез Исхак Әхмәди һәм Мансур Арсланбикләрнең шигырьләре укылып, халыкка зур тәэсир калдырылган.

Яшьләр оешмасы төзелгәнгә кадәр Шанхайда кичәләр дә, конферанслар да эшләнмәгән булган. Яшьләр оешмасы төзелү берлә вә оешманың бөтен әгъзалары бер кеше уларак иштиракь итүләре аркасында, хәзер сәхнәдә яхшы гына уйнаучы көчләремез табылып, шулай ук хор һәм оркестрлар да төзелде. Яшьләр оешмасы милли матбугатымызда армый-талмый хезмәт итүчеләрне тәкъдир итүдә һәм милли истикъляль җәбһәләренең нәшриятын укырга халыкны дәгъвәт итүдә байтак кына эшләр эшләде.

Гомуми җыелышның мәгърузасы беткәннән соң, Шаһвәли әфәнде тарафыннан башка шәһәрләрдә Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте төзелгәне шикелле, Шанхай Яшьләр оешмасын да «Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте»нә әйләндерү тәклиф ителде. Бу фикергә бер кем дә каршы килмичә, 6 кешедән мөрәккәб бер һәйәт сайланып, тизлектә «Идел-Урал мәдәнияте җәмгыяте»не вөҗүдкә чыгарырга карар кылынды.

Идел-Уралчы.

*«Яңа милли юл» журналы (Берлин). – 1934. – №10. – Б. 26.*

## ТӘГЪЗИЯ

Төркчелек өчен бөтен яшь гомерен сарыф кылып, безнең арадан вакытсыз киткән Гариф әфәнде Кәриминең вафаты Шанхайда яшәүче төрк-татарларга зур тәэсир итте. Шушы мөнәсәбәт берлә Шанхай Төрк-татар яшьләр оешмасы Шанхайда яшәүче милләттәшләремезне җыеп, оешманың рәисе К.Әхмәди тарафыннан Идел-Урал истикъляле һәм бөтен төрк өлкәләрендә булган хәрәкәтләр тугрында мәгъруза укылып, Гариф әфәнде Кәриминең тәрҗемәи хәле һәм дә төркчелек өчен кылган хезмәтләре халыкка гарыз кылынганнан соң, аның рухына Коръән укылды вә Гариф әфәнденең рәсемене Яшьләр оешмасының идарәсендә сакларга карар ителде. Җыелган халык мөтәәссир булып, төрк-татар истикъляле өчен көрәшүчеләремезгә сәламәтлек, сафларымызның ныгуын, көчләремезнең артуын теләп мәҗлес таралды.

Шанхай, 5 июль.

Идел-Уралчы.

*Яңа милли юл. – 1934. – №10. – Б. 26–27.*

## ШАНХАЙ ТӨРК-ТАТАР МӘДӘНИ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ НИЗАМНАМӘСЕ

Шанхайда яшәүче төрк-татарлар 7 нче сентябрьдә булган гомуми җыелышларында Шанхай Төрк-татар мәдәни җәмгыятене тәэсис иттеләр. Һәйәте идарәгә түбәндәге ханым вә әфәнделәр сайландылар: рәис – Кәшшаф Әхмәди, сәркятиб – Исхак Әхмәди, хәзинәдар – Шаһвәли Келәүле; әгъзалар – Мансур Арсланбик, Кадыйр Габдрахман, Мәдинә Әхмәди, Латыйфа Габдрахман.

Шанхай Төрк-татар мәдәни җәмгыятенең низамнамәсе түбәндәгечә:

1. Җәмгыятьнең исеме «Шанхай Төрк-татарларның мәдәни җәмгыяте»дер.

2. Җәмгыятьнең идарәсе Шанхай шәһәрендәдер.

3. Җәмгыятьнең төп максаты – төрк-татар мәдәниятене саклаудыр.

4. Җәмгыять шул максатка ирешү өчен түбәндәге эшләрне кылырга карар бирде:

а) милли тарих, мәдәният вә әдәбият хакында конферанслар эшләү;

б) милли әдәбият аркылы яшьләремезне тәрбияләү өчен әдәбият кичәләре ясау вә кичке курслар ачу;

т) милли максатка хезмәт итәчәк китап вә рисаләләр нәшер итү;

с) гайни максатка хезмәт иткән Идел-Урал мәдәнияте җәмгыятьләре берлә мөнәсәбәткә керү;

ж) көтепханәләр ачу.

5. Җәмгыятьнең әгъзалары «хакыйкый», «кандидат», «фәхри» исемнәре астында 3-кә бүленәдер.

6. Җәмгыятьнең беренче ачылу мәҗлесенә катнашкан әгъзалар хакыйкый әгъзалардыр. Яшьләре тулмаган төрк-татар әгъзалар кандидат хисапланалар. Җәмгыятьнең низамнамәсен кабул иткән, җәмгыятьнең максатына хезмәт иткән башка милләт кешеләре фәхри әгъза булалар.

7. Җәмгыятьнең эшләре махсус мәҗлестә сайланган идарә әгъзалары тарафыннан идарә ителәдер. Идарә әгъзалары, хакыйкый әгъзалар арасыннан бер ел мөддәткә сайлана вә саннары 5 кешедән мөрәккәбтер. Рәис, сәркятиб, хәзинәдар гомуми җыелыш тарафыннан сайлана.

8. Идарә әгъзалары һәйәте идарә тәшкил итәләр; һәйәт әгъзаларының саны гомуми җыелышның карамагына баглы булып, бер рәис, бер сәркятиб, бер хәзинәдар булуы мәҗбүридер.

9. Гомуми җыелыш, хакыйкый әгъзалардан бер ел мөддәт берлә, өчтән ким булмау шарты берлә, тәфтиш һәйәте сайлыйдыр.

10. Бу һәйәтнең хәзинәсе, әгъзалык түләүләреннән, җәмгыятькә бирелгән бүләк вә иганәләрдән, кичәләрдән кергән вәридатлардан гыйбарәттер. Һәрбер әгъза ай саен 50 тиеннән ким булмау шарты илә, кандидатлар 25 тиеннән ким булмау шарты илә, җәмгыятьнең хәзинәсенә түләү кертергә тиешледер.

Шанхай төрк-татар Мәдәни җәмгыятенең
киләчәк 1934-35 ел эчендә эшләнергә тиешле булган эшләре:

1. Идел-Урал истикъляллен халкыбызга аңлату өчен, Идел-Урал истикъляль фикерен таратучы, Гаяз әфәнде Исхакый тарафыннан чыгарыла торган «Яңа милли юл» мәҗмугасен халык арасында таратырга.

2. Идел-Урал истикъляле бөтен төрк өлкәләренең истикъляле берлә баглы булганга, шул юлда язучы мәҗмугаләрне: Төркестан истикъляль фикерен таратучы «Яшь Төркестан»ны, Азәрбәйҗан истикъляль фикерен таратучы «Истикъляль», Кырым истикъляль фикерен таратучы «Әмәл» мәҗмугаләрен төрк-татарлар арасында таратырга.

3. Шанхайда, айда бер мәртәбә генә булса да, татарча мәҗмуга чыгарырга.

Искәрмә: башка милләтләргә истикъляллебезне аңлату өчен әҗнәби газитәләрдә шул тугрыда язарга.

4. Конферанслар эшләү: 1) Төрк-татар тарихы; 2) 1905 нче елдан башлап бүгенгә кадәрле милли хәрәкәт; 3) Төркестан тарихы һәм милли хәрәкәте; 4) Азәрбәйҗан тарихы һәм милли хәрәкәте; 5) Кырым тарихы һәм милли хәрәкәте; 6) Төркия тарихы вә Төркиядәге милли агымнар; 7) төрк-татарларның әдәбияты; 8) төрк-татар теле, мусыкасы; 9) төрк-татарларның театры хакында; 10) төрк-татарлар өчен эшләгән бөекләремезне таныту; 11) милли бәйрәмнәрне бәйрәм итү; 12) төрк-татарлар арасында уку-язу белмәүне бетерү өчен курслар ачу, шулай ук латинча курслар ачу; 13) мусыка курслары ачу; 14) мәктәп балаларымызны милли тарихымыз, әдипләремез, шагыйрьләремез һәм төрк-татарларга хезмәт иткән кешеләремез берлә таныштыру; 15) чит милләтләрнең гәзитәләрендә төрк-татарларга гаид булган мәкаләләрне җыеп, һәр ай саен шул тугрыда халкымызга мөгъруза эшләргә; 16) бөтен милли-мәдәни һәйәтләр берлә якын мөнәсәбәткә керергә.

Рәис: Кәшшаф Әхмәди.

Сәркятиб: Шаһвәли Келәүле.

*Яңа милли юл. – 1934. – №12. – Б. 25–26.*

## ШАНХАЙДА ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕ

Бу зур космополит һәм финанс үзәге саналган шәһәргә татарларның йөрешүләре 1920 нче елларда гына башланды. Шанхай ул заманнарда инглизләр тарафыннан идарә ителгән концессия иде. Шанхайга ул заманнарны урысларга һәм (алар арасында башка милләт кешеләренә дә) революциядән качкан кешеләргә шәһәргә килеп яшәргә рөхсәт бирелер иде.

1920 нче елларда берничә татар ак гаскәриләрдән башка кеше ияләшмәгән иде. Гаилә рәвешендә Харбиннан килү 1928 елларда башланды. Шанхайда, заманында, иң күп дигәндә 100-дән артык татар яшәмәде.

Шанхайда татарларның җәмгыять корылышы 1932 елларда Харбиннан килгән Кәшшаф Сәлихмәт (Әхмәди) белән башлана. Ул Харбин татар җәмгыятен куәтле бер нигезгә салган Инаят (Гыйниятулла – *Ә.К.*) Сәлихмәтнең яшь туганы (энесе – *Ә.К.*) Кәшшаф үзе дә Харбинда елларча (күп еллар – *Ә.К.*) яшьләр түгәрәгендә фаал (актив) роль уйнаган иде. Хатыны Мәдинә исә Харбинда мөгаллимәлек эшләгән.

Җәмгыять рәсми рәвештә 1934 елның 5 сентябрендә корылды һәм рәис буларак, Кәшшаф Сәлихмәт сайланды. М.Әүхәди Җамалетдин* – ви-

* Бу исем китапта «Йамалетдин» дип басылган.

це-рәис һәм мулла; Мәдинә Сәлихмәт, Латыйфа* һәм Кадыйр Абдурахман, Һ.Ильяс, Шаһвәли Келәүле, Мансур Арслан һәм Айниҗамал Ильяс.

1935 елны Мукденда йулышкан Гаяз Исхакый тарафыннан корылган корылтайдан соң, Шанхайга кайткан 2 делегаттан алынган хәбәрләрдән соң, 1935–1941 еллар – иң эшлекле дәвер дип әйтергә мөмкин булыр.

1941 елда, Япониянең сугышка керүе белән, оешуларга рөхсәт бирелмәде һәм буның өчен җыелышлар аз булды. Җәмгыять 14 ел дәвам итеп, 1948 елны, татарларның күбесенең Төркиягә китүе белән ябылды.

1935 елда татарларның Идел-Урал җәмгыяте Украина, Гөрҗи һәм Кавкас җәмгыятьләре белән элемтә корып, бу милләтләрнең азатлык юлында берлек хәлендә хәрәкәт итү өчен Кавкасия, Идел-Урал һәм Украина халкының бергә эшләү комитеты корыла һәм безнең җәмгыятьтән Мәдинә Сәлихмәт бу комитет тарафында вице-президент буларак сайлана.

Ул заманнарны җәмгыять Догу (Көнчыгыш – *Р.М.*) төркестанлылар белән дә якын элемтә коралар һәм сәяси эшләрдә бер-берләренә ярдәм итәләр.

1940–1942 елны Төркиянең Шанхайда ул заман булынган сәфарәте (илчелеге – *Р.М.*) белән дә элемтә корыла.

Балаларга үзебезнең гадәтләрне, тарихны, телне һәм динебезне саклау өчен шимбәләре (шимбә көннәрне – *Ә.К.*) дәрес бирелә. Милли һәм дини бәйрәмнәрдә җыелышулар эшләнә һәм татар пьесалары сәхнәгә куела. Ул ук заман татарларны чит илләрдә таныштырыр өчен урыс эмигрант газеталарында һәм инглиз телендә чыга торган газета һәм мәҗмугаләрдә (журналларда – *Ә.К.*) татар олылары, культура һәм милли теләкләре хакында язулар (мәкаләләр – *Ә.К.*) чыгарыла. Урысларга җавап язылганда һәм алар тарафында басылмаганда памфлетлар белән таратыла иде.

Идарәбез матди яктан фәкыйрь булганга, 1941 елга кадәр бүлмә дә арендага алалмый идек һәм кичәләр күбесе Ләх (поляк) вә йә украиналыларның салоннарында эшләнә иде, милли рух бик бай иде.

Бәйрәмнәр кытайларның кечкенә мәсҗедендә уздырыла иде. (Сүз Кытай мөселманнары мәсҗеде турында – *Ә.К.*) Аларның да йетерлек җирләре булмаса да, алар безгә бер бүлмә бирә иделәр.

Җәмгыятьнең соңгы елларында, 1942-ләрдән соң мадәт вәзгыяте (матди хәл – *Р.М.*), аз гына булса да, яхшыланды һәм бер бүлмә дә арендага ала белдек.

Сугыштан соң ак урыслар (акгвардиячеләр – *Ә.К.*) СССРга кайтканда татарлар Кытай һәм Американ властьлары тарафыннан танылалар, аларга Кытайдан китүебездә ярдәмләре булына.

---

* Бу исем китапта ялгыш «Зарифа» дип басылган.

Соңгы бу информация – Шанхайдагы җәмгыять, Харбин, Япония һәм Кореядагы җәмгыятьләр кебек, һичбер кабиләчелек белән саташмады. Татар вә йә башкорт булганмы – һичкем дә аерып карамады һәм дикъкать итмәде. Һәммәбез төрки Идел-Уралдан килгән халык дип үзебезне таный идек.

Равил Салиәхмәт.

*Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – Б. 74–76.*

## ШАНХАЙДА БАЛАЛАР КИЧӘСЕ

Гайде фитыр бәйрәменең икенче көнендә, 28 нче декабрьдә, Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте һәм Ата-аналар һәйәте балалар өчен махсус кичә ясадылар вә шул кичәгә Шанхайда яшәүче бөтен милләттәшләрне кунакка чакырдылар. Әүвәлге бәйрәм мөнәсәбәте белән ясалган «Балалар кичәсе» кичәнең актыгына таба, зурларның иштиракь итүләре белән, тәмам башка төс алып китә торган иде. Ләкин быел, бөтен програм балалар тарафыннан гына үтәлгәнгә, кичә бөтен мәгънәсе белән балаларныкы булды.

Кичә бер пәрдәлек «Саран күрше» исемендәге көлке белән башланды. Пьесада иштиракь итүче Нияз Габдрахман, Рәшидә Ильяс, Тасия Габдрахман, Равил Әхмәдиләр, бик җанлы рәвештә үзләренең рольләрен суфлёрның ярдәменнән башка, килештереп уйнап бирделәр. Әдәбият бүлеме «Чынгыз бабам»ны күмәкләп җырлау белән башланды вә әдәбият бүлеменең дәвамында осталык белән Сания Гыйффәтнең «Дибез» һәм «Төрк сүзе», Исхак Арсланның «Киләчәк, булачак» шигырьләре укылды, «Борынгы заман» җырланды. Шулай ук аерым рух вә осталык белән «Салават батыр» көе махсус язылган сүзләр белән үтәлде. (Халык бәетләренә караганда, шул көй белән Салават батырның гаскәре русларга һөҗүм иткәндә махсус 150 җырчы җырлап барганнар, имеш). Халык бу көйне бик яратып, балаларны тәкрәр җырлауларын үтенеп, кичәнең дәвамында берничә мәртәбә «Салават батыр» көе җырланды.

Кичә өчен хәзерләнгән махсус програм беткәннән соң, милли уеннар, биюләр башланып, кичәгә килгән халык, балалар белән бергәләп, чын шатлык, көлке арасында уздырдылар. Шанхайда яшәүче төрк-татар балалары әҗнәби мәктәпләрнең ят програмнарын беренчелек белән алып барулары өстенә, үзләренең ял итү көннәрендә, үзебезнең милли, дини тәрбиябезне дә күңелләренә чын мәгънәсендә урынлаштыра алулары шул кечкенә генә кичәдә ачык күренде. Үз милли көйләребезне, үз шагыйрь-



Шанхай төрк-татар Мәдәният җәмгыяте тарафыннан Ураза бәйрәме хөрмәтенә уздырылган Балалар кичәсен оештыручылар һәм анда катнашучылар. Алда уңнан беренче – Үзбәк Дүзи. Артта (*сулдан-уңга*): Равил Әхмәди (Салиәхмәт), Нияз Габдрахман, Мәдинә Салиәхмәт, Рәшидә Ильяс, Шаһвәли Келәүле, Зәйтүнә Дүзи, Тасия Габдрахман, Гайниҗамал Ильяс, Рифгать Хаҗи. 1935 ел, 28 декабрь.
*(Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2007. – №2. – Б. 185).*

ләребезнең сүзләрен килештереп әйтеп бирүләре, ата-аналарның кәефләрен никадәр китерсә, үз илен күрергә, үз тормышы белән яшәргә зар булган, кичәгә җыелган халыкның күзләренә яшьләр китерде.

Г[айниҗамал] Ильяс.

*«Милли байрак» газетасы (Мукден). – 1936. – 15 гыйнвар.*

## РУС ТЕЛЕНДӘГЕ ГАЗЕТАДА ЧЫККАН МӘКАЛӘГӘ ҖАВАП. 1936 ЕЛ, АПРЕЛЬ.

# НАШ ОТВЕТ.

Статья М. Колосовой о книге Аяз Исхаки «Идель-Урал», напечатанная в газете «Новый Путь» № 150 никогда не появилась бы в печати среди культурных наций, умеющих даже в чувстве ненависти к своему политическому противнику не переходить дозволенных границ и тем не ронять достоинство своей нации.

Что ж мы видим в статье М. Колосовой? Ведь-это сплошная ругань, битье, ломанье, т. е. выявление самых грубых, самых низких инстинктов человеческой натуры. Кликушество переходит в старушечьи причитания, а за ними следуют сочные слова проклятий, бабушкины пословицы пущены в ход как оружие защиты.

И таким способом реагирует молодое русское поколение в лице М. Колосовой на выступления своих политических противников, и «вот каким языком заговорило молодое русское поколение».

Что еще характерно-эту статью пишет женщина, русская женщина, некогда воспетая Пушкиным и возведенная на пьедестал Тургеневым. А теперь? А теперь одна из них в лице поэтессы М. Колосовой добровольно взяв на себя позорную роль палача в садистическом удовольствии готовит заблаговременно виселицы народным вождям и борцам за свободу своей нации.

Неужели женщины в кожаных тужурках с маузером в руках хладнокровно расстреливающие «контр революционеров» не чудовишные исключения, не выродки?

Оставим им полное право размножаться как угодно и сколько угодно, а перейдем к сути дела.

Ни, «заговорившее точным, сухим и жестким языком своих предков, молодое русское поколение» и не женшины-палачи, вдохновительницы этого поколения ни капельки не страшны как Аяз Исхаки, так идущим за ним тюрко-татарам, идель-ураловцам. За Аяз Исхаки идут ни кучка какая-то и не выродки, а все сознательные, все те, кому дорога своя нация и в жилах которых течет кровь бесстрашных предков. Если во имя чужих интересов они храбро сражались и проливали свою кровь, то уверенные в свое право сумеют добиться его и с радостью отдадут свою жизнь во имя осуществления своей национальной идеи.

Напрасно М. Колесова всячески ухищряется запутать, исказить факты из истории тюрко-татар. Нам не важно, что подумают о нас не знающие ни своей, ни чужой истории и несмыслящие о ходе исторических событий профаны. Нам важно то, что знаем мы сами, во что уверены. Нам известно, что тюркские народы на много раньше вступили в историю-чем, скажем, славяне, и что культура их на много древнее той же славянской, одним из мест развития этой культуры были территории Идель-Урала и в течении 1000 летий эти земли были нашими и если в период слабости были захвачены чужими, то могут быть и возвращены.

Как известно тюркские народы обладают одним из высших качеств общественности, именно, создавать могучие государства опираясь лишь на свою силу. Их история не знает позорных страниц, подобных: «Земля наша велика и обильна, а порядка в ней нет, идите владейти и княжьте над нами».

Если принять во внимание тот факт, что 99% тюркских народностей не смотря на пройденные тысячелетия, сохранили чистоту своей крови и в жилах их не течет чужая, разлагающая их кровь и в годы гнета сумели сохранить особенности быта, нрава, свой язык, так такой народ более чем кто либо имеет право на самостоятельное существование.

Ни у кого они и не испрашивают на это разрешения, сами добиваются его в конечном итоге и добьются.

Вот какие мысли теперь в голове у тюрко-татарина, спасшего жизнь другу М. Колосовой, вот в каком духе воспитывает своих детей татарка, бывшая подруга М. Колосовой, ставшая теперь матерью.

А те выродки, к счастью в ничтожном количестве, «русские-татары» или «татары-русские», к которым М. Колосрва обращается с большой буквой нам не нужны, берите их и разлагайте свою и без того разложившуюся кровь.

Мрачные, тяжелые страницы нашей истории, годы гнета, последовашие после больших ошибок допущенных прадедами дали хороший урок детям: они возродили нацию и об'единили всех тюркских народов (идель-урадьцев, крымцев, туркестанцев, кавказских нар). околэ одной общей тюркской идеи.

Давность не страшна нации, владевшей 1/3 мира, за ней история сохранила все права и настало время сказать-ИСТОРИЯ ПОВТОРЯЕТСЯ!

**Комитет Идель-Урала Тюрко-Татар**

**гор. Шанхая.**

## ГАЯЗ ӘФӘНДЕНЕ АУРУПАГА ОЗАТУ

7 нче март Шанхай портында Аурупага китә торган француз вапуры янында ашыгычлык берлә соңгы хәзерлекләр бара. Төрле милләт халкы, төрле телдәге сүз кисәкләре. Ләкин күпчелек хәрәкәт җир хуҗалары кытайлар ягында. Алар кырмыска кеби кайный, ашыга, йөгерә, кычкырып сөйли, шунда сәүдәсен дә итә, хәерен дә сорый, төрле уеннар да күрсәтә. Әлхасыйль, мөмкин кадәр күбрәк акча җыеп калырга тырыша.

Вапур кузгалу берлә тирә-як фейерверк тавышы берлә тула. Кытай халкы үзенең ниндидер зур кешесен озата һәм аның юлындагы кара көчләрне шул тавыш берлә куа, куркыта.

Шанхайда яшәүче Идел-Урал төрк-татарлары да шул вапур берлә үзләренең юлбашчылары Гаяз әфәнде Исхакыйны озаттылар. Кытайларча фейерверк та атылмады, Аурупа халыкларыча артык хиссияткә бирелеп, шау-шу да күтәрелмәде. Ләкин китүчегә булган зур ихтирам һәр озатучының йөзеннән, хәрәкәтләреннән күренеп торды. Күңелләр киләчәк күрешү туган илдә насыйп булсын иде дигән теләкләрне теләде. Ерак Шәрыктә яшәүче төрк-татар арасында ике ел ярым буе үзен-үзе онытып эшләгән эшләре, сарыф иткән көчнең нәтиҗәләре күз алдына килеп басты да, «шәхесләр тарихта роль уйнамыйлар» дигән фикернең киресенә тагын бер куәтле дәлил арттырдылар. Ике ел ярым эчендә халкыбыз арасындагы зур үзгәрешләр, халкыбыз үзенең кемлеген эзләп, табигый үсү юлына кереп, әхвале рухиясенең яңаруы һәм, барсыннан да бигрәк, милли гаййәнең нык урнашуы – шулар бар да озату вакытындагы күңелсезлекләрне югалттырып, күңелне шатлык берлә тутырдылар. Башны югары күтәрттереп, иркен сулыш берлә, киләчәк – халкыбызның кулында дигән фикерне ышаныч берлә әйттерделәр. Шундый иман берлә Ерак Шәрыктәге төрк-татарлар үзләренең юлбашчыларын озаттылар.

Ләкин башкачарак әхваль астында алар аны каршы алганнар иде. 1933 елның көзе иде. Гомумән, Ерак Шәрык төрк-татарлары үзләренең көзге, болытлы-яңгырлы көннәрен уздыралар иде. Көзен яфракларын койган агач төсле, халык үзенең күп сыйфатларын югалтып, иң кадерле саналган милли идеал да:

> Төшәр-төшмәс торадыр соңга калган бер генә яфрак,
> Төшәм дип калтырый җил сызгырып киткән саен чак-чак...

хәлендә иде.

1905 елда көчәеп киткән милли хәрәкәт гәүдәләнеп беткән вакытта гына октябрь инкыйлабы тарафлы тар-мар кылынды. Мөһаҗәрәт тормышында бу хәрәкәт инерция буенча бераз вакыт дәвам итеп килсә дә, авыр тормыш халкыбызны шәхси мәнфәгатьне бар нәрсәдән күбрәк алга тоту

юлы буенча алып китте. Милли гаййә бөтенләйгә ташланмаса да, читкәрәк тибәрелде. Табигый, ул тибәрелү берлә халкыбызны башка тәэсирләр чорнап алдылар. Шул тәэсирләрнең берсе – гасырлар буенча безне изеп килгән рус тәэсире иде. Бишенче елдан башланган милли хәрәкәт, милли кортылу фикерләре халкыбызның бар катлауларына таралып урнашып өлгерә алмаганга, бу алда йөрүче сыйныфыбызның фикере булып, гавам исә үзен чын төрк-татар итеп белсә дә, руска бик дошман булса да, рустан аерылып мөстәкыйль яшәүне бик теләсә дә, аның өчен хәзерләнеп өлгермәгән вә юлларын билгеләмәгән иде. Әлбәттә, бу бар да гасырлар буе рус кул астында яшәүнең эзе, рус истибдадының милли барлыгыбызны югалттыру, тарихыбызны оныттыру сәясәтенең җимешләре иде. Шул сәбәпләрдән мөһаҗир халкыбызның байтагы ерак шимальдә үз сынын үзе тоталмый, үрмәләп үсә торган каен агачы хәленә килгән иде. Урта халык эчендә кайбер рус тәрбиясен генә күргәннәребез, халык телендә башка үләннәргә үрмәләп, алсу чәчкәле, «эт эчәге» исемендә йөртелә торган чүп үләненә әйләнә башлаганнар иде. Рус гәүдәсе, рус идеоложисыннан башканы күрә алмыйлар иде.

Мөһаҗәрәт дулкыны алдагы сыйныф халкыбызны алып чыккан кеби, сынын тота алмый торган каеннарны, руска үрмәләгән эт эчәкләрен дә алып чыкты. Алдагы сыйныфыбыз бездә күп булмаганга, мөһаҗәрәткә чыгу берлә, төрлесе төрле якка таралды, сибелде. Сибелсә дә милли гаййәне югары тотып килделәр һәм хәзер дә тотып киләләр. Шулар арасыннан милли көрәшчеләр, юлбашчылар чыкты. «Эт эчәкләре» исә хәзергә көнгәчә рус тирәсендә паразит булып яшиләр. Милли хисе булган, ләкин көче-куәте булмаган, арка үзәкләре ныгып өлгермәгән халкыбыз авыр хәлдә уртада калды.

Мөһаҗирләрнең күбесе Ерак Шәрыктә булганга, шул югарыда күрсәтелгән сәбәпкә бинаән, Ерак Шәрык иң авыру урыныбызга әйләнде. Берничә руска сатылган хаиннәрнең дә бу йирдә үк булулары халкыбызның фаҗигасен бигрәк тә арттырды. Бу рәвештә тагын берничә ел яшәлсә, мәгънән үлү алдында идек. Бәхетебезгә каршы, Ерак Шәрыккә Гаяз әфәнде Исхакый килеп чыкты. Япониягә йитүе берлә, халкыбыз арасында милли иманны көчәйтү-ныгыту, истикъляль фикеренә йитештерү эшенә тотынды. Черек нигезгә төзелгән һәйәтләр йимерелеп, яңы, сәламәт әсастә төрле һәйәтләр төзелде. Шуның берлә бәрабәр, төрле конферанслар биреп, матбугатка чыгып, япон әфкяре гомумиясенә үзебезнең кемлегебезне, теләгебезнең хаклыгын белдерде һәм шуның берлә хәерхаһлык тугдырды. Халкыбыз исә мәгънән бик тиз үсә башлады. Истикъляль фикерен бик яхшы аңлады. Төрк-татар халкының шундый алмашынуы русларга охшамады. Алар сатлык хаиннәр аша һөҗүмнәрен башладылар. Ләкин бу ха-

иннәр үз яннарына аңсыз халкыбызны җыеп, милли эшләребезгә каршы мөмкин булган бөтен пычракларны эшләделәр. Ләкин бу хәрәкәтләр халкыбызны оештырды, милли иманын көчәйтте. Япониядә беренче корылтай уздырылды. Япониядән Манжу-Ти-Гога килеп шул ук эшләр эшләнде. Халкыбыз хәзерләнде. Әфкяре гомумиягә кемлегебез белдерелде һәм Манжу-Ти-Года Ерак Шәрыктә яшәүче бар төрк-татарларның беренче корылтае да җыелды. Мәркәз төзелеп, төрле йирдәге төрле һәйәтләр бер җепкә тезелде. Ничә еллар буенча милли матбугатка мохтаҗ булып яшәгән халык өчен милли матбугат вөҗүдкә китерелде. Хәзерге көнне «Милли байрак» милләтчеләр тарафыннан гына яратылып укылмый, милләтче исемендә йөрмәгән төркем тарафыннан да бик тәмләп укыла. Милли истикълялебез, башка мәхкүм булган милләтләрнең истикъляле берлә баглы булганга, иң мөһим адымнар бу тугрыда эшләнеп, җәбһәдәшләребез гөрҗи, Украина, Кафкасия, Төркестан һәм башкалар берлә җанлы бәйләнеш башланды.

Бу эшләр Гаяз әфәнденең күп чәчләрен агартып, сәламәтлеген дә алып киттеләр. Ләкин корбансыз эш булмый, шуларның нәтиҗәсендә халкыбыз үсте, ныгыды. Арадагы төрле чүп-чарлар уталды, чуар фикерләрнең урынына бер төркчелек иманы, истикъляльчелек омтылышы калды һәм шул юлдан башка юл юк дип эшләүче актив вөҗүдкә килде. Гаяз әфәнде китү берлә дә бөтен мәсьүлиятне күтәргән шул актив һәм аның эшләре дәвам итәчәк.

Мәдинә Салиәхмәт.

Шанхай, 12 март.

*Яңа милли юл. – 1936. – №5. – Б. 21–23.*

## ЙОСЫФ БӘК АКЧУРА ИСТӘЛЕГЕ

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте 11 нче мартта бөек остазыбыз Йосыф бәк Акчураның үлүенә бер ел тулу мөнәсәбәте илә искә төшерү мәҗлесе ясады.

Халык җыелу белә, сәгать 9-да, Шаһвәли әфәнде Келәүле тарафыннан Коръән укылып, мәрхүм Йосыф бәк Акчураның рухына багышланды. Бөек остазыбызның тәрҗемәи хәлен Латыйфа ханым Габдрахман сөйләде. Гайниҗамал ханым Ильяс бөек галимебезнең төрк берлеге наменә эшләп килгән эшләрен күз алдына китереп, бөтен дөнья төркләренең истикъляльләре өчен армый-талмый эшләве хакында ачык мәгълүмат бирде. Мәдәният җәмгыятенең курсларында укучы шәкертләр тарафыннан бу көнгә махсус шигырьләр укылып, бөек остазыбызның милләте өчен

эшләгән эшләре, аның бөтен тормышы кичәдә булган халыкның күз алдына китерелеп бастырылды.

Мәҗлес сәгать 12-дә генә таралды.

Кадыйр.

*Милли байрак. – 1936. – 1 май.*

## ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте тарафыннан 17 нче апрельдә шагыйребез Габдулла Тукайга багышланып эшләнгән кичә, узган елдагыча ук, бик муаффәкыятьле рәвештә уздырылды. Кардәшләребез төркестанлыларның һәм җәбһәдәшләребез: гөрҗи һәм Украина мөмасиләләренең мәҗлескә бөек шагыйребезне олуглап килүләре аерым бер күтәренке рух кертеп, кичәнең уңышлы узуына сәбәпче булдылар.

Мәҗлесне җәмгыятьнең рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди бүген яд итә торган Тукай, милли барлыгыбызны арттыру юлында күп хезмәтләр куйган Курсави, Каюм Насыйри, Шиһаб хәзрәт Мәрҗани, Исмәгыйль бәк Гаспралы, Гаяз әфәнде Исхакыйлар белән бер максат, бер идеал өчен янучы затларның берсе булуы һәм шул затлар тугрында көчебез, аңыбыз җиткән кадәр халкыбызга мәгълүмат бирү вазыйфалары – мәдәният җәмгыятьләренең эше икәнлеге тугрында сүзләр белән мәҗлесне ачты.

Соңра, мәктәп шәкертләре тарафыннан Коръән укылгач, Мәдинә ханым Әхмәди «Габдулла Тукай – борынгы ил шагыйрьләренең варисы» мәүзугында мәгъруза эшләде. Халык әдәбияты, чыгытай, госманлы әдәбиятлары, аларның Тукайга тәэсире, халык әдәбияты аркылы үзен-үзе табуы хакында мәгълүмат бирде. Мәгърузадан соң зурлар һәм балалардан мөрәккәб күмәк «Өзелгән өмид»не җырладылар.

Шуның белән мәҗлеснең матәм мәрасиме бетеп, балалар кыйсеме башланды. Кичәдә иштиракь иткән балалар: Рифгать Хаҗи, Равил Әхмәди, Камал Мостафа, Рәшидә Ильяс, Тасия Габдрахман, Зәйтүнә Дүзи, Искәндәр Дүзи, Нияз Габдрахманнар һәркаюсы сөекле шагыйребезнең шигырьләрен бик килешле итеп әйттеләр, күмәкләп җырладылар. Шулай ук бик осталык белән Тукайның «Таз» һәм «Су анасы»н уйнадылар.

Әдәбият бүлеме беткәч, ханымнарыбызның тырышлыгы һәм уңганлыклары аркасында, бәйрәм көннәрендәге кебек күркәм хәзерләнгән өстәл янына кунаклар дәгъвәт ителделәр. Җәбһәдәшләребезнең сораулары буенча Габдулла Тукай тугрында аларга аерым мәгълүмат бирелде һәм алар да үз нәүбәтләрендә: «Сез, төрк милләте, шундый Габдулла Тукай кебек шагыйрьгә малик булуыңыз белән бәхетле милләтләрнең берсе. Сез

бетәчәк түгел! Киресенчә, Тукайлардан көч алып, куәтле, мөстәкыйль милләткә әйләнәчәксез һәм сезнең шундый мәҗлесләреңездә булуыбызга бик шатбыз» мәфһүмендә сүзләр сөйләделәр.

Шанхай имамы Әүхәди әфәнде динебезне, милләтебезне саклап килгән бөек затларыбыз хакында һәм хәзер дә динебезне һәм милләтебезне берлек аркасында гына саклый алганыбыз хакында сүзләр сөйләде.

Сүзләр дәвамында Гайниҗамал ханым, Мәрьям ханым, Латыйфа ханым, Фатыйма ханымнар милли көйләребезне җырладылар. Рәшидә, Тасия туташлар милли биюләребезне биеп, кичәгә матурлык бирделәр. Гомумән, кичә бик рухлы узып, килгән халык та бик мәмнүн калдылар.

Хәбәрче.

*Милли байрак. – 1936. – 8 май.*

## ИДАРӘГӘ МӘКТҮБ

Хөрмәтле мөхәррир әфәнде!

Ошбу хатка «Милли байрак»та урын бирүегезне үтенәбез вә урын бирүеңез өчен алдан ук рәхмәтләребезне укыйбыз.

«Милли байрак»ның 25 нче санында Хөсәен әфәнде Габдүшнең бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 50 ел тулу юбилеен быелның 12 нче июнендә, ана телебездә язылган беренче романның дөньяга чыгуына 50 ел тулу көненә туры китереп эшләү фикерен бик мәгъкуль табабыз вә, милли хәятебездә бу ике зур вакыйгага аерым әһәмият бирү йөзеннән, үзебез тарафыннан ошбу тәкъдимне кертер идек:

Һәр җирдәге милли оешмалар бөек истәлек көненең хатирәсе уларак, Шәрыктәге милли хәятебездә ифрат зур ихтыяҗы сизелгән «Милли матбага» вөҗүдкә китерү максатын алга куеп, 12 нче июнь көнен Ерак Шәрык Мәркәзенең «Матбага тудыру көне» итеп тәгаенләргә һәм шул көннең матди яктан уңышлы рәвештә узуы өчен һәр милли оешма, һәр милләтче бар көчен сарыф итеп кулыннан килгән ярдәмен бирергә тиеш.

Шанхай Мәдәният җәмгыятенең башкармасы.

*Милли байрак. – 1936. – 22 май.*

## ЕРАК ШӘРЫКТӘ МАТӘМ КӨНЕ

Шанхайда

Идел-Урал төрк-татарының милли вөҗданына рус аягы басылган, шөһрәтле Казан ханлыгының җәгърафия харитасыннан төшкән гүзәл

пайтәхете Казан шәһәре Мәдһиш Иван тарафыннан җимерелеп, йөз меңнәрчә бабаларыбыз шәһид булган вә кадерле байрагыбыз җиргә төшкән көн – 15 нче октябрь – милли матәм көне Шанхай төрк-татарларының Мәдәният җәмгыяте тарафыннан аерым рәвештә сызып узылды.

Бу көн мөнәсәбәте белән кич сәгать 8-дә украиналылар клубында махсус тупланыш эшләнелде вә шул көнгә багышлап махсус мәгъруза нәшер ителде. Эштән, хезмәттән буш булган Шанхайда яшәүче халкыбыз мәҗлескә җыелганнар иде. Шәһәребезгә үзенең әүвәлдә дәваланган докторыннан дәваланырга килгән Диния шөгъбәсенең әгъзасы Габдрахман хәзрәт Кәрим, җәбһәдәшләребездән украиналы, Аурупа «Прометей» әгъзасы доктор Милко, украиналылар Громадасыннан доктор Квашенко, «Украинская Сечь» оешмасыннан Пирогов, Тутский, гөрҗиләрдән рәисләре – полковник Носадзе, инженер Махарадзе* һәм башкалар да хазир иделәр.

Мәрасим җәмгыять рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди тарафыннан ачылып, мөкаддимә уларак бүгенге көн хакында мәгълүмат бирелде. Габдрахман хәзрәт Кәрим Коръән укып, Казан алынган вакытта шәһид булган бабаларыбызның рух шәрифләренә багышлады. Шанхай төрк-татарларының дини-милли мәктәбендә укытучы Мәдинә ханым Әхмәди, Алтын Урда вә Казан ханлыкларының тарихын сөйләп, Олуг Мөхәммәд хан дәвере, Касыйм ханлыгы тәшкиляте хакында аерым мәгълүмат биргәннән соң, Казан алыну вакыйгасын сөйләде. Мәгъруза аерым дикъкать белә тыңланып, зур тәэсир калдырды. Шанхай төрк-татарлар дини-милли идарәсенең рәисе Әүхәди әфәнде Җамалетдин, мәмләкәтебез беткән булса да, милләтебезнең яшәве, милли хиснең саклануы хакында тәэсирле нотык сөйләде. Дини-милли мәктәбебезнең шәкертләреннән Үзбәк Дүзи, Рифгать Хаҗи, Равил Әхмәди, Нияз Габдрахман, Тасия Габдрахман, Рәшидә Ильяс, Зәйтүнә Дүзиләр тарафыннан матәм көненә багышланган шигырьләр укылды вә ханбикәбез Сөембикә рухына Коръән укылды. Дини-милли Мәркәз Диния шөгъбәсенең әгъзасы Габдрахман хәзрәт Кәрим, Дини-милли идарәнең рәисе соравы буенча хәзрәт аякка калкып, Коръән аятьләре вә хәдисе шәрифләр укып, Аллаһы Тәгалә вә Тәбарәкәнең әмере буенча яшәүне тәүсыя итәрәк, тәэсирле вәгазь сөйләде.

Моннан соң ханымнар тарафыннан милли ашларыбыз белән чәй тәкъдим ителде. Доктор Милко, полковник Носадзе, инженер Махарадзе мәрасимгә багышланган ялкынлы нотыклар сөйләделәр.

Ибраһим әфәнде Мамли ханбикәбез Сөембикәне яд итү йөзеннән мәҗлескә тынлык эчендә калырга тәклиф итә. Тәклиф алкышлар белән кабул

* Газетада: Макарадзе.

ителә. Моннан соң милли хәрәкәттә җәбһә берлегенең әһәмиятенә тукталып нотык сөйли вә мәҗлес рәсем алу белән тәмамлана*.

Шанхай мөхбире.

*Милли байрак. – 1936. – 25 ноябрь.*

## ШАНХАЙДА 40 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЙ

Мәшһүр әдибебез вә бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләренең туган көне һәм әдип уларак кырык ел хезмәт итүенең юбилейсе Шанхай төрк-татарларының Дини-милли идарәсе һәм Мәдәният җәмгыяте идарәсе тарафыннан аерым тантаналы рәвештә үткәрелде. Бу хосуста, Шанхайда чыга торган әҗнәби гәзитәләрендә хәбәр ителүдән башка, Шанхайда яшәүче илдәшләргә дә аерым дәгъвәтнамәләр таратылган иде.



«Зыяфәттән соң. Шанхайда». *(Милли байрак. – 1937 ел, 23 апрель).*

* Бу мәкалә янында күмәк төшелгән фоторәсем басылган һәм аның астына «Матәм мәрасимендә алдырган рәсем» дип язылган.

Мәҗлес 24 нче февральдә украинлылар клубында ясалды. Клуб бу көннең хөрмәтенә матур итеп җыелган вә хөрмәтле әдипнең рәсеме махсус урынга эленгән иде. Мәҗлескә килгән илдәшләребез арасында җәбһәдәшләребездән украиналы доктор Квашенко, Тутский, гөрҗиләрдән меңбашы Носадзе, казаклардан Пирогов һәм башкалар да килгәннәр иде.

Мәҗлес Мәдәният җәмгыяте рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди тарафыннан кичке сәгать 8-дә ачылды. Мәхәллә имамы Әүхәди әфәнде Җамалетдин Коръән укып, бөек юлбашчыбызга сәламәтлек теләп дога кылды һәм бу көнгә багышлап сүз сөйләде. Мәдинә ханым Әхмәди Гаяз әфәнденең тәрҗемәи хәле белән таныштырып, аның әдәби хезмәтләре хакында озын мәгъруза укыды. Кәшшаф әфәнде Әхмәди «Гаяз әфәнде Исхакый – бөек юлбашчыбыз һәм сәяси эшчебез» башлыклы мәгъруза укыды. Шаһвәли әфәнде Келәүле Гаяз әфәнденең кырык еллык юбилей көненә багышланма «Миллион чәчәкләр» исемле шигырен укып чыкты.

Гаяз әфәндегә «Милли байрак» гәзитәсе аркылы тәбрик телеграмы бирелде.

Тәнәфесдән соң Мәдинә ханым Әхмәди «Гаяз Исхакый – әдип вә юлбашчыбыз» мәүзугында рус телендә мәгъруза эшләде, җәбһәдәшләребездән доктор Квашенко, меңбашы Носадзе, Тутский тәбрик нотыклары сөйләделәр. Кунаклар ханымнар тарафыннан хәзерләнгән чәй өстәленә дәгъвәт ителделәр.

Мәҗлестә булучылар рәсемгә алыну белән мәҗлес сәгать бердә тәмам булды*.

Мөхбир.

*Милли байрак. – 1937. – 23 апрель.*

## ШАНХАЙДА МИЛЛИ КИЧӘ

25 нче февральдә Шанхай төрк-татарларының Мәдәният җәмгыяте тарафыннан украиннар клубында мәктәп файдасына милли кичә эшләнде.

Сәхнәгә «Отрезчик»** – комедия, бер пәрдәдә, Шаһвәли Келәүле әсәре куелды. Уенда иштиракь итүчеләр: Гөлчәһрә ханым Хаҗи, Мөнәвәрә ханым Нәсифулла, Шаһвәли әфәнде Келәүле, Фәрит әфәнде Агыш үзләре-

* Бу мәкалә янында тантанада катнашучыларның күмәк төшкән фоторәсеме басылган һәм аның астына «Зыяфәттән соң (Шанхайда)» дип язылган.

** Тукыма белән сату итүче асламчы һәм кечкенә кибеттә тукыма белән сату итүченең ярдәмчесен «отрезчик» дип йөрткәннәр.

нең рольләрен бик яхшы уздырдылар. Шаһвәли әфәнде Келәүле аерым алкышланды.

Икенче бүлемдә күмәкләп милли җырлар җырланды. «Авыл яшьләре» исемендә күренеш куелды. «Шанхайда безнекеләр» «Җизнәкәй» көенә Шаһвәли әфәнде Келәүле вә Әхкяметдин әфәнде Зыяэтдин тарафыннан җырланды.

Сәхнә беткәч, ханымнар тарафыннан чәй хәзерләнеп, барча халык чәйгә дәгъвәт ителде. Чәйдән соң биюләр, җырлар, милли уеннар белән кич сәгать 3-кә кадәр дәвам итте.

*Милли байрак. – 1937. – 23 апрель.*

## ШАНХАЙДА ИСТӘЛЕК КӨННӘРЕ

Идел-Урал төрк-татарларының соңгы мөфтисе вә дин галиме Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең ел билгесе һәм бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 24 ел тулу көнен искә алу мөнәсәбәте белән Шанхай төрк-татарларының Мәдәният җәмгыяте 15 апрельдә украиннар клубында махсус утырыш ясады.

Мәҗлес сәгать 8-дә җәмгыять рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди тарафыннан ачылды. Шанхайда яшәүче илдәшләрнең хезмәттән буш булганнары хазир иде. Нанкиннән Галимә туташ Әхмәди вә төркестанлы кардәшләребездән доктор Мәсгудь бәк килгәннәр иде. Шулай ук җәбһәдәшләребездән Украина җәмгыятенең рәисе доктор Квашенко вә башкалар хазир иделәр. Мәхәллә имамы Әүхәди әфәнде Җамалетдин Коръән укып, савабын мәрхүмнәрнең рухларына багышлап дога кылгач, бүгенгә каратып нотык сөйләде. Моннан соң Мәдинә ханым Әхмәди Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләренең дин галиме, тарихчы вә мөхәррир уларак эшләгән эшләре хакында мәгъруза эшләде.

Ун минут тәнәфестән соң, Шанхай төрк-татар дини-милли мәктәбендә укучы шәкертләр шагыйребез Габдулла Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар. Мәдинә ханым Әхмәди, Тукай шигырьләренең балалар кыйсемен алып, «Бала тәрбиясе» мәүзугында мәгъруза укыды. Рәхмәтулла әфәнде Фәтхулла «Габдулла Тукай – халык шагыйре» мәүзугында мәгъруза эшләде. Балаларга бүләкләр бирелде, ханымнар тарафыннан чәй өстәле хәзерләнеп, килгән халык чәйгә дәгъвәт ителде. Чәй арасында доктор Квашенко һәм Онученко милли мәдәният вә аның милли хәрәкәткә тәэсире хакында сүз сөйләделәр.

Кәшшаф әфәнде Әхмәди, бу мәҗлесне оештыруда ярдәм иткән ханым вә әфәнделәргә, мәгъruзачыларга вә барча мәҗлестә булган кардәшләребезгә рәхмәт укып, мәҗлесне япты.

Мөхбир.

*Милли байрак. – 1937. – 30 апрель.*

## ШАНХАЙ ТӨРК-ТАТАРЛАРЫ ОЕШМАСЫНДА ТУКАЙ МОҢЫ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 25 еллык билгесе Шанхайда 19 апрельдә Украина клубында уңышлык белән уздырылды. Шагыйрьне хөрмәтләү йөзеннән җыелган үз халкыбыздан тыш, Шанхайдагы Украина, гөрҗи милли идарәләренең, Хатыннар, Яшьләр оешмаларының рәисе вә кятибләре һәм башка әгъзалары хазир булып, ләһлеләрнең дә байтак мөмасилләре быел мәҗлесебезгә килгән иделәр. Һәр елны милли тантана тупланышларыбызга махсус вәкилләр җибәреп катнашып килгән, Нанкиндә яшәүче Шәркый Төркестанлы кардәшләребез генә быел мәҗлесебезгә катнаша алмадылар.



«Тукай истәлеге кичәсеннән бер күренеш».
*(Милли байрак. – 1938 ел, 17 июнь).*

Мәҗлесне Идел-Урал җәмгыятенең рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәди көннең әһәмияте хакындагы сүзләр белән ачкач, имам Әүхәди Җамалетдин тарафыннан Коръән укылып, мәрхүмнең рухына багышлана һәм чит илләрдә, үзебезне саклау юлында, шагыйрьнең иҗаты җан азыгыбыз булып килүе хакында мәгълүмат бирелә. Соңра мәктәп шәкертләре: Рифгать Хаҗи «Нәсыйхәт», Рәшидә Ильяс – шуның русча тәрҗемәсен, Равил Салиәхмәд «Борын», Тасия Габдрахман «Сәрләүхәсез», Нияз Габдрахман «Чын белән ялган», Рәшидә Ильяс «Теләү бетте» шигырьләрен бик гүзәл итеп укып чыгалар һәм каты алкышланалар.

Мәгърузалар кыйсемендә Мәдинә ханым Әхмәдинең «Илебезнең бөек шагыйре» мәүзугындагы сүзе тыңланылгач, Яшьләр оешмасының рәисе Әнвәр әфәнде Сали шагыйрьнең тәрҗемәи хәле һәм иҗаты хакында туплanышка катнашкан җәбһәдәшләребез өчен рус телендә мәгъруза укый. Бу мәгърузалар байтак вакыт алганга, тәнәфес ясалып, кунаклар бәйрәмчә хәзерләнгән өстәл тирәсенә дәгъвәт ителәләр. Соңра «Әдәбиятыбыз һәм шунда Тукайның урыны» мәүзугында Мәдинә ханым тарафыннан рус телендә озын мәгъруза укыла.

Тәбрикләр кыйсемендә Украина Громадасының рәисе доктор Квашенко төрк-татар халкының тәрбияче һәм өндәр шагыйрьгә малик булуы белән тәбрикли, төрк-татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай һәм Украина халкының «пәйгамбәре» кебек саналган шагыйрь Шевченколарның халык эченнән чыгулары, шул халыкка булган гыйшык һәм сагышларында мөштәрәклек барлыгын күрсәтеп уза. Гөрҗиләр оешмасының рәисе Миралай Носадзе бер милләт авырлыкка төшкәндә аны коткаручыларның беренче сафында гаййәле шагыйрьләр торуын төрле халыкларның көрәш тарихларындагы мисаллар белән күрсәткәч, шагыйребезнең «Кайтмады үч...» шигыренә туктап, «Изге үчнең нәрсәдән гыйбарәт булуын без – Шәрык халыклары гына чын мәгънәсе белән аңлый алабыз. Гомер буе халкы өчен янып, халкын чорнап алган кара көч, зольмәтләрнең нәрсәдән икәнлегене иң нечкә төшенгән шагыйрь үз күзе белән милләтнең хөрлеген, сәгадәткә ирешүен күрми, изге үче кайтмый сезнең арадан киткән икән, шуңа ирешү, изге үч кайтаруны үзеннән соң килгән буын – сезнең өстеңезгә тапшырып киткән» дип, ялкынлы нотык сөйли. Соңра ләһләрдән Каменский «Бу көн матәм түгел, бәлки зур барлык көне» дип, төрк-татар милләтен шуның белән куәтле һәм истикъляль көрәшенең тәмәл ташы уларак, халкы өчен янган әдип, шагыйрьләре булса – ул халык, шиксез, теләгенә ирешәчәк дигән мәгънәдә сөйли. Украиналылардан Сабетиков: «Бер милләтне бөеклеккә ирештерүче – милли язучы вә шагыйрьләре булса, икенчедән, шул милләтнең хатыннары була» дип, төрк-татар хатын-кызлары исеменә мактаулар яудыра.

Мәҗлеснең рәсми кыйсеме шуның белән тәмамлана. Сәгатьләр буе дәвам иткән бу мәҗлес, Тукай моңы, Тукай калдырган мәгънәви барлык эчендә узып, Русия әсарәтеннән котылучы төрле милләт мөмасилләре авызында Тукайның шәрәфле исеме бертуктаусыз иҗекләнә һәм шундый шагыйрьгә малик булганлыгыбызга күңелләрне милли горур белән тотыра.

Мөхбир. Шанхай.

*Милли байрак. – 1938. – 3 июнь.*

## МӘҮЛИДЕН-НӘБИ

Шанхайда

Соңгы ике-өч ел эчендә Шанхайда мәүлиден-нәби бәйрәме Чин мөселманнары һәм башка мөселманнарның катнашы белән тантаналы рәвештә уздырыла башлаган иде. Быел исә, Чин мөселманнары бәйрәмне бик кечкенә тарызда уздырдылар. Безнең төрк-татарларда бәйрәм үзенең елдагы тәртибе белән уздырылды.

Бәйрәм мәҗлесе 14 нче майда «Украина клубы»нда сәгать 8-дә башланып, Шанхай мулласы Әүхәди әфәнде тарафыннан Коръән укылып, пәйгамбәребез рухы шәрифенә багышлангач, ислам дине һәм аның өндәре Мөхәммәд саллал-лаһы галәйһис-сәламнең мөбарәк симасы хакында озын һәм тәэсирле сөйләнде. Вә аның тарафыннан ук мәүлүд укылгач, мәктәп шәкертләре күмәкләп салават укыдылар. Моннан соң ханымнар тарафыннан хәзерләнгән бәйрәм өстәленә кунаклар дәгъвәт ителделәр.

Кәшшаф әфәнде Әхмәди, Сөнгатулла әфәнде Дүзиләр тарафыннан тәбрик нотыклары сөйләнде. Әүхәди әфәнде Милли идарә исеменнән, бәйрәм уздыру эшендә зур ярдәмнәре тигән ханымнарга рәхмәтләр укыды.

Мәҗлес дуслык, берлек эчендә, кичке сәгать 12-гә кадәр дәвам итте.

Мөхбир.

*Милли байрак. – 1938. – 17 июнь.*

## ШАНХАЙ МАТБУГАТЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Шанхайда чыга торган урыс гәзитәләре «Слово» һәм «Шанхайская заря»[*]ларның 3 нче май саннарында Мәдинә Салиәхмәд ханымның «Бөек

[*] Бу газетаның исеме журналда «Шанхайское время» дип ялгыш басылган.

төрк шагыйре Габдулла Тукай» башлыклы мәкаләсе һәм Ә.С.-нең «Тукайның тәрҗемәи хәле» башлыклы мәкаләсе басылып чыкты*.

*Яңа милли юл. – 1938. – №7. – Б. 27.*

## МӘДӘНИЯТ ҖӘМГЫЯТЕНЕҢ «БЕРЛЕК» ГАЗЕТАСЫ

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсе 1935 елның 26 сентябрь җыелышында 15 нче октябрьгә – Матәм көненә багышлап газета чыгару турында карар кабул иткән була. Җәмгыятьнең рәисе Кәшшаф Әхмәди 3 нче октябрь утырышында газетаның нинди булырга тиешлеге турында сөйләгән. Шунда ук газетага исем вариантлары һәм шигарьләр тәкъдим ителгән, эчтәлеге уйланылган. Газетаның мөхәррирлек вазыйфасы Мәдинә Салиәхмәткә йөкләнгән. 10 ноябрь җыелышында бу газетага «Берлек» дигән исем расланган.

Кулъязма «Берлек» газетасының бер саны (№4) Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1659 т» шифры белән саклана. Ул, Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең җыелышлары беркетмәләре дәфтәре белән бергә, китапханәнең директоры Разил Вәлиевкә 1993 елда Равил Салиәхмәт тарафыннан бирелгән кыйммәтле истәлек.

Зур форматтагы (39х54 см), 4 битле (ике кәгазьдәге) бу газета юка кәгазьгә карандаш белән язылган. Беренче бите гади карандаш белән, ә 2–4 нче битләре карандаш белән зәңгәр күчергеч кәгазе (копировка) аша язылган. Бөтен текстлар да бер үк кеше кулы белән язылган.

Газетаның исеме 1 нче битенең өске уң як почмагында зур хәрефләр белән язып куелган. Анда «Шанхай Мәдәният җәмгыяте тарафлы аена бер мәртәбә чыгарыла торган «БЕРЛЕК» газетасы. Сан – 4. 15 октябрь, 1935 ел» дип язылган. Димәк, «Берлек» газетасын айга берәр сан чыгару ниятләнгән булган.

---

* М.Салиәхмәтнең «Шанхайская заря» газетасының 1938 ел, 5 май санында чыккан мәкаләсен академик Әбрар Кәримуллин татарчага тәрҗемә итеп бастырган иде (Салиәхмәт М. Төркиләрнең бөек шагыйре Габдулла Тукай: үлүенә 25 ел тулу җәһәтеннән // Татарстан хәбәрләре. – 1993. – 14 апрель).

Икенче мәкаләнең имзасы «Ә.С.» дип «Яңа милли юл» журналында ялгыш басылган. Ул, дөреслектә, «З.С.» имзасы астында чыккан. М.Салиәхмәтнең «З.С.» имзасы белән рус телендә басылган әлеге мәкаләсе турында Ә.Кәримуллин язган иде (Кәримуллин Ә. Язмыш, язмыш... – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – Б. 57).


برلك
گازيتاسی سان ٤
تورکلك
اولا برچه يوق بولماس
توركلك - تورك تەگرسی كبك
مەنگيلكدر.
يوسف آقچورا

«Берлек» газетасы. 1935 ел, №4.

Китапханәгә «Берлек» газетасының шул ук 4 нче номерының икенче нөсхәсе дә бүләк итеп бирелде. Аны Америка Кушма Штатларында яшәүче галимә Гайшә ханым Азадә-Рорлих 2010 елның март аенда тапшырган иде. Бу нөсхә һәм Р.Салиәхмәттән алынганы арасындагы бер-берсен тулыландыра торган кайбер аермаларны искәртеп үтәбез. Газетаның әлеге икенче нөсхәсе калынрак, саргылт кәгазьгә язылган. Беренче бите алда тасвирланган (Р.Салиәхмәттән алынган) нөсхәдән зәңгәр копировка аша төшерелгән. Монысында 2–4 нче битләрдәге текстлар гади карандаш белән язылганнар һәм алар алда әйтелгән нөсхәдәгегә тәңгәл түгел. Ягъни бу ике нөсхәнең 2–4 нче битләрендәге текстлар бер-берсеннән копировка ярдәмендә күчерелмәгән.

Газетаның беренче битенең югары өлешендә мондый юллар язылган: «Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте тарафлы моңа кадәр чыгарылган «Аңлатма» бүгеннән соң «Берлек» исеме белән чыгарылачак. Төп максат – милләттәшләребез арасында Идел-Урал истикъляль фикерен һәм дә, гомумән, төркчелек фикерен таратуда, аз гына булса да, ярдәмдә булу. Шанхай Мәдәният җәмгыяте».

Моннан күренүенчә, Мәдәният җәмгыяте тарафыннан башта «Аңлатма» исемле газета чыгарылган икән. Алары да кульязма булгандыр һәм «Берлек»нең бу (дөреслектә беренче) саны 4 нче номер белән билгеләнүенә караганда, газетаның «Аңлатма» исеме белән өч саны чыгарылган булган. Җәмгыять идарәсенең җыелыш беркетмәләрендә аерым вакыйгалар уңаеннан «Аңлатма»лар чыгару һәм тарату турында сүзләр бар. Беренчесен – Мукден шәһәрендә 1935 елның 4 февралендә Идел-Урал корылтае ачылу уңаеннан «...халкыбызны тәбрикләп «Аңлатма» чыгарырга карар ителә» дип, 22 нче номерлы беркетмәдә язылган. Аннан соң шул корылтайның бюллетенен «Аңлатма» рәвешендә тарату турындагы җыелыш карары 24 нче беркетмәдә язылган. Ислам динен кабул итү көненә һәм Азәрбәйҗанның бәйсезлек көненә багышлап 1935 елда тагын ике «Аңлатма» чыгару күздә тотылган (37 һәм 39 беркетмәләр). Боларның дәвамы кебек чыккан «Берлек» газетасының беренче чыгарылышы 4 нче номер белән билгеләнгән булуына караганда, алда әйтелгән «Аңлатма»ларның өчесе генә чыгарылганлыгы аңлашыла. Ягъни, ниятләнгән дүрт санының арадагы берсе чыкмыйча калган.

«Берлек»нең беренче битендәге калган зур мәйданда эре хәрефләр белән горизонталь һәм ромбсыман шәкелдә төрле шигарьләр язылган. Шигарьләрнең күбесе җәмгыять идарәсенең 3 октябрь җыелышында тәкъдим ителгәнчә. Иң югарыда: «Яшүсмерләр! Бөек төрк юлбашчыларыбызның шигарьләрен тикшерегез!». Уртада: «Төрклек үлмәс, юк булмас! Төрклек – төрк Тәңресе кебек мәңгелектер (Йосыф Акчура)». Өстә, уң як-

та, кыйгач рәвештә: «Телдә, фикердә, эштә – берлек (Исмәгыйль Гаспралы)». Өстә, сул якта, кыйгач рәвештә: «Юлыбыз тугры, теләгебез хак, халкыбыз иманлы, милләтебез көчле (Гаяз Исхакый)». Түбәндә, уң якта, кыйгач рәвештә: «Һәр төркнең ике йорты бар. Беренче – үзенең туган йорты, икенчесе – Төркиядер». Түбәндә, сул якта, кыйгач рәвештә: «Бер милләтнең көче – бер үк теләккә бер үк юл белән бергә баруда».

Газетаның 2–4 битләрендәге текстлар өчәр багана итеп язылганнар. Мәкаләләрнең авторлары күрсәтелмәгән.

Газетаның 2–3 битләренең иң өске тарафында, төп текстка караганда эрерәк хәрефләр белән «Идел-Урал мөселман төрк-татарларның Мәркәз башкармасы һәм Мәркәзгә табигъ булган бөтен һәйәтләр белән бергә 15 нче октябрь – Матәм көнебезнең кайгысын уртаклашабыз (Мәдәният җәмгыяте башкармасы)» дип язылган*. Ул, үз нәүбәтендә, шул битләрдәге зур күләмле баш мәкаләнең исеме рәвешендә тора. Баш мәкалә Матәм көненә багышланган: Хәтер кичәсенең әһәмияте, тарихтагы хаталар һәм сабаклар, югалтулар, дин һәм милләтнең изелүе һ.б. Бу мәкаләнең кайбер өлешләре монда күчерелә. «…Үз илебезне русларга бирдек. …Ул безне кол ясады, изде. Анысы гына йитми, безнең иң мөкатдәс булган динебез, милләтебезне бетерергә, югалтырга тырышты. Шатлык көннәребез бер якта торсын, матәм көннәребезне дә күпсенеп, берәмләп аларны да бездән тартып алып юк итә башлады. Соңгы гасырда бездә фәкать ике-өч дини бәйрәм генә калды.

Шул калган ике-өч бәйрәмне дә без чын мәгънәсе белән уздыра алмыйбыз. Күбебез бәйрәмне ак ашъяулык өстендә тезелгән таудай чәкчәк, бәлешләр, ләвәшләр рәвешендә күз алдына китерә. Димәк, ашказанының рәхәте үзенә шатлык итеп алып, шуны бәйрәмнең чын мәгънәсе дип таный. Шулай ук берничә матәм көннәребезне уздырырга тугры килсә – сөйләүченең сүзе кайчан бетәр икән дип, исни-исни көтеп, күңелебез бик йомшап китсә – ике күздән бер тамчы яшьне агызып, шуларны үтәгәч өстебездән авыр йөк төшкәндәй булып, тиз генә мәҗлесне ташлап китәргә ашыгабыз. Шулаймы без бәйрәмнәребезне, матәм көннәребезне уздырырга тиеш? Шуның өченме алар төзелгән?

Менә 15 октябрь тагын килеп йитте. Узган ел да без аны уздырган идек, тарихын тыңлаган, бераз әсәрләнгән идек. Милли барлыгыбызны тулы көе кайтарып алырга да теләк юк түгел иде. Инде быелгы 15 нче октябрьгә кадәр бер ел эчендә без ниләр эшләдек? Югалтуларны кайтарып

* Газетаның Гайшә Рорлихтан алынган нөсхәсендә бу сүзләр язылмаган һәм икенче битендәге баш мәкалә «15 октябрь 1935 сәнә, Шанхай» исеме астында бирелгән.

алыр өчен реаль көч хәзерли алдыкмы? Үзебезнең эчке, тышкы дошманнарыбызның кем икәнлекләрен яхшы аңладыкмы? Шуларны, шуларны аңлап бергә оештыкмы? Халкыбызның бер кыйсеме һәм күп кыйсеме боларны яхшы аңлады. Ләкин барсы да аңлап бетмәде. Әле халкыбыз һаман яңлыш юл белән баруында дәвам итә. Үзенең йә кызыл, йә ак рус колы булуына һич төшенеп бетә алмый. Шул коллыктан чыгара торган көч – «МИЛЛӘТЧЕЛЕК» икәнлеген яхшы аермый.

Рус интригасын халкыбыз арасында таратучы үзебезнең эчке дошманыбыз булган рус ялчысы Корбангали артыннан, чиркәнмичә, аз булса да, баручыларыбыз бетми. Милләттәшләр, менә шул хаталарыбызны аңлап, безгә күптән аларны бетерергә тиеш инде. Менә шушы 15 октябрь 383 ел мөкаддәм бабаларыбызның түккән каннары, әбиләребезнең түккән яшьләре бездән сорыйлар бар төрк-татар баласының бер фикердә, бер юлда, бер максатта булуын һәм киләчәк октябрьгә бер җан, бер тән булып йитешеп, үз хакыбызны тартып алырдай РЕАЛЬ көчкә әйләнүебезне».

Газетаның икенче битендәге өченче баганада башланган «Төрк-татар тарихыннан» исемле мәкалә дүртенче битнең ахырынача дәвам итә. Анда Алтын Урда һәм Казан ханлыкларының шанлы һәм фаҗигале тарихларына күзәтү ясалган, татар халкының 1552 елдан соңгы милли һәм рухи коллыкта яшәве тасвирланган. Бу мәкаләдә аерым алганда, түбәндәгечә юллар бар. «…Дөньяда яшәүче һәрбер адәм баласының үзенә күрә кайгысы, зары бар һәм уртак шатлыклары да бар. Ул да булса – аларның туган хөр иле, үзләренең мәмләкәте, ул мәмләкәтне корып, балаларына бүләк итеп калдырган сөекле борынгы бабалары, шанлы падишаһлары.

Бер дәүләт никадәр тәрәкъкый иткән саен, халкы каршында шул дәүләтне корып йибәргән бабаларының да кыйммәте арта. Һәм бабаларының мирасын шул дәрәҗәгә йиткезүләренә шатлыклары зурая. Мәгәр, шул йортны югалту берлә, халкы өчен аның кайгысы, үкенече бигрәк тә әйтеп бетергесез ачы була. Чөнки бу кайгының ачысы боларның үзләре өчен генә түгел, бәлки балаларының балаларына да мәңге коллык, хурлык китерә торган бер фаҗигадер. Шундай мәхрүм булган милләт балаларыннан без дә – Идел-Урал төрк-татар мөселманнары урыс вәхшияте астында хурлыкта, хөр торган илен, шөһрәтле үз мәмләкәтен, хөкем башындагы шанлы бабаларының сүзләрен ишетә алмый, өч йөз сиксән өч ел торабыз.

…Теге сатлык хаиннәр, дәрәҗә алам дип, үз корсагын зурайтыр өчен, төрк-татар милли пәйгамбәрләре өстенә, юк гаепләрне бар дип, урыс җандармасына ялган донос ясарга да чирканмаганнар. Урыска сатылып,

«төрк-татар милләте – хыялый куәт»* дип, «ау-ау» итеп өреп йөрүче берике көчек шулай ук Ерак Шәрыктә хәзер дә бар булса кирәк…»

Газетаның дүртенче битенең өченче баганасында мондый юллар язылган. «Төркче бабамыз Йосыф Акчура угылының шигаре: «Төрклек үлмәс, юк булмас... Төрклек – төрк Тәңресе кебек мәңгелектер. Төркчелеккә тырышучыларда өмидсезлек, имансызлык юктыр». Бу сүзләр газетаның Гайшә ханым тапшырган нөсхәсендә генә бар, ә Р.Салиәхмәттән алынган нөсхәдә юк. Бу бит ахырында «28 нче октябрь – Төркиянең Кортылыш бәйрәме. Шанхай Мәдәният җәмгыяте бу бәйрәмне тантаналы рәвештә уздырырга хәзерләнә» дигән игълан басылган. Газетаның соңгы битенең түбәнге өлешендә «Мөгамәлә өчен адрес: Route Vallon, 508. Shanghai» дип язылган. Шунда ук «Газетаның нашире: Шанхай Төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте» дип күрсәтелгән.

***

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсенең 10 һәм 23 октябрь көннәрендә узган җыелышларында Төркиянең Кортылыш бәйрәме уңае белән 28 октябрьдә газета (ягъни, «Берлек»нең нәүбәттәге санын) чыгару турында карар ителгән һәм булачак эчтәлеге каралган. Күрәсең, газетаның ул саны да чыгарылгандыр. Идарәнең 4 ноябрь утырышында «Берлек» газетасы халык арасында таратылды» дип язылган сүзләргә карагангда, ул 28 нче октябрь – Төркия азатлыгы бәйрәменә багышлап чыгарылган саны булгандыр дип фаразлыйбыз.

Ә җәмгыятьнең 1935 ел 23 октябрь җыелышы беркетмәсендәге «Берлек» газетасы турында «моннан соң дәвамын туктата» дигән сүзләр 28 октябрь саныннан соң чыкмаячагын белдергән дип аңларга кирәктер.

Р.Мәрданов.

---

* Бу очракта Габдеррәшит Ибраһимның (1857–1944) «Хыялый куәтләр» исемендә чыккан язмасы күздә тотылган. «Яңа япон мөхбире» журналында 1934 елның март аенда (№15) басылып чыккан ул язмада Г.Ибраһим Россия төркиләренең бәйсезлек хәрәкәтләрен «хыялый куәтләр» дип атаган булган. Шуннан соң мөһаҗирлек матбугатында Гаяз Исхакый тарафдарларының Г.Ибраһимга каршы мәкалә һәм язмалары дөнья күргән. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналында (1934 ел, №5, 32–38 битләр) М.Б.Мөхәммәтзадәнең «Хакыйкый куәтләр» исемле мәкаләсе басылган.

## СҮЗЛЕКЧӘ

*агыр* – авыр
*аз-чук* – азмы-күпме
*алгынча* – алганчы
*англиз* – инглиз
*ашасы* – тарафы
*әҗнәби* – чит, башка милләт
*әлхасыйль* – кыскасы
*әсарәт* – коллык
*әсас* – нигез
*әфкяре гомумия* – гомуми фикерләр
*әхвале рухия* – рухи халәт
*баба* – ата
*бәгъзе* – кайбер
*бәдәл* – взнос
*бәйнәлмиләл* – халыкара
*берлән* – белән
*бинаән* – нигезләнеп, сәбәпле
*вакыйгыять* – вакыйгалар, хәлләр
*вапур* – пароход
*вәридат* – керем
*виргә* – керем
*вөҗүд* – тормышка ашыру, башкару
*гавам* – гади халык
*газый* – җиңүче
*гаид* – бәйләнешле, караган
*гайде фитыр* – ураза бәйрәме
*гаййә* – максат, төп теләк
*гайни* – үзе кебек, охшаш
*гакселхәрәкәт* – каршы хәрәкәт
*гарыз* – белдерү, аңлату
*гөрҗи* – грузин
*Громада* – украинлыларның милли-мәдәни оешмасы
*групп* – группа, төркем
*дарелфөнүн* – университет
*дәхи* – тагын
*җәбһә* – фронт, көрәш
*җәбһәдәш* – көрәштәш
*җәгърафи* – географик

*җәридә* – газета
*зәмин* – җирлек, нигез
*зольмәт* – караңгылык, золымлык
*зыяфәт* – хөрмәтләү кичәсе, кунак итү
*идеоложи* – идеология
*иен (иена)* – Япониядәге акча берәмлеге
*илән* – белән
*имкян* – мөмкинлек
*истибдад* – деспотизм
*истикъбаль (истикъбалият)* – киләчәк
*истикъляль (истикълялият)* – мөстәкыйльлек
*итәрәк* – итеп
*иштиракь* – катнашу
*йыйу* – җыю
*казаший* – казачий
*караклашу* – күзәтү, хәстәрләү, белешү
*конферанс* – лекция, чыгыш
*кортылу, кортылыш* – азатлык
*кыйраәтханә* – уку залы, китапханә
*кыйсем* – өлеш
*кятиб* – сәркятиб, секретарь
*ләһ, ләһле* – поляк
*летучка* – кыскача хәбәр язылган кәгазь
*лязем* – тиешле, зарур
*малик* – ия
*матлуб* – таләп ителгән, кирәкле
*мәгазә* – магазин, кибет
*мәгаш* – хезмәт хакы
*мәгънән* – мәгънәви яктан
*мәгъруза* – доклад
*мәҗмуга* – журнал
*мәктүб* – хат
*мәмнуг* – тыю, чикләү
*мәрасим* – йола, церемония
*мәсариф* – чыгымнар
*мәсьүлият* – җаваплылык
*мәүзуг* – тема
*мәүлиден-нәби* – Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган көне
*мәфһүм* – эчтәлек
*мәхкүм* – җәберләнгән, кыерсытылган

*моназарә* – бәхәс
*мохалиф* – каршы
*мөвакъкат* – вакытлы, вакытлыча
*мөддәт* – вакыт
*мөдһиш* – куркынычлы (*Мөдһиш Иван* – Иван Грозный)
*мөзакәрә* – фикер алышу
*мөкаддәм* – элек
*мөкаддимә* – кереш
*мөмасилә* – охшаш, тиңдәш
*мөндәрәҗә* – эчтәлек
*мөрәккәб* – җыелган, тәшкил иткән, кушылган
*мөтәәссир* – тәэсирләнгән, кайгылы
*мөфассаль* – тәфсилле
*мөхәкъкак* – шөбһәсез
*мөхбир* – хәбәрче
*мөштәрәк* – уртак
*муаффәкъ* – ирешү
*муаффәкыят* – уңыш
*мусыка* – музыка
*назыйр* – мөдир
*нам* – исем, максат
*наразый* – ризасыз, килешмәүче
*нәмәгълүм* – билгесез
*низамнамә* – устав
*ноктаи нәзар* – караш
*өндәр* – юлбашчы
*полис* – полиция
*рух шәриф* – изге рух
*сабикъ* – элекке
*садыйк* – тугрылыклы
*салават* – мактау догалары
*сахә* – мәйдан
*сахтә* – ялган
*сәмәрә* – нәтиҗә
*сәнә* – ел
*сәфир* – илче
*сима* – төс
*соңга (соңра)* – соңыннан
*сөэ истигъмаль* – явыз ният белән куллану

*сценариус* – режиссёр ярдәмчесе, спектакльнең барышын оештыручы һәм күзәтүче

*табигъ* – иярүче, буйсынучы

*тарафлы* – тарафыннан

*тарыз* – рәвеш, сурәт

*татбикъ* – куллану

*тәбәга* – граждан, берәр ил халкы

*тәгаллекъ* – бәйләнеш

*тәдриҗи* – эзлекле, эволюцион

*тәзайык* – җәбер, кыенлык

*тәклиф* – йөкләмә, бурыч

*тәкърибән* – якынча

*тәмәл* – нигез

*тәнбиһ* – кисәтү, искәрмә

*тәрҗемәи хәл* – биография

*тәсдыйк* – раслау

*тәүсыя* – киңәш бирү, тапшыру

*тәфтиш һәйәте* – тикшерү-контроль комиссиясе

*тәхкыйр* – хурлау, түбәнсетү

*тәһликә* – һәлакәт

*тәшәббес* – керешү, инициатива

*тәшкил* – оештырылу

*тәшкилят* – оешма, төзелеш

*тәэсис* – төзү, оештыру

*тугды* – туды

*тугрыда (тугрында)* – турыда, турында

*уграу* – юлыгу, дучар булу

*уларак* – буларак

*ултырдаш* – әңгәмәдәш

*ултырыш* – утырыш

*үгрәнү* – өйрәнү

*фаиз* – процент

*фатира* – фатир

*фәхри* – почётлы

*хазир* – катнашу

*харита* – карта

*хәдисе шәриф* – изге хәдис

*хәтем* – Коръән уку

*хәттый хәрәкәт (хәттыль-хәрәкә)* – тоткан юл, максат, тактика

*хәят* – тормыш

*химая* – яклау, ярдәм
*хосуста* – турында, хакында
*һәйәт* – комитет, комиссия
*һәйәте идарә* – идарә комитеты
*һәмшәһри* – якташ
*һәфтә* – атна
*һиммәт* – тырышлык
*Чин* – Кытай
*шәгарь* – шигарь, лозунг
*шәгъбә* – бүлекчә
*шималь* – төньяк
*шөгур* – аң
*эстәү* – теләү
*янгал* – ялган
*яңы (яңгы)* – яңа

# РЕЗЮМЕ

Девятая книга серии «Татарская археография» посвящена националь-но-культурной жизни тюрко-татарских эмигрантов, проживавших в 1920–1940-ых годах в городе Шанхае.

Основную часть данного сборника составляют впервые публикуемые тексты протоколов собраний правления Общества культуры тюрко-татар города Шанхая 1934–1936 гг. Данный документальный источник – журнал протоколов – был передан в 1993 году Равилем Салиахметом, проживающим в США, бывшему директору Национальной библиотеки Республики Татарстан Р.И.Валееву.

Первые татарские эмигранты попали в город Шанхай в 1922 году в составе остатков белогвардейских частей армии Колчака. Среди них были и мирные беженцы. В конце 1920 – начале 1930 годов в Шанхай переехали татары из Харбина и других городов Китая и Маньчжурии. Татарское население города Шанхая в 1920–1940-е годы составляло, по разным данным, от 200 до 400–450 человек. Они населяли французский и английский кварталы города, где проживало большинство российских эмигрантов, общее число которых в разные годы насчитывалось от 20 до 50 тыс. человек.

В 1925 году татарские эмигранты Шанхая образовали своё первое общество. В 1928 году это общество было преобразовано в «Национально-духовное общество тюрко-татар города Шанхая», которое кратко именовалось «Национальное правление» (Милли идарә). Общество занималось помощью малоимущим эмигрантам, устройством их на работу, обеспечением жильём, а также организацией культурных мероприятий и религиозных треб.

В сентябре 1934 года в этом же городе была организована ещё одна национальная организация – Общество культуры тюрко-татар города Шанхая. Оба общества просуществовали параллельно, взаимодействуя друг с другом, до 1945 года.

Руководителем Общества культуры тюрко-татар города Шанхая был Кашшаф Ахмеди (Салиахмет, 1890–1963, отец Равиля Салиахмета). Активными членами правления общества в 1934–1936 годах были Мадина Салиахмет (супруга К.Ахмеди, 1897–1964), Шахвали Кляули (1900–1970), Мансур Арсланбек (1915–1978), Кадыр Габдрахман, Латыфа Габдрахман,

Гайниджамал Ильяс. Общество полностью поддерживало идеи национального освобождения знаменитого татарского писателя и драматурга, публициста, политического и общественного деятеля, духовного лидера тюрко-татарской эмиграции Гаяза Исхаки (1878–1954). Г.Исхаки в октябре 1933 года и в марте 1936 года побывал в Шанхае и встречался с татарскими эмигрантами.

Общество осуществляло культурно-просветительскую деятельность: проводились лекции, посвящённые знаменитым личностям, татарской культуре, религиозным и общественным деятелям, а также истории, татарскому языку, литературе и искусству; организовывались литературно-музыкальные вечера, национальные и духовные праздники; обучение татарских детей на родном языке. При обществе работала библиотека имени народного поэта Габдуллы Тукая (1886–1913). Большинство мероприятий, организованных Обществом культуры тюрко-татар, проводилось в клубе Громады, то есть Украинского национально-культурного общества, где в качестве уважаемых гостей часто присутствовали лидеры украинского и грузинского движений. Деятельность общества освещалась в татарской эмигрантской прессе: газете «Милли байрак», издававшейся в городе Мукден и в журнале «Яна милли юл» (Берлин).

Членами правления Общества культуры тюрко-татар города Шанхая выпускались рукописные газеты-однодневки. Два экземпляра газеты под названием «Берлек» (Единство) от 15 октября 1935 года хранятся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки РТ. Один из них был передан Р.Салиахметом в 1993 году, а второй – профессором Калифорнийского университета США Айшой Азаде-Рорлих в 2010 году.

Общество культуры тюрко-татар города Шанхая прекратило своё существование в 1945 году, в связи с капитуляцией Японии. После 1945 года, как и большинство бывших российских эмигрантов, тюрко-татары покинули Шанхай, уехав в Турцию, Австралию, США и др.

Данный сборник содержит обзорную статью Р.Марданова, посвящённую истории и общественной деятельности тюрко-татарской эмиграции города Шанхая, тексты 72 протоколов собраний правления Общества культуры тюрко-татар города Шанхая.

В издании представлены описание журнала протоколов, именной и географический указатели, словарь. Приложение включает статьи и документы, освещающие деятельность Общества культуры тюрко-татар города Шанхая. Публикуемые в сборнике тексты протоколов и статей переложены с арабской графики на современную татарскую.

Издание снабжено иллюстрациями (образцы факсимиле рукописи, фотографии, копия документа).

ЭЧТӘЛЕК

Мәрданов Р. «Юлыбыз тугры, милләтебез көчле» ............................ 3

Шанхай Төрк-татар мәдәният җәмгыяте
идарәсенең җыелыш беркетмәләре................................................. 58

Исемнәр күрсәткече ..................................................................... 143
Географик атамалар күрсәткече ................................................... 145
Җыелыш беркетмәләре язылган дәфтәрнең тасвирламасы .......... 146

КУШЫМТА
Идел-Уралчы. Ерак Шәрыктән ............................................... 150
Идел-Уралчы. Тәгъзия .......................................................... 151
Шанхай Төрк-татар мәдәни җәмгыятенең низамнамәсе ........ 151
Равил Салиәхмәт. Шанхайда татар җәмгыяте ......................... 153
Шанхайда балалар кичәсе ....................................................... 155
Рус телендәге газетада чыккан мәкаләгә җавап (Наш ответ) 157
Мәдинә Салиәхмәт. Гаяз әфәндене Аурупага озату ............... 158
Кадыйр. Йосыф бәк Акчура истәлеге ..................................... 160
Хәбәрче. Тукай кичәсе ........................................................... 161
Шанхай Мәдәният җәмгыятенең башкармасы.
Идарәгә мәктүб ................................................................... 162
Шанхай мөхбире. Ерак Шәрыктә матәм көне ........................ 162
Мөхбир. Шанхайда 40 еллык юбилей ..................................... 164
Шанхайда милли кичә ............................................................ 165
Мөхбир. Шанхайда истәлек көннәре ...................................... 166
Мөхбир. Шанхай төрк-татарлары оешмасында Тукай моңы . 167
Мөхбир. Мәүлиден-нәби ........................................................ 169
Шанхай матбугатында Габдулла Тукай ................................. 169
Мәрданов Р. Мәдәният җәмгыятенең «Берлек» газетасы ...... 170

Сүзлекчә ...................................................................................... 176
Резюме ....................................................................................... 181

**ОБЩЕСТВО КУЛЬТУРЫ ТЮРКО-ТАТАР ГОРОДА ШАНХАЯ**

*(на татарском языке)*

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 16. 04. 2012. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ №289.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 16. 04. 2012. Формат 60х84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ №289.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.